**VII Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләре жыены**

**ПЛЕНАР УТЫРЫШ**

*3 март 2018 ел* *«Корстон» сәүдә-күңел ачу комплексы*

**Васил Шәйхразиев:** Хәерле көн, мөхтәрәм Рөстәм Нургалиевич, газиз милләттәшләр, хөрмәтле утырышта катнашучылар! Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләре жыенын" башлап җибәрергә рөхсәт итегез. Быел без җиденче тапкыр әлеге чарага җыелдык.

Бүген һәр елдагыча безнең белән бергә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов. Бүгенге җыенда шулай ук Татарстан Республикасы хөкүмәт әгъзалары, Дәүләт Советы депутатлары, Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге вәкилләре, район һәм шәһәр башлыклары, җәмәгать эшлеклеләре, татар зыялылары, Россия Федерациясенең 38 төбәгенең татар авылларыннан килгән 784 эшмәкәр катнаша.

*Иң зур делегация Башкортостан Республикасыннан (80 кеше).*

*Шулай ук күпләп эшмәкәрләр килгән төбәкләр:*

Мордовия Республикасы

Ульяновск

Самара

Пенза өлкәләре.

Мәгълүм ки, 1 март көнне форум делегатлары 5 дискуссион мәйданчыкта һәм «Татар авылларының социаль-икътисадый нигезен булдыруда эшмәкәрләрнең роле» дигән сессиядә фикер алышты. Монда яңгыраган барлык тәкъдимнәр форумның гомуми резолюциясенә кертеләчәк.

Шулай ук форум кысаларында 2 март көнне делегатлар Татарстанның Әлки районына сәфәр кылды. Алар райондагы авыл эшмәкәрләренең хуҗалыклары һәм татар авылларының яшәеше белән танышты.

Әйтәсем килә, монда безнең авыл хуҗалыгы министрлыгы Әлки муниципаль район җитәкчесе бик зур үзләренең рольләрен керттеләр һәм безнең эшләргә ярдәм иттеләр. Шуңа күрә, хөрмәтле милләттәшләр, әйдәгез әле барыбыз да аларга кул чабып, аларга рәхмәтләр белдерик.

Яңа гына Россия төбәкләрендә җитештерелгән азык-төлек һәм халык кәсебе товарлары күргәзмәсе белән таныштык. Монда илебезнең төрле төбәкләреннән 37 шәхси эшмәкәр үз хезмәт җимешен тәкъдим итте.

Хәзер инде чыгышларга күчик. Без сезнең белән регламент турында сөйләшергә тиешбез. Чыгыш ясарга теләүчеләр шактый күп. Шуны истә тотып, 5-7 минут дип билгеләсәк, ничек карыйсыз? Каршылар юкмы? Чыгыш ясаучылар каршы түгелме? Алай булгач тавышка куеп тормыйм. Каршылар булмаса, килешәбез.

Хөрмәтле милләттәшләр! Безнең бүгенге җыен онлайн режимда Бөтендөнья татар конгрессының рәсми сайтында һәм “Татар информ” республика мәгълүмат агентлыгы порталында бара.

Мин 37 регион хуҗаларына, главаларга, губернаторларга үзем исеменнән хат җибәрдем. Без Татарстанда авыллардан 750 татар эшмәкәре җыябыз дип, сезнең өлкә буенча шушындый квота дип. Әгәр дә мөмкин булса, очрашып ярдәм итегез. Һәм Татарстаннан кайткач, нинди фикер булды, нинди алга бара торган омтылышлар бар, нинди нәтиҗәләр, нинди үрнәкләр бар дип, шундый хат китте. Күбегез безгә әйттегез инде, чакырдылар, шалтыраттылар, белештеләр, ярдәм кылдылар дип. Шундый очрашулар булса, без бик шат булырбыз.

Чыгыш ясау өчен сүз “Бөтенроссия татар авыллары” иҗтимагый оешмасы Советы рәисе, Башкортстан Республикасы Туймазы районы “Йолдыз” крестьян-фермер хуҗалыгы башлыгы **Галимов Фәнир Гыйльметдин** улына бирелә. Аның темасы **“Татар авылларының икътисадый нигезен булдыру: үстерү юллары, ирешелгән уңышлар”** Рәхим итегез!

**Фәнир Галимов:** Бөтендөнья татар конгрессы каршында 8нче елдан бирле эшләп килүче “Россиянең татар авыллары” Бөтенроссия иҗтимагый оешмасы авылларны саклау һәм берләштерү, аларның иҗтимагый һәм икътисадый хәлен өйрәнү, анда эшләүче эшмәкәрләр арасында ныклы элемтә булдыру максатын алга куя.

Бүгенге форум кысаларында очрашуыбыз да безне борчыган проблемаларыбызны уртага салып сөйләшергә, аларның чишү юлларын бергәләп табарга ярдәм итәр дип ышанабыз. Без бүген шактый катлаулы үзенчәлекле чорда яшибез. Илнең азык базарында килеп чыккан кыенлыклар эшмәкәрлек хәрәкәтенә дә шактый сизелерлек йогынты ясый. Безнең оешма вәкилләре моны бик яхшы аңлый һәм килеп туган шушы авыр шартлардан чыгу юлларын бергәләп эзлибез.

2017нче елның августында Пермь өлкәсе татар эшмәкәрләре белән уздырылган I Икътисадый форумда шушы актуаль мәсьәләләр күтәрелде. Бу чарада Россиянең татар авыллары оешмасы рәисе урынбасары Алмаз Хавыев делегатларны Пермь өлкәсе татар авылларының бүгенге икътисадый хәле белән таныштырды. Авыл хуҗалыгы тармагына караган төрле темаларга түгәрәк өстәлләр оештырылды.

“Татар булган җирләрдә ат бар, ат бар җирләрдә татар бар”, - диләр. Кызганычка каршы соңгы елларда әлеге терлек саны күпкә кимеде. Килеп туган хәлне исәпкә алып, бүгенге көндә татар атлары белән кыю, тәвәккәл карарлар кабул итүебезне көтә дип тулы ышаныч белән әйтә алабыз. Шушы җәһәттән Башкортстанның Кушнарен районында туып үскән Марсель Әлтәф улы Әхияретдинов татар атларын бар дөньяга танытуының үзенчәле ысулын уйлап табып, бер төркем инициативалы кешеләр белән атларда хаҗга сәфәр кылу тәкъдиме белән безнең оешмага мөрәҗәгать итте.

Аның фикеренчә, бу татар атлары чыдам, ышанычлы терлек икәнлеген генетик ысуллар белән генә түгел, ә гамәлдә тикшереп карарга мөмкинлек бирер иде дип ышандыралар. Марсель Әлтәф улы үзе дә берничә ел дәвамында Башкортстанның Иглин районында яшәүче Хәсән Идиятуллин

белән борынгы нәселле татар атларын үрчетү белән шөгыльләнә. Ат җене кагылган кешеләрне үз янына тупларга, барларга тырыша.

Татарстанның Лениногорский районында да мондый ат җене кагылган безнең шәхесләребез бар. Татар токымлы атлар асраучы фермер Фәрит Нәбиуллин күпләрегезгә таныштыр дип уйлыйм. Инде берничә ел дәвамында аның тарафыннан оештырылучы бәйге традицион-милли күңел ачу чарасы, җәен узучы кымыз бәйрәмнәре матур традициягә әверелде. Гомумән, авыл җирендә туризмны җәелдерү максатыннан Фәрит әфәнде тарафыннан байтак эшләр башкарыла. Ә инде авыл җирендә туризм белән шөгыльләнү бизнесны күпкырлы итә дип уйлыйбыз.

Алда әйтелгәннәрне искә алып, Татарстан хөкүмәтенең шушы изге ниятне башкарып чыгуда ярдәм күрсәтүне сорыйбыз һәм татар атларының киләчәктә үзләрен бар галәмгә танытуына ныклы ышанычыбызны белдерәсебез килә.

Безнең иҗтимагый оешма 2017 елның июль аенда тагын зур бер проектны тормышка ашырды. Июль аенда Башкортстанның Туймазы районы Түбәнәк авылында беренче тапкыр Ык буе авыллары Сабантуе уздырылды. Чарага Татарстан, Башкортстан, Ырынбур, Россиянең бик күп төбәкләреннән кунаклар килде. Шулай ук чит илләрдә: Австралиядән, Кытайдан, Германиядән, Төркиядән кунаклар килде. Һәм бу инде үзе бер милли бәйрәм “Дуслык күпере”нә әверелде.

Бу күркәм чараны уздыру хокукы быел эстафетаны Татарстанның Азнакай районына тапшырды. Шушы күркәм чарага бу көнне ачык һавада “Бабай утары” этно-авылының ачылу тантанасы да өстәлде. Әлеге музей-комплексы 17нче-21нче гасырларда халкыбызның яшәешен күрсәтә торган объектлар, саман кирпечтән салынган йортлар, салам түбәле йортлар, җил тегермәне һ.б. тарихи ядкарьләр күрергә була бу этно-авылда.

Бүгенге көндә конгресс белән берлектә җәй айларында “Бабай утары”нда талантлы татар балалары өчен “Сәләт” лагерен оештыру проекты өстендә эш башладык. “Сәләт “Бабау утары” лагере алдында торган иң

мөһим бурыч – Татарстан һәм Башкортстанда яшәгән авыл балаларына хезмәт тәрбиясе бирү, киләчәк буында туган авылыбызның киләчәге өчен җаваплылык хисе, туган табигатькә мәхәббәт тәрбияләү, оештыручылар махсус программа буенча җир кешесенә хас иң гади күнекмәләргә өйрәтәчәк. Һәм шуның аша авыл шартларында да уңышлы яшәргә һәм эшләргә мөмкин икәнлеген күрсәтәчәк.

Без бөтенебез дә Татарстанга шундый итеп карыйбыз, Татарстан тирәсендә гомумән бик күп татар авыллары бар. Шушындый ук форумнарны без Киров өлкәсе белән, бүтән өлкәләр белән тагын да таныштырсак, безнең балаларыбыз аша безнең дуслыгыбыз тагын да ныгыр иде. Безнең оешма алдында торган иң мөһим бурычларның берсе – татар авыллары тарихын барлау.

Шушы юнәлештәге эшне җанландыру максатыннан 2017нче елда Бөтендөнья татар конгрессы “Безнең мирас” журналы белән берлектә “Минем авылым” иҗади һәм тикшеренү эшләре бәйгесен уздырдык. Бәйгегә барлыгы 230га якын эш кабул ителде. Димәк, халкыбыз үзенең үткәне белән кызыксына, киләчәге хакында уйлый.

Милли гореф-гадәтләрне саклауга да үз өлешебезне кертәбез. Мисал өчен, берничә ел дәвамында татар авыллары ассоциациясе Киров өлкәсе татарларының мәдәни-мәгърифәти иҗтимагый оешмасы белән берлектә хоккей ярышлары уздырып киләбез. Аларның максаты – авыл җирлегендә спортка яшьләрне җәлеп итү һәм илнең төрле регионнарында урнашкан татар авылларында яшәүче милләттәшләребез арасында милли-мәдәни багланышлар булдыру. Мисал өчен, 2018нче елның гыйнвар аенда узган ярышларга Россиянең төрле регионнарыннан килгән командалар катнашты. Инде без бу эшне киләсе елда да дәвам итәрбез дип сөйләшеп куйдык.

Чыгышымда безнең оешма белән тыгыз элемтәдә торган үрнәк итеп куярдай шәхесләребезнең дә исемнәрен телгә аласыбыз килә. Милли гореф-гадәтләребезне саклап калырга юнәлтелгән мәдәни чараларыбызның иганәчеләре: Уфадагы “Стройтехком” ЖЧҖ җитәкчесе Минвәрис Мәрвән

улы Усманов, Ульяновск өлкәсе Иске Кулатка муниципаль районы башлыгы Эдуард Әнвәр улы Ганиевка зур рәхмәтләребезне белдерәбез.

Самара өлкәсе Совет Нурлаты авылында туып үскән, бүген Самара яшәүче абыйлы-энеле Ильмухиннарны да башкаларга үрнәк итеп куясым килә. Туган авылына җан өрергә тырышкан бу егетләр киләчәктә Совет Нурлатында парк төзергә һәм шушы җирдә Сабан туен үткәрүне гадәткә кертергә телиләр. 2016нчы елның 20нче августында парк булачак урында Ильмухиннар ярдәмендә Совет Нурлатын төзүгә көч салган фидәкарь хезмәт ияләренең эшен символлаштырылган сабанга һәйкәл куелды.

Без дә бу чарада катнашып, Самара татарларының уңганлыгына сокланып, уңай тәэсоратлар белән кайттык. Әйтергә кирәк, бүгенге көндә бу асыл егетләр Самарада тагын бер татар мәктәбе ачу теләге белән янып яшиләр. Ләкин бу егетләрнең проблемалары бар, чөнки безнең җир мәсьәләсе бик катгый авыр. Фермерларга җир алып эшли башлау өчен безнең Россия законында шушындый этно-туризм ачу өчен бик катгый. Су буенда эшләргә ярамый, урманга керергә тагын ярамый, ә туризмны бит тау башында үткәреп булмый. Менә шушы проблема бар инде. Моны бергәләп депутатлар һәм җитәкчеләр белән эшләсәк, бик шат булыр идек без.

Башкортстанның Чакмагыш районы Аблай авылында уңган-булган егетләр яши: Илнур Сакаев, Рамил Хәбиров, Тәүзик Ширәеф, Айдар Габдуллин кебек эшмәкәрләр тырышлыгы белән сүнеп барган авыл бүгенге көндә яңа сулыш ала, юллар төзекләндерелә, кешеләр өчен яңа эш урыннары булдырыла, милли бәйрәмнәр, спорт ярышлары һәм башка чаралар даими үткәрелеп тора. Мондый милләт җанлы, уңган булдыклы эшмәкәрләребез башка районнарда да бар һәм аларның кылган гамәлләре башкаларга үрнәк итеп куярлык.

Әлбәттә, проблемалар да юк түгел. Дөресен әйткәндә, алар җитәрлек. Беренче нәүбәттә безне борчыган нәрсә – авыл авылларыбызның картаюы, аларда яшьләрнең төпләнеп калмаулары. Танырга кирәк, бу шактый катлаулы мәсьәлә. Ул бөтен Россия эчендә зур әһәмияткә ияder дип

уйлыйбыз. Авылларда яшь гаиләләр корылмаганда, төпләнмәгәндә аларның үсешен тәэмин итү дә гаять кыенлаша. Балалар тумый, авыл мәктәпләре бетүгә бара. Россия төбәкләрендә шул сәбәпле күпме татар мәктәпләре ябылды, күпме балалар бүген еракта рус мәктәпләренә йөрергә мәҗбүр. Ә балаларыбыз туган телне онытып, рус теленә күчкәндә, әлбәттә, авылларның милли йөзе дә җуела.

Күрәбез ки, татар авылларын саклап калу һәм үстерү мәсьәләләре милли мәктәпне яшәтү проблемасына килеп тоташа. Дөресен әйткәндә алар тыгыз бәйләнештә бара. Без күптән әйтеп килгән бер хакыйкәтьне таныргa тиешбез. Авыл – ул ныклы икътисадый нигезле булганда гына яши ала. Ә бүген базар шартларында мондый нигезне фәкать эшмәкәрлек хәрәкәте генә булдырырга сәләтле дип уйлыйбыз һәм башка чара юк дип уйлыйбыз без.

Россия киңлекләрендә уңышлы татар авыллары байтак. Аларның яшәешенә күз салсак, бер нәрсә комачаулый - кайда административ басым юк, шул җирләрдә эшмәкәрлек хәрәкәте көчәя бара. Ә бу административ басым күп җирләрдә эшмәкәрлек юлына күчәргә теләгән авыл кешесе шул киртәләргә килеп терәлә дә инде.

Кызганыч, мондый зар-моң Татарстаннан да күп ишетелә. Югыйсә, тарихи ватаныбыз Татарстан барыбызга да үрнәк булырга тиеш бит. Без бу эшмәкәрләр җыеннарын шундый чыгымнар чыгарып, юкка гына уздырмыйбыз дип саныйм. Шуңа да, әйдәгез, бергәләшеп уйлашыйк. Әлеге бюрократик әфәтне ничек җиңәргә икәнен уйлашыйк.

Чыгышымның азагында шуны әйтәсем килә. Безнең кичә Бөтенроссия татар авылларының Совет утырыш узды. Анда бик күп фикерләр яңгырады. Һәм менә безнең Совет әгъзалары теләген үтәп, шуны әйтәсем килә. Киләчәктә бу форум нәтиҗәле, милләтебезгә файдалы булсын өчен делегатлар итеп авыл өчен янып йөргән, чын фидакарь кешеләр килсен иде. Рәхмәт игътибарыгыз өчен!

**Васил Шәйхразиев:** Бик зур рәхмәт, Фәнир әфәнде! Бик төпле доклад булды. Бу безнең төп доклад инде. Шуңа күрә, хактан да, һәр әйткән сүзегез,

җөмләгез дөрес. Килгән милләттәшләргә әйтәсем килә, авылларда гаиләләр кору, балалар табу буенча безнең Президентыбыз Рөстәм Нургалиевичның карары буенча без 1 гыйнвардан башлап авыл җирлекләрендә гаиләләрдә туган балаларга грант яисә бер күләм премия бирә башладык, беренче һәм өченче бала туганга. Шуңа күрә, сөбханаллаһ, аларны алучылар бар инде, туа башладылар. Алар туу премия белән бәйләнмәгәннәр, ләкин калганнарын карап, бу авылларны саклап калу өчен, гаиләләр кору өчен, балалар табу өчен, безнең уйлавыбызча, зур ярдәм булачак.

Хөрмәтле милләттәшләр, күптән түгел Мәскәүдә авыл хуҗалыгы өлкәсендә Бөтенроссия күләмендә “Эшмәкәрлек – уңыш” бәйгесендә “Иң яхшы авыл хуҗалыгы проекты” номинациясендә “Кырдан кибет киштәсенә кадәр” дигән проекты белән Чувашстан Республикасы “Сәнҗәпов” крестьян-фермер хуҗалыгы җитәкчесе Рәшит Шәйхулла улы Сәнҗәпов катнашты һәм II урынга лаек булды. Без аны зур җиңүе белән котлыйбыз.

Ә хәзер шул проект белән таныштыру өчен сүзне Чувашиянең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, Рәшит Шәйхулла улының үзенә бирәбез. Аның темасы **“Татар авылының социаль-икътисадый нигезен булдыру максатында “Кырдан кибет киштәсенә кадәр” проектын тәкъдим итү”**. Рәхим итегез!

**Рәшит Сәнҗәпов:** Хәерле көн, хөрмәтле Президен, Президиум һәм коллегалар! Россиядә 4 меңнән артык төрле хәлдәге татар авыллары бар. Бар бик хәлләре дә, бетә барган татар авыллары да җитәрлек, урталыкны саклап яшәүчеләр дә байтак.

Вакытында безнең Озын Куак авылы бетеп баручы авылларның берсе иде. Шул чакта без туган авылларына битараф булмаган авылдашлар белән бергәләп түгәрәк өстәл артына утырып, авылыбызны ничек саклап калырга дигән сорауга җавап эзләдек. Озак уйлашканнан соң, без үзгәртүне бүген башламасак, иртәгә соң булыр дигән уйга килдек. Бу 2008нче ел иде. Авыл халкының, дусларның ярдәменә ышанып, дәүләт программаларына таянып, банктан кредит алдык, хуҗалыкны аякка бастыру өчен көрәштек.

Авылларда булган кече бизнеска җиңел түгел. Еллар эчендә без зур сораулар аша уздык. Мин үземнән чыгып әйтәм, шул вакыт эчендә тәҗрибә дә тупларга өлгердек. Бүген шул уңышларыбызны авылда эшләп ятучы башка эшмәкәрләр белән дә бүлешергә телибез.

Бүгенге көндә экспертиза узган, туган җирдә үстергән һәм җитештергән продукция девизы белән “Кырдан кибет киштәсенә кадәр” дигән әзер проектыбыз бар. Инде алда телгә алынганча, безнең бу проектыбыз Россия күләмендәге бәйгедә икенче урынны алды.

Безнең проектның уникальлеге нәрсәдә? Беренчедән, безнең азык, чимал һәм техник базабыз бар. Бу безгә югары сыйфатлы һәм конкурентлыкка каршы тора алучы продукция җитештерү мөмкинлеге бирә. Икенчедән, үзебезнең сату нокталарыбыз булу. Продукцияне арадашчыларсыз һәм кибет челтәренә урнаштырмыйча, турыдан-туры халыкка сатып, бәя сәясәтен контрольдә тота алабыз.

2017 ел авыл хуҗалыгына зур тәэсир ясады. Бөртекле культураларның, сөт бәяләренең кискен төшүенә китерде. Безнең проект шундый вариант тәкъдим итә: бөртекне сатмаска, терлекчелек аша үткәреп һәм әзер продукцияне генә сатуга чыгарырга. Шул сәбәпле бизнес бәяләр сикерешеннән саклана. Әлеге проектның тагын бер мөһим ягы бар – ул авылларны саклау һәм үстерү, авыл кешесенә эш урыннары булдыру, авыл казнасына налоглар түләү, авылның социаль һәм җәмәгать тормышында актив катнашу.

Төп максатыбыз – уңышлы тәҗрибәбез белән уртаклашу. Без әлеге проектны башка төбәкләрдә үстерү юнәлешендә килешүләр алып барырга әзер. Бергәләп сату базарыннан сыйфатсыз продукцияне кысып чыгару һәм илебездә натураль продукцияне җитештерүне һәм куллануны пропагандалау.

Хөрмәтле коллегалар, дөресен әйтергә кирәк, колбаса булса, иттән булырга тиеш, творог булса, сөттән булырга тиеш. Кеше бизнес белән шөгыльләнүче милләттәшләргә берләшергә кирәк. Бүгенге тормыш таләбе шундый. Без берләшеп бер юнәлештә эшләмәсәк, киләчәк уңышлы

булмаячак. Бүгенге көндә кооперативлар өчен дәүләт программалары да эшли. Минем бер тәкъдимем дә бар. Россия төбәкләрендәге татар авыллары эшмәкәрләренең эш тәҗрибәсе белән уртаклашыр өчен, якыннан якын танышыр өчен, бер мәйданда җыелышып тәҗрибәләр белән уртаклашыр өчен Татарстан Президенты канаты астында зур бер бизнес-бәйге игълан итәргә. Нәкъ Бөтендөнья татар авыллары оешмасы кысасында уздырылса, безгә тагын да берләшергә бер матур чара булыр иде.

Тагын бер матур күренешкә тукталып үтәсем килә. Бүгенге көндә Озын Куак авылында 300гә якын хуҗылык бар. Шулар арасында 90га якын эшмәкәр уңышлы эшләп, яшәп яталар. Яшьләр күп кала авылда. Алар үзләренә шөгыль табып, үз эшләрен булдырып, көн күрәләр һәм яратып яшиләр. Бу инде авылның бәясе арта дигән сүз. Авылыбызның кыйммәте артуда, дәрәҗәсе күтәрелүдә Бөтендөнья татар конгрессы һәм Татарстан Яңа гасыр телевидениесенең эше әйтеп бетергесез күп.

Әйтергә кирәк, алар килеп безгә ниндидер биналар ясап бирмәделәр, аларның эше нечкәрәк, уникаль дип әйтергә кирәк. Вакытында аларның эшләгән эшләренә бәя бирер өчен сүзләр табу да кыен. Аларның эше нәрсәдә? Авылыбызның тормышына кереп, халык белән эшләп, авылдашларны уятып җибәрделәр. Безнең халыкка күп кирәкми. Безнең эш нәтиҗәләребезне күрсәтеп, мактап, өмет һәм ышаныч уяттыгыз. Без рухланып киттек, юллар төзедек, йортларга сулар керттек, газ кергән, федераль трассасында йорт саен икешәр, өчәр машина. Аллага шөкер, халыкның тормышы матур якка шактый үзгәрде. Артка борылып карап, нәтиҗә ясасак, алга таба барырга тагын бер омтылыш булачак инде ул.

Эшләгән эшләребез күп, эшлиселәре дә байтак. Без үзебезнең уңышларыбыз белән бүлешергә һәрчак әзер. Уңышлы авыллар да, уңышлы эшмәкәрләр дә башка төбәкләрдә күп. Менә быел җиденче тапкыр татар авыллары эшмәкәрләре җыены уздырыла. Уңышларыбыз белән бүлешергә, тәҗрибәбез белән уртаклашырга, фикеребезне җиткерергә, республика җитәкчелеге белән очрашырга бик тә кирәкле проект ул. Аның әһәмияте бик

зур. Хөрмәтле коллегалар, бу файдалы һәм кирәкле эшебез дәвамлы булсын иде. Рәхмәт!

**Васил Шәйхразиев:** Рәшит әфәнде, сезгә эшегездә зур уңышлар! Хактан да, безнең өчен бу зур горурлык. Әле күптән түгел генә олимпиада вакытында без үзебезнең Алинә белән горурланган идек. Шуңа күрә менә шундый безнең эшмәкәрләр Россия күләмендә, дөнья күләмендә алга чыксалар, подиумга менсәләр, безнең өчен бик зур горурлык һәм татар милләте өчен зур байлык. Шуңа күрә рәхмәт!

Ә хәзер сүзне Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы “Җиләкле үзән” оешмасы җитәкчесе **Ситдиков Илдар Рөстәм** улына бирәбез. Аның темасы **“Эшмәкәрлек хәрәкәтен җәелдерүдә җиләк-җимеш тармагының мөмкинлекләре”**. Рәхим итегез!

**Илдар Ситдиков:** Безнең “Җиләкле үзән” фермер хуҗалыгы 2012нче елдан эшли башлады. Май аенда без минем ярдәмчем белән Яшел Үзән районында 2 гектар итальян технологиясенең җир җиләген, клубниканы утырттык. Шул елны без бик әйбәт урожай җыйдык һәм шул акчага 13нче елда мәйданыбыз 5 гектарга артты.

Җиләк уңышын җыйган вакытта “Ватаным Татарстан” газетасыннан Лилия исемле корреспондент безгә килгән иде. Без аның белән яхшы гына язма эшләдек. Әңгәмәбез ахырында җиләк үстерү тармагында шактый гына идеяләр булу турында һәм Татарсан Республикасының Авыл хуҗалыгы министры Марат Готыф улы Әхмәтов белән бүлешәсе килү турындагы язуны үтәгән идем. 3 көннән соң Марат Готыф улы безгә килгән иде. Без министр белән күзгә күз очрашып, Республикада җиләк үстерү ысуллары турында сөйләштек.

Татарстанның авыл хуҗалыгы министры үз эшенең остасы, үрнәк кеше булып тора. Минем карашка, ул Россиядәге иң яхшы авыл хуҗалыгы министрлыгы. Рәхмәт сезгә, Марат Готович!

2014 елда безнең хуҗалыгыбыз белән Татарстан Президенты Рөстәм Нургалиевич Миңнеханов та танышты. Бүгенге көндә 50дән артык җиләк

үстерү хуҗалыклары эшли. Алардан дөньякүләм тәҗрибә кулланып, җир җиләге, кура җиләге, карлыган, кара бөрлегәннең (ежевика) иң яхшы сортлары үстерелә. Әлеге проектны эшләп җибәрү өчен шушы тармакка 450 мең сумнан артык акча кертелде.

Җиләк кластерындагы түбәндәге ташламалар һәм субсидияләр алу мөмкинчелеген алу 70% су белән тәэмин итүе 40% техникага. Шулай ук үсентеләр утырту һәм күпъеллык үсентеләр өчен махсус федераль субсидияләр дә каралган. Россиядә җиләк үстерү тармагы 2004 нче елдан яңа көчләр белән башланып китте. Бу хәл санкцияләр кертү сәбәпләре валюта бәясе артуы һәм срогына бәйле дефицит барлыкка килү нәтиҗәсе булды.

2015-2017нче елда күпләп сатып алучылар 1 тонна бакча җиләге, клубникага 210 мең 600 сумга якын оптовый бәяләр булган. Кура җиләге, кара бөрлегән, бакча җиләге пленкадагы туннельләрдә үстерү табышы төрле яктан арзанга төшә. Әлеге ысул белән үстерелгән вакытта легитация срогы арта, зыян күрү күрсәткечләре кими.

Татарстанда 1 гектардан тотрыклы рәвештә клубника 45 тонна, кура җиләге 35 тонна, ежевика 25 тонна җыеп алына. Республикада җиләк-җимеш үстреү өчен яхшы шартлар тудырылган һәм ул үзенең нәтиҗәсен дә бирә. Мисал өчен 13нче елда әлеге тармакта 2 гектар җир эшкәртелсә, 2017 елда җир мәйданнары 450 гектарга кадәр җитте.

Җиләк культурасына сатып алучылар тарафыннан сорау һәм кызыксыну тудыра. Мисал өчен, кара карлыган үстерү тулысынча механиклаштырылган. Уңыш бу очракта 1 гектардан 14 тоннагача җитә. Утырткач та, икенче елда җимеш бирә башлыйлар. Карлыганнан уңышны 15 ел җыярга мөмкин. Кара карлыганда корткочлар зыяны булу нәтиҗәсендә аңа карата минималь эшкәртү кулланыла.

Бүгенге көндә Әлмәт районында 97 гектар мәйданда тамчылы су сибү технологиясе белән кулланып, карлыган үстерелә. Әлеге җирдә комбайн куллану уңышның 97% җыеп алырга мөмкинчелек бирә. Бүгенге көндә безнең компаниябез 1 миллион карлыган һәм 500 мең кура җиләге үсентеләре

алу өчен махсус цехлар буенча эшли. Хәзерге вакытта Татарстанда югары технологияләр, плантацияләр булдыру өчен бик зур, бик тә уңайлы шартлар бар.

Россиянең башка бер төбәкләрендә дә әлеге тармакны җәелдерү һәм үстерү буенча башка бер ярдәм күрсәтелми. Күптән түгел без бөтен Европа буйлап, Ирландиянең заводыннан теплицалар күчермәсен алдык. Алга таба шул завод белән берлектә эшләргә планлаштырабыз. Киләчәктә ике үзәк фермерлар җитештергән продукцияне саклау һәм Европа кооперативларына нигездә сату итү өчен кабул итә алачаклар.

Татарстанда 1 гектар җирдән 15 миллион сум табыш алу мөмкинчелекләре бар. Бары тик тырышып эшләргә һәм яхшы сыйфатлы продукцияләр үстерергә кирәк. Әлмәт районында Айрат Хәйруллин башлады һәм фермерлар инициативасы белән “Яшелчәләр үзәне” дигән яңа проект төзелде. Әлеге проектта катнашырга теләк белдерүче фермерларга уңайлы шартлар тудырылган. Заманча яшелчә саклау урыннары, утырту һәм уңышны җыю өчен заманча технологияләр, җирне эшкәртү өчен махсус техникалар паркы булдырылган.

Шулай ук җиләк-җимеш һәм яшелчә өчен туңдыру линияләре эшли. Әлеге кооператив Европада эшләүче кооперативларның тәҗрибәсен кулланып төзелде. Шулай ук Әлмәт районында яңа технологияләр төзү һәм барлау буенча махсус бюро төзеләчәк.

Киләчәктә яңа технологияләр табып, аларны инвесторларга тәкъдим итеп, гамәлгә ашырылачак. Якын киләчәктә без Татарстан Россиянең Голландиясенә әйләнергә телибез. Чөнки безнең халык талантлы һәм эшчән. Рәхмәт сезгә бик зур!

**Васил Шәйхразиев:** Бик зур рәхмәт сезгә, Илдар әфәнде! Сез тырышып эшли беләсез. Менә бу докладны да татарча тырышып җырып чыктыгыз.

**Рөстәм Миңнеханов**: Җырып чыкмады, татарча сөйләде. Алай дип әйтергә ярамый. Аңа кул чабарга кирәк шуның өчен.

**Васил Шәйхразиев:** Чираттагы сүз Башкортостан Республикасы «Уралагротехсервис» Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять генераль директоры **Зарипов Рәсим Миңнефәрит** улына бирелә. Аның темасы **“Башкортстан татарларында эшмәкәрлек традицияләре һәм бүгенге базар шартларында халкыбыз тормышына булган йогынтысы”**. Рәхим итегез!

**Рәсим Зарипов**: Хәерле көн, мөхтәрәм Рөстәм Нургали улы, хөрмәтле милләттәшләребез! Бер ел үткәнен сизми дә калганбыз. Без татар балалары Татарстан хөкүмәте чакыруы аркасында тагын да Казаныбызда. Ихтирамыгыз өчен зур рәхмәт!

Берничә сүз үзем турында әйтеп китәм. Мин Зарипов Рәсим Миңнефәрит улы. 1966нчы елда Башкортстан Республикасының Илеш районында туганмын. Балачак һәм үсмер елларым ямьле Сөн елгасы буенда атлар көтеп, атлар чабыштырып үтте. Совет армиясе сафларында хезмәт иткәннән соң, Башкорт дәүләт университетының юридик факультетын тәмамладым.

90нчы елда авыл хуҗалыгы техникасының запас частьләр белән тәэмин итү буенча беренче предприятиемне ачып җибәрдем. Берникадәр вакыттан соң төзелеш эшчәнлеген үзләштерә башлап, җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять «Уралагротехсервис» исемле предприятие оештырылды. 2000нче елдан алып Сургутгазпром җәмгыяте республика башкаласының янгын саклау идарәсенә төзү, монтаж эшләрен башкарулар буенча эшли башладык.

Соңгы 4 елда гына предприятиядә 1 миллиардка якын дәүләт килешүләре отты. Бүгенге көндә Башкортстан Республикасы муниципаль районы администрацияләре белән социаль объектлар даирәсендә эшлибез, мәдәният йортлары төзибез, балалар бакчалары, мәктәпләр, спорт заллары. Уфа шәһәре администрациясе коммуналь хуҗалык төзекләндерү идарәсе белән шәһәрне төзекләндерү буенча төрле эшләр башкарабыз: Уфадагы парклар, фонтаннар, ял итү урыннары – барсы да “Уралагротехсервис” оешмасы куллары белән эшләнгән эшләр.

Оешманың берничә материаль-техник базасы бар. Шулай ук гранит белән мрамор добывать итә торган карьерлары бар. 2 ел элек гранит мрамор эшкәртү цехы эшли башлады. Ул эшләрдән башка 91нче елдан алып без инде атлар ала башладык. Атлар үрчетү максатыннан Башкортстан Республикасында берничә хуҗалык оештырылды. Алтай өлкәсендәге “Катон” ат заводы сатып алынды. 2016-2017нче елларда аукцион вакытында 119нчы санлы ат заводын да без сатып алдык.

Бүгенге көндә атлар Казан, Уфа, Мәскәү, Барнау, Курган ипподромнарында сынала. Атларның баш исәбе бүгенге көндә бияләр күләменнән санаганда башкорт атлары меңнән артык, йөздән артык урыс авыр йөк аты, токымлы, 250 җирле атлар. Йөздән артык призлы токымлы атларга җитте.

Бүгенге көндә безнең оешма 5 авылда эшли. Якынча 300 эш урыны саклап калдык. Эш хакын түләп барабыз. Ат итеннән деликатеслар җитештерү цехы, кымыз җитештерәбез. Бүген Башкорт дәүләт университеты һәм Белоруссиянең сөт һәм сөт азыклары фәнни институты белән берлектә ат сөте һәм кымызны сублимацион азык җитештерү өстендә эшләр алып барыла.

Безнең атлар арасында иске татар токымлы атларга ошаган атлар да бар. Чөнки 5-6 ел элек Идиятуллин Хәсән Сәгыйтьҗән улы башлаган тәҗрибәле юнәлешкә барып кушылдык. Татарстан егетләре, биология фәннәре докторы Хәйретдинов Равил Әнвәр улы, Нәбиуллин Фәрит безнең хуҗалыкларга еш кына эзләнүләр белән килеп йөрделәр. Нәтиҗәдә, Татарстанда да берничә йөз баш иске токымлы татар атлар бәрәкәт булды. Кичәге сәфәребездә кайсыларын күреп тә кайттык.

Хәзер инде бу хәрәкәтне Татарстан хөкүмәте карарлары белән махсус программа төзеп алга алып барырга гына кала. Бу чарада кулыбыздан килгән ярдәмне күрсәтергә һәрчак әзербез. Кичәге көн тәртибендә булган Әлки районында күп күренешләр күңелгә зур уңай йогынты ясады. Һәм безнең барыбызда да киләчәккә якты ышаныч һәм якты теләкләр уятты. Район

башлыгы Никошин Александр Федорович аша безне каршы алган Әлки халкына чын күңелдән барыбыз исеменнән дә чын рәхмәт белдерәбез.

Сүземне йомгаклап әйтәсе килгән фикерем, бу үткән җыен кебек чаралар – бу билгеле бер урында җыелып бер-берең белән очрашу гына түгел, минемчә. Бу очрашулар үзара мөнәсәбәтләр урнаштырырга ярдәм итәләр, яшәүгә дәрт, көч өстиләр, үз эшчәнлегенә башка сыйфаттан карарга мөмкинлек бирәләр. Бу очрашулар бер-беребезнең арадагы киләчәк күпере. Барыгызга да исәнлек-саулык, егетләрне үткән бәйрәмнәре белән, хатын-кызларыбызны киләчәк бәйрәмнәре белән котлыйм.

**Васил Шәйхразиев:** Хактан да, безнең монда иң төп мөнәсәбәтләрнең берсе, сезне, хөрмәтле милләттәшләр, монда чакырганда без, беренчедән, сезне горизонталь буенча бер-берегез белән танышып, аңлашып, нинди эшләр эшлибез, кайда сатырга була, икенчедән, Татарстан күп кенә юнәлешләр буенча Россия күләмендә без лидер, 2нче, 3нче урыннарны алып барабыз. Шуңа күрә монда килгәч, үзебезнең стандартларны күрсәтеп, сезгә дә менә шундый эшләрне эшләргә мөмкин дип әйтеп күрсәтәсебез килә.

Менә Әлки районында булганда, Балтачта да булдык, бүтән районнарда да булдык, без инде бәләкәй генә программаны үзгәрттек. Эшне генә түгел, клубларны күрсәтеп, авылда ничек тормыш барырга тиеш дип, аларны да күрсәттек. Хактан да, әгәр дә бер-беребезгә файдалы булсак, без бер-беребезгә рәхмәтле булырбыз.

Әле 7нче тапкыр гына очрашсак та, бу Оренбург өлкәсендәге безнең тәҗрибә – ул уңышлы. Моннан ике дистә еллар элек Россиядә беренчеләрдән булып фермерлык таныклыгын алучылар арасында Оренбург өлкәсе Александров районы Ягьфәр авылыннан Газинур Яһудин да була. Башта алар КФХ төзиләр, вакыт узгач “Мишәр” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятькә әйләнә. Бүген аның улы **Яһудин Радик Газинур** улы бирелә. Ул Оренбург өлкәсе Александров районы Ягьфәр авылының “Мишәр” Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять директоры. Сүзне аңа бирәбез. Аның темасы **“Татар авылын саклап калуда эшмәкәрлекнең роле”**. Рәхим итегез!

**Радик Яһудин:** Хөрмәтле Рөстәм Нургалиевич, Президиум әгъзалары, эшкуар дуслар! Мин Яһудин Радик Газинур улы үземнең туган авылым Ягъфәрдә яшим. “Мишәр” җаваплылыгы чикләнгән хуҗалык белән җитәкчелек итәм. Безнең хуҗалыкның 6 мең гектарга якын җире бар. Хуҗалыкта 15кә якын механизатор. Безнең яктагы җирләр бик уңдырышлы булмаса да, һәр гектардан уртача 25шәр центнер иген суктырып алабыз.

“Мишәр” хуҗалыгының тарихына бераз гына күз салсак, болайрак. Аңа нигезне әтием Газинур Рафкать улы Советлар Союзы булган чорда ук 1989нчы елны Премьер-министр Иван Силаевның 25 кешедән иң беренче фермерлар ясау теләге буенча фермер хуҗалыгы ача. Әтиебез Союзда һәм бүгенге Россия хөкүмзтендә беренче фермерлардан санала.

Ул безне энем белән икебезне туган үскән җирне яратырга, нигезебезне хөрмәтләргә өйрәтте. Без 12 яшьтән комбайнда комбайн ярдәмчесе булып, 14 яшьтән үзебезнең СК-5 комбайннарында өлкәннәр белән ярышып эшләп үстек. Мәктәпне тәмамлаганда кем булабыз, кайда яшибез икәне билгеле иде. Мин агроном, туганым Рамил юрист фәннәрен сайлады. Мәскәүгә барып, югары белем алгач, без кабат туган авылыбызга әйләнеп кайттык. Туганым Рамиль юридик академияне бетерсә дә, авылда яшәп, бүгенге көнне малчылык белән шөгыльләнә. Меңләгән нәселле сарыклар үрчетә.

Безнең бүгенге иң зур теләгебез үзебезнең туып-үскән авылыбызны саклап кына калу түгел, чит-ят җирләргә дә үрнәк итеп күрсәтү. Безнең авылда 220 йорт-хуҗлыгы исәпләнә. Шуларда 530 кеше яши. Халкыбыз уңган, тырыш, иң мөһиме айнык. Авылдашлар матур һәм мул яшәсен өчен барлык шартлар да тудырылган. Нәниләр өчен балалар бакчасы, укучыларга 11 еллык мәктәп, спортчыларга спортзал. Азык-төлек кирәксә, ике кибет. Күңел ачырга, туйлар уздырырга ике кафе һәм мәдәният йорты төзелгән. Дин юлына басканнарга мәчетебез, эш теләгәннәргә 2 пилмән ясау цехы, кондитер цехлар, каз үстерү фермасы, инкубатор, 2 тегермән бар.

Авылда үткәрелгән барча бәйрәмнәр дә авыл эшкуарлары ярдәмендә башкарылган эшләр. Без ничә гасыр башка милләттәр арасында яшәсәк тә, чын татар телендә мишәрләрчә горурланып сөйләшәбез, үз телебездә җырлыйбыз. Җырчы авыл диләр безнең Ягьфәр авылын.

Татарның “Ана сөте белән кермәгән, тана сөте белән керми” дигән мәкале бар. Татар булып калуның бер авырлыгы юк. Бу үзебездән тора. Хөрмәтле коллегалар, балаларыбызны татар итеп күрәсебез килсә, тел саклансык дисәк, әти-әни, әби-бабай, аларны бишектән үк татарчага өйрәтергә тиешбез. Горур булыйк, бергә булыйк. Безне берләштерә торган Татарстан Республикасына, Бөтендөнья татар конгрессына без рәхмәтле. Зур рәхмәт!

**Васил Шәйхразиев:** Бик зур рәхмәт, Радик әфәнде! Бик дөрес әйттегез. Чираттагы сүз Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба авылы “Гафель” гаилә компаниясе хуҗалыгы **Галимуллин Әлим Фирхать улына һәм Галимуллина Эльмира Инрат кызына** бирелә. Аларның чыгышы темасы: “Гафель” гаилә компаниясе эшчәнлеге.

**Әлим Галимуллин:** Хөрмәтле Рөстәм Нургалиевич, Президиум, кадерле милләттәшләр! Мин инде бу чыгышымны кешене хыялы кая алып бара дип башлар идем. Чөнки мин үзем авыл малае. Шуңа күрә кечкенәдән урманчы булырга хыялландым. Һәм агачларның үсүе буенча кызыксындым, ничек алар үсәләр.

Бу кызыксыну мине җир йөзенең нинди генә почмакларына алып бармады. Англия, Америка кебек илләрдә укыдым. Европаның барлык илләрендә булдым. Бер сорау белән – алар анда ничек агач үстерәләр дип. Анда алган бөтен белемнәр белән мин үземнең илемә кайттым. Һәм күп кенә эшләрдә эшләгәннән соң, без Сааба районына күчендек. Шуннан мин Саба урман хуҗалыгында эшли башладым. Миңа анда бик ошады. Ләкин көннәрнең бер көнендә без тормыш иптәшем белән бер фикергә килдек үзебезнең гаилә компаниясен ачарга дип.

Безнең агач үстерү буенча питомник төзисе килде. Ләкин ул вакытта безнең акча да юк иде, җир дә юк иде. Мин инде аптырагач, шушы костюмнарны киеп Казанга да бардым берәр программага эләкмәдем микән дип. Ләкин туры килмәдем. Кайткач, тормыш иптәшемә әйтәм: “Костюмны салыйк та, эшлик инде без”, -дидем.

Шушы питомникны ясыйбыз дип, без инде күп төрле эшләр башкардык: агачтан өйләр төзү, ландшафтный дизайн. Аннары мин үземнең белемнәремне консультант буларак сата башладым. Иң рентабельлесе булып чыкты  интернет-магазин. Ул агачларны интернет аша сату. Без кыш буе заказ җыеп, яз көне таратабыз. Ул бик әйбәт эш булып чыкты. Эш башланганда бик кызык иде инде. Минем рәхмәт әйтәсе килә әниемә, әтиемә, туганнарыма. Минем әнием дә бүген монда. Чөнки алар бөтенесе ярдәм итте. Без бөтенебез бергәләп эшлибез инде бөтен эшне.

2017 елда, минемчә, җиңүләр булды инде дип уйлыйм. Без үзебезнең Байлар Сабасында матур кибет ачтык. Бу инде “Садовый центр “Гафель” дип атала. Безнең һаман да сатуның 70% бара инде интернет аша. Безнең кибетнең максаты – ул чаралар уздырып, кешеләргә бакчачылыкка, табигатькә мәхәббәт уяту. Без инде бик рәхмәтлебез Кадрия Рәесовнага безгә “Ак калфак”ны алып килгән өчен.

Безгә 170 кеше килеп киткәч, безнең белән журналистлар кызыксына башлады. Менә мондый җыеннарга чакыра башладылар. Бик зур рәхмәт сезгә! Шулай ук минем рәхмәт әйтәсем килә Саба районы башлыгына. Чөнки безнең Сабада бик матур парклар, набережнаялар төзелде. Ул безгә ышанып, яшелләндерүне безгә тапшырды. Без шул кадәр шатланыбыз, үзебезнең бәләкәй генә гаилә компаниябез районда файдалы оешма булып торганына.

Миннән күп кеше сорый: “Нәрсәгә син күченеп йөрисең, нишләп анда яшәмисең?”, -дип. Безнең Татарстан яшәр өчен иң тыныч, иң әйбәт җир. Монда бөтенесе дә эшли торган кешеләр. Алар үзләре эшләп, үзләре таба. Безнең бит инде эшләүче кешеләрнең эше сату, реализация. Инстаграмм. Ул һәрвакытта бушка. Мәсәлән, иртә белән генә дә 15 секунд шул атларның

чапканын күрсәтсәгез, сезне районнан чыгып күрә башлыйлар, кешеләр киңш бирә башлый. Мин үзем дә инстаграмм алып барам. Шуңа әйтәм инде. һәм ул нindидер бер көч бирә. Хәзер инде безнең гаилә турында минем тормыш иптәшем сөйли.

**Эльмира Галимуллина:** Хәерле көннәр, тырыш, уңган, булган татар халкының эшмәкәрләре. Мин монда сезнең арагызда булуым белән бик горурланам һәм залда утыручы бу җыенда булган кешеләр безнең өчен бик зур үрнәк. Без чын күңелдән сезнең уңышларыгызга сөенәбез.

Безнең инде гаилә компаниясе. Миннән еш кына: “Ирең белән эш алып бару, гаиләне төзү ничегрәк микән? Аның серләре бар микән?”- дип сорыйлар. Әйе, сер бар, чөнки гаилә – ул бер-береңә карамау, ә тормыш иптәшең белән бер юнәлештә карау. Һәм менә бу безнең эшебез, максатларыбыз бердәм булу, без бер юнәлештә карыйбыз ирем белән. Кайсыбер вакытта ир-ат фикере һәм хатын-кыз фикере – ул төрлечә була. Кайсыбер вакытта каршылыклар да була. Һәм аларны кушып бер яхшы идея кайвакыт килеп чыга.

Мин үзем профессиям буенча экономист. КАИ университетында алган белемем миңа хәзерге вакытта бик тә булыша. Үсемлекләргә, тирә-юньгә мәхәббәт, экологиягә битараф булмау – бу хисләрне минем эчемдә ирем уятты. Һәм мин аңа чиксез рәхмәтлемен. Ул мине төрле выставкаларга алып бара. Күптән түгел генә Америкага барып кайттык. Анда 40лап төрле питомниклар, бакча үзәкләре карап кайттык. Шунысы гаҗәп, алар бөтенесе дә гаилә белән эшлиләр.

Мин алар белән аралашып, ирем белән эшләүдә күңелдәге фикерем ныгайды. Анда буыннан буынга күчә бизнес. Без инде шуны күзаллап, үзебезнең бизнесыбызны булдырырга карар кылдык. 7 юнәлеш алдык. Безнең логотиптан күрә аласыз, шушы 7 юнәлештән акча эшләп, без питомник төзергә хыялланабыз. Бу агачның тамырлары Галимуллин Әлим Фиргатович һәм Эльвира дигәне без аны безнең балаларыбыз, оныкларыбыз дәвам итәр

дип бик теибез. Логотипка карап, без бервакытта да үзебезнең максатыбызны онытмыйбыз.

Без Әлим белән ике бала тәрбиялибез. Үзем Казан кызы мин. Ләкин балаларны тәрбияләү өчен иң уңайлы җир Саба районы дип саныйм мин һәм район үзәкләре. Чөнки балачактан ук, балалар бакчаларыннан ук стандартлар бик югары, инфраструктура бик көчле. Без үзебезнең балаларга тәрбия генә түгел, киләчәк буынга да үзебезнең белгәннәрне, тәрбиябезне бирәсе килә.

Җәй көнне безнең садовый центрда балалар эшли. Алар инде үзләре үсентеләр үстерәләр. Без аларга аңлатабыз үсетрүне, сатуны. Һәр чәршәмбе көнне Әлим инглиз клубы уздыра. Мин дә катнашам. Без анда инглизчә аралашабыз мәктәп балалары белән. Һәм еш кына Әлим скайп аша үзенең Америкадагы, Европадагы дусларын безнең Сабадагы укучы балалар белән сөйләштерә. Ул аларга киләчәктә бик көчле тәҗрибә булыр дип ышанып калабыз.

Әти белән әнинең туган авылында Коръән конкурслары да балалар арасында уздырырга тырышабыз. 2017 елда без “Салават күпере” журналы белән бик матур проект ясадык. 10 мең данә чыршы орлыклары тараттык. “Киләсе буын өчен урман утыртыйк” дигән инструкция белән һәрбер бала чыршы орлыгын алды, утыртты, үстерде, көндәлек алып барды һәм “Салават күпере”нә җибәрде. Без инде җиңүчегә “Гафель” компаниясе кыйммәтле бүләк бирдек.

Әлим генл әйтә: “Әгәр дә кешенең күңелендә табигатькә, үсемлекләргә ярату булса, ул кешенең эчендә начарлык беркайчан да була алмый. безнең гаиләдә шулай, минем ирем идеяләр бирә, ә мин үземне аның булышчысы дип саныйм. Бу форсаттан файдаланып, бөтен хатын-кызларны якынлашып килүче бәйрәм белән котлыйм. Хатын-кызның көче йомшаклыкта дип саныйм. Ир-атларыбызны үстерик, канатландырыйк. Безнең илебезнең ирләре көчле булса, безнең илләребез тыныч була дип уйлыйм. Алланың рәхмәте яусын. Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт!

**Васил Шәйхразиев:** Бик зур рәхмәт сезгә, Әлим әфәнде, Эльвира ханым! Хактан да, бик матур чыгыш. Татар милләте ул һәрвакытта да үзенең гаиләләре белән көчле булган. Бик зур рәхмәт!

Сүз Оренбург өлкәсе “Оренбург шәлләре” оешмасы генераль директоры, эшмәкәр, Оренбург өлкәсенең “Ак калфак” оешмасы җитәкчесе **Әбсәләмова Альбина Фаиль** кызына бирелә. Аның темасы **“Оренбург шәлләре оешмасы мисалында авыл җирендә яшәгән халыкны эш белән тәэмин итү юллары”**. Рәхим итегез!

**Альбина Әбсәләмова:** Хәерле көн, хөрмәтле җыенда катнашучы милләттәшләребез һәм хөрмәтле Президентыбыз рөстәм Нургалиевич! Сезгә татар дөньясының гаҗәеп тирән тарихлы истәлекләре сакланган Оренбург якларыннан кайнар сәлам алып килдек.

Бүген без бик тә кызыклы, уйландыра да, яңа карашларыбызны арттыра да торган фикерләшү мәйданчыгына җыелдык. Бирелә катнашучы һәрберебезгә бер-беребезнең эшләре дә бик тә кызыклы. Һәр елны безне очраштырып, фикерләшергә, аралашырга мөмкинлекләр тудырган оештыручылабызга ихлас рәхмәт.

Бүген миңа шушы трибунадан чыгыш ясау мөмкинлеге бирелгән икән, эшебез турында гына түгел, татар авылларында борынгы һөнәрләребезне, чын татар һөнәрләребезне саклап калуга оешмабыз, гаиләбезнең керткән өлеше турында берничә фикер җиткерәсем килә.

Мин үземнең белгечлегем буенча фельдшерлык белгечен үзләштерсәм дә, кияүгә чыгып берничә ел үткәч, ирем Фаиль белән шәхси эшебезне ачып җибәрдек. Ә инде 2008 нче елдан “Оренбург шәлчеләре” оешмасын оештырып, аның җитәкчесе булдым. 17нче елдан Оренбург шәлчеләре кулланучылар кооперативы идарәсе рәисе итеп билгеләндем.

Бүгенге көндә үзебез ясаган әзер продукциябезне халыкка җиткерү өчен 4 кибет оештырдык, ә икесен кибет-музей дип җиһазладык. Халыкара күргәзмәләрдә катнашабыз. Гарәп Әмирлекләрендә, Казакъстанда, Германиядә, Италиядә, Россиядә безнең Оренбург шәлләре бик югары бәя

ала. Хыялыбыз – тагын да зуррак масштабларда эшне оештыру. Бөтен мөмкинлекләр дә бар, иренмәскә генә кирәк. Ялкау гына булмаска кирәк.

Беренче шәлемне бәйләгәндә миңа 6 гына яшь иде. Бу һөнәр орлыгын бала чактан ук минем калебемә әбием белән әнием салды. Һәм хәзер шул орлыкларның җимешләрен татыйм дип сөенәм. Без гаиләбез белән “Авыл яшәсә – ил яши” дигән гыйбарәне алдыбызда максат итеп яшибез. Шуңа күрә дә оешмабызда эшләгән йөз кешенең 86 кулдан бәйләүчесе Оренбург өлкәсенең төрле татар авылларыннан.

Минем фикеремчә, бала чактан ук һөнәрне тирәнтен үзләштергә очракта гына, зур нәтиҗәләргә ирешергә була. Шуңа күрә үз һөнәребезне балаларыбызга өйрәтүне, аны югалтмыйча, буыннан буынга тапшыруны үзмаксат итеп куйдык. Бүгенге көндә Сакмар районы Татар Каргалысы авылы, Саракташ авылы Рәдүд авылы, Переволоцк авылы Зубачи авыллары мәктәпләрендә үзебезне һөнәрчелеккә өйрәтә торган сыйныфлар оештырдык. Анда 7 яшьтән алып 14 яшькә кадәр 47 бала шөгыльләнә. Алар арасында 2 егетебез дә бар. Әгәр дә егетләр дә кызыксынып өйрәнәләр икән, бу безнең кечкенә генә җиңү дип уйлыйбыз. Сыйныф атнасына 6 сәгать эшли. Аларны иң яхшы белгеч-осталар эшләтә. Балалар өчен чималны, эш коралларын, укытучылар өчен хезмәт хакларын да үзебез түлибез.

Шәлне бәйләүне генә түгел, ә бу һөнәрнең бөтен процессын үз куллары белән эшләп карыйлар балалар. Мамыкны юалар, тарыйлар, җепне әзерләгәч, миллиметрлы кәгазьгә бизәкләр төшереп, бәйли башлыйлар. Үзебезнең “Оренбург шәлчеләре” предприятиесенең дебет, мамык эшкәртү цехына сәяхәтләр оештырабыз. Бу сәяхәт балаларга бик тә ошый инде. Чөнки алар зурлар белән беррәттән дебетне тетәләр, юып, буяу серләренә төшенәләр. Чимал эшкәртүнең яңа ысуллары белән дә танышалар. Машина белән җеп эрләргә өйрәнәләр. Энә дә тота белмәгән балаларның бүген шәл уртасы гына түгел, ә шәлнең матур итеп читләрен, оста итеп бәйләп утырулары безне бик чиксез куандыра инде.

2016 елны мине Бөтендөнья татар хатын-кызларының “Ак калфак” иҗтимагый оешмасының Оренбург өлкәсендәге бүлекчәсендә җитәкче итеп куйдылар. Бу инде миңа татар авыллары, андагы милләтебез, балаларыбыз, яшьләребез, хатын-кызларыбыз белән эшләү өчен өстәмә йөкле икәнен аңладым. Аллага шөкер, бүгенге көндә өлкәбезнең 16 татар районының 14дә оешмабызның бүлекчәләре ныклап эшли.

Һөнәрләребезне саклау һәм кайтару йөзеннән күп эшләр башкарыла. Барсын да әйтеп тормыйм инде. Ләкин балаларны кызыксындыру өчен “Шәл бәйләдем, шәлем түгәрәк түгел” дигән бәйгенең дә отышлы булуын әйтеп китәсем килә. Россия халык сәнгать промыселләре ассоциациясе әгъзасы булып торганлыктан, теләгем – иң сәләтле балаларны Мәскәү шәһәрендә үтә торган “Молодые дарования” дигән конкурска алып барып, катнаштырырга. Яңа уку елыннан шундый ук сыйныфлар арттыру, халык белән үткәрә торган чараларны киңәйтү максат итеп куябыз. Аллабирса, барсы да барып чыгар дип уйлыйм.

Без инде әлеге эшләребездән бик кәнәгать. Чөнки бернигә карамастан эшкуарлар гаять мөһим бурычларын үти. Татар авылларын саклауга үз өлешләрен кертәләр. Ә безнең мамык шәлләр исә нык җепләр кебек, таралмасын өчен сала тормышын бәйләп тора. Оренбург өлкәсенең горурлыгы булган шушы тармак хезмәткәрләренең бу төп теләге. Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт!

**Васил Шәйхразиев:** Рәхмәт! Хәзер мин сүзне Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районыннан шәхси эшмәкәр **Миңнебаева Гөлсем Әдеһәм** кызына бирелә. Аның темасы **“Авыл яшәсә – ил яши” (Балтач районы мисалында эшмәкәрлекнең үсеше”).** Рәхим итегез!

**Гөлсем Миңнебаева:** Әссәләмәгәләйкүм, хөрмәтле җыенда катнашучылар, хөрмәтле президентыбыз Рөстәм Нургалиевич! Без бүген бик тә үзенчәлекле, абруйлы җыенда катнашабыз. Залга тормышыбызны әйдәп барырга, үзе яшәгән төбәкнең әйдәманы булырга тиешле халкыбызның булдыклы уллары һәм кызлары – эшмәкәрләр җыйналган. Җыенда

Президентыбызның, хөкүмәт әгъзаларының катнашуы, җыенда катнашучыларга зур өметләр баглануын күрсәтә. Шуның өчен дә мин бу җыенда катнашуыма бик тә шат.

Конгресс тарафыннан оештырыла торган мондый очрашу беренчесе генә түгел. Ул очрашуларның һәрберсе гаять зур әһәмияткә ия. Менеә шундый әһәмиятле форумга җыелганбыз икән, минемчә, сөйләшүне эшмәкәрләрне үстерү кысаларында гына алып бару урынлы түгел. Без инде ул стадияне үттек. Булдыклы уйлый һәм уйлап гамәл кыла белә торган кешегә бүген эшмәкәрлекне булдыру һәм үстерү өчен шартлар җитәрелк дип саныйм.

Егетләребез, чыннан да, уйланалар. Нәтиҗәдә, эшмәкәрлекнең нәтиҗәлеген һәм эффектлыгын нык итеп үстерү юллары табыла. Районыбызда бүген комплекслы кооперация алымы практикага кереп бара. Кайсыдер авылда күп итеп, мәсәлән, терлек асраучылар, ит җитештерүчеләр бар. Икенче бер авылда үзебезчә борынгы халык рецептлары нигезендә колбаса ясау, казылык җитештерү осталары бар. Ә инде бу продукция һәркайда үтемле, көтеп алына. Сату бәясе дә отышлы. Күп итеп каз, үрдәк, күркә асраучылар белән алардан какланган, киптерелгән, ысланган кош ите җитештерү кооперацияләре шуның тагын бер отышлы мисалы. Билгеле, проблемалар бар һәм булачак. Аларны хәл итәргә, хәл итү юлларын эзләргә кирәк.

Әмма минем бүгенге сөйләшүне башка яссылыкта күрәсем килә. Сүзне бүген ничек итеп эшмәкәрләрне урыннарда киң җәмәгатьчелекне актив нәтиҗәле эшкә тартып, урында тормышны яңартучылар итәргә. Яңарыш двигательләре итәргә дигән аспектта алып барырга кирәктер. Эшмәкәрләрнең урыннарда абруе да, мөмкинлекләре дә зур. Алар белән халык та, җитәкчеләр дә исәпләшә. Әнә шул абруй мөмкинлекләрне, конкрет урындагы поблемаларны урында файдалану да җитеп бетми әле. Югыйсә Республикабыз җитәкчелеге тарафыннан бик күп матур инициативалар

үткәрелә. Һәр елыбыз мәгънәле бер исем астында уза. Һәм шушы юнәлештә хәтсез игелекле эшләр башкарыла.

Республикабыз күләмендә бик актуаль социаль программалар эшли. Аларның нәтиҗәсен без үзебезнең җирлегебездә дә ачык тоябыз. Сугыш ветераннарын  һәм аларның тол калган җәмәгатьләренең фатирлы итү программасын гына алыйк. Минем әнием ягыннан булган Мифтахетдин бабам йортыннан сугышка 6 ир-ат чыгып киткән. Аларның 4се кире әйләнеп кайтмаган. Менә шушы нигездә ветеран йорты төзелүне авылдашлар улларны кайгырту гына түгел, Ватан азатлыгы өчен шаһит булганнарга һәйкәл буларак кабул иттеләр авылның түбән очында. Яки авария хәлендәге тораклардан котылу программасы.

Авылыбызны ямьсезләп торучы сельхозтехника заманында ук салынган баракларның тиешле яшәү шартлары булмаганнары сүтелде. Һәм 12 авылдаш гаиләбез 2018нче елны яңа фатирларда каршылады. Мондый мисалларны дәвам итәргә була. Бу бит бер авыл җирлегендә. “Авылларны үстерү” федераль программасы яшь гаиләләрне фатирлар белән тәэмин итү, авыллар юллар кертү, чиста су кебек күп программалар авыл кешесенең тормышын яхшыртуга юнәлдерелгән.

Кешене, шулай ук менә монда утырган барлык авыл эшмәкәрләрен дә туган авылы үстерә. Шулай булгач, туган авылыңны үстерү, аны дөньяга таныту шушы авыл үстергән күренекле шәхесләр, эшмәкәрләр бурычы булып чыга. Без барыбыз да аңлыйбызмы моны?  Үз эчебезгә бикләнеп кенә яшәмибезме? Минем кабатлап шундый сорау бирәсем килә. Ә менә ул игелекле программалар урында, әйтик кечкенә генә бер авылда, урындагы мөмкинлекләр кысаларында үзенең дәвамын табамы?

Кариле авылы борынгы чордан зур байлар, эшмәкәрләр авылы булып танылган. Шушы авылдан чыккан Усмановлар, Юнысовлар Казанның иң абруйлы, иң атаклы байлары булып тарихка кергән. Казанның үзәгендә без һәр адымда аларның игелекле эшләренә юлыгабыз. Казанның иң борынгы

мәчетләрен, мәдрәсәләрен алар төзеткән. Әлеге мәчет, мәдрәсәләр алар хисабына яшәгән.

Ятим, каравылсыз балалар өчен, мөселман балалары өчен дөньяда беренче приютны Юнысовлар төзеткәннәр. Һәм аларны үз хисапларына эшләткәннәр. Казанда йогышлы авырулар таралган чорда махсус бина сатып алып, мөселман авырулары өчен хастаханәләр оештырганнар, алар өчен табиблар, шәфкать туташлары тапканнар. Шулай ук үз хисапларына тәэмин иткәннәр.

Әлеге изге җаннарның игелекле эшләре рус байлары өчен үрнәк итеп күрсәтелгән. Аларның игелекле эшләрен санап бетерерлек түгел. Алар озак еллар Казан татар Ратушасында җитәкчелек иткәннәр. Туган авылларын да онытмаганнар. Бүген менә шушы изге традицияләр дәвам итәме? Без әнә шул ерак бабаларыбыз истәлегенә тугрылыклымы?

Бүген дә бит  һәр авылдан диярлек шунда туып, үсеп читтә яшәүче зур эшләр башкаручы шәхесләр, эшмәкәрләр бар. Аларның һәрберсенең туган авылы өчен зур игелекләр кылырлык мөмкинлекләре бар. Мин аларның һәрберсенең туган авылларында, бу кешеләрне үстергән авылларында матур итеп үз йортын булдыруларын теләр идем. Ял вакытларында, ял көннәрендә мөмкинлек булганда гаиләсе белән шунда кайтсын, туган җир тойгысын яңартсын иде. Балалары тирән тамырларының кайда икәнен күреп, шушы җиргә бурычлы икәнен аңлап үссен. Табигать шифасын сеңдерсен иде.

Монда утыручы эшмәкәрләрнең һәм Казанда яшәүче эшмәкәрләрнең, Мәскәүдә яшәүче эшмәкәрләрнең, Казанда, Мәскәүдә фатирларыбыз бар бит. Ә нишләп әле менә шушы ук безнең эшмәкәрләрнең безне үстергән авылларыбызда матур авыл йортлары булмаска тиеш?

Хөрмәтле Рөстәм Нургалиевич, референдум уздырып, шуның нәтиҗәләре белән туган төбәгебезне төзекләндерү өчен тупланган акчаларны 4 мәртәбә арттырып, республика букетыннан кайтару инициативасы өчен барлык авылдашларым исеменнән сезгә олы рәхмәтемне җиткерәм. 1 сум, 4 сум булып үзеңә кайтсын әле. Кайда акчаны шулай эффектлы итеп эшләетп

була соң? Бу безгә бик кирәкле программа. Авыл халкы бу эшкә башта читләтебрәк караса да, нәтиҗәләрен күргәч бу программада, бик теләп катнашабыз. Озын гомерле булсын ул.

Менә монда дәүләт тарафыннан акча бирелеп эшләгән программалар турында мин күбрәк әйттем. Ә менә хәзер берничә сүземне акчасыз эшмәкәрләр белән эшләгән эшләргә юнәлтәсем килә. Күптән түгел генә декабрь аенда мәктәпнең 100-еллыгын үткәрдек. Без бу чарага бик әйбәтләп әзерләндек. Җомга көнне башланды, шимбә көнне бетте. Ике көн бәйрәм иттек.

Районыбызда Казанның 1000-еллыгы исемендәге мәдрәсәсе эшли. Шушы мәдрәсәне бетергән барлык кешеләрне җыеп, укытучыларыбызның зират каберләренә барып, догалар кылып, менә шушыны оештырдык. Ә җомга вакытында имамнарыбыз мәктәбебез өчен дога кылдылар, гыйлем, дөньяви белем һәм дини белем буенча вәгазь сөйләделәр. Ә икенче көнне 140 кешегә әзерләнгән табынга мәктәп ашханәсендә, пенсиягә чыккан барлык укытучыларны җыеп, истәлекле бүләкләр биреп, монда да ике имамыбыз катнашты, аларның истәлекләре белән уртаклаштык. Шундый матур мәҗлес булды инде! Обедтан соң клубка төштек. Анда укучыларның кул эшләре, тарих буенча күргәзмәбез һәм үзебезнең мәктәпне бетергән укучыларның официаль өлеше булды.

Менә монда район администрациясе үзидарә эшләде, мәктәп эшләде, детсад эшләде, колхоз эшләде. Яңадан “Ак калфак” оешмасы катнашты, китапханә, клуб, хатын-кызлар оешмасы катнашты. Менә күпме оешма! Монда чыккан акчаның бөтенесен, Аллага шөкер, үзебезнең мәктәпне бетергән эшмәкәрләр бөтенесен үз өсләренә алдылар.

“Үз мәктәбеңә булыш” дигән программа ялт итеп, бөтен халыкның җыйнап, шундый бәйрәм итеп, шундый матур итеп эшләде. Ә нишләп “Үз туган авылыңа булыш” дигән программа эшләмәскә тиеш? әйдәгез, кабул итик андый программаны. Сорыйк Республикабыз җитәкчеләреннән.

Минем күптән күңел түрендә йөрткән бер хыялым бар. Кечкенәме ул, зурмы, һәр татар авылында көчле рухлы, эшлекле авыл халкын үз тирәсенә туплый һәм игелекле эшләргә күтәрә ала торган мәхәллә булдыру. Безнең җирле үзидарәгә 6 авыл керә. Кайсын гына карап бетерсеннәр. Һәр авылның үз хуҗасы булырга тиеш. Минем туган авылымда аның 10 елдан артык эшләп килүче башлангычы бар инде. Бу авылда башкарган игелекле эшләр дә хәтсез. Беркемне дә борчымыйча, үз көчебез белән, үз хисабыбызга авылның һәр йортына табигый газ керттек, һәрбер йортка чишмә суы китерттек, авылның урамнарын төзекләндердек. Мине татар авылларындагы зиратларның хәле бик нык борчый. Үз авылыбызның зиратын нигезле итеп, чистартып тәртипкә китердек. Бу эш дәвам итә. Бу эштә бөтен авыл халкы бик теләп катнаша.

Күптән түгел генә авылыбызның күп гасырлык тарихын архив документлары нигезендә тәфсилле итеп бәян иткән “Кариле – кара ил исеме” исемле зур китап бастырып чыгардык. Менә бу китапны да башлап йөрүче эшмәкәр булмаса, гади авыл кешесе генә моны эшләп бетерә алмый. Чөнки һәрбер ахривка барсаң, анда акча кирәк. һәрбер документны сатып алырга кирәк. Менә моның башлангычында без ятарга тиеш, шушында утырган кешеләр ятарга тиеш. Һәм инде һәрбер нормальный авылның тарихлы китабы булырга тиеш.

Шушы эшмәкәрлекнең, аның да нигезендә эшмәкәрлек ята. Рамазан айларында ифтар мәҗлесе турында. Безнең иң беренче елларда моннан бер 15 еллар элек авылда йә мин үткәрә идем һәм бер тапкыр мәчет үткәрә торган иде. Ә бүгенге көндә 3 ел рәттән инде 15ләп йорт берләшә, урам-урам булып берләшәләр дә, Рамазан аеның беренче көненнән башлана ифтар мәҗлесләре, ахыргы көненә кадәр, хәтта чыешып та бетә алмыйбыз ахыргы көннәрдә, 30шар күрше җыйналып, ифтар мәҗлесләре оештырабыз.

Монда инде мәчеткә аягын атлап кермәгән яшь киленнәр дә керә. Мәчетне дә күрәләр, эшне дә күрәләр. Авыл гөрләп тора. Тагын да татар икәнебезне үзебезнең матур яшәвебезне күрсәтә алабыз. Безнең авылыбыз

бик матур, төзек. Аны тагын да ямьлерәк итәсебез килә, чөнки бу тормыш матурлыгы дигән сүз.

Шуны да әйтеп китим, безнең авыл аша бөтен Россияне иңләп үтә торган тарихи себер юлы уза. Моннан илнең әллә кайсы төбәкләренә көн саен йөзәрләгән машина уза. Безгә карап алар татар халкының тормышын, яшәешен бәялиләр. Минем фикерем, дәүләт биргәнне генә көтеп утырырга түгел, авыл җәмгыяте авылның күп проблемаларын үзе дә хәл итә ала.

Хәзер авылларда мәчетләрнең роле бик зур һәм үсә бара. Һәр авылга тирән белемле, халкыбыз әйткәнчә, йөрәкле, көчле, үз фикерен үткәрә белә торган  иман кирәк. Ул динебезне өйрәтсен, әхлак тәрбиясен бирсен, мәктәп, мәдәният мәсьәләләрен аңлатсын һәм аларны чишәргә ярдәм итсен. Мәхәлләнең җитәкчесе булсын, мәхәлләсе белән акча эшли алсын. Акчалы мәхәллә кирәк. Бүген инде шундый егетләр бар, әмма аларның статусы тәгаенләнмәгән.

Булган егет әле мин санаган эшләрне рәхмәт өчен генә эшли алмый бит. Аның яшисе, гаиләсен туйдырасы, балалар үстерәсе бар. Имамның эшмәкәр егетләрнеке шикелле яхшы йорты, яхшы машинасы булсын. Аның сүзе үтсен. Ул халыкны, халык аны бер сүздән аңларлык булсын. Һәм иң әйбәте, кем мәхәллә хуҗасы, ул имаммы, башка кешеме, ул дин мәнфәгатен, үз мәнфәгатеннән өстен күрсен, авылдашлары мәнфәгатен, авыл мәнфәгатен ул инде шулай ук үз мәнфәгатеннән өстен күрергә тиеш. Менә шул вакытта гына безнең мәхәллә яшәячәк. Менә шул вакытта гына авылның үз хуҗасы барлыкка киләчәк.

Бу мәсьәләгә дәүләт игътибары кирәк, чөнки һәр авылда үзенең көчле рухлы хуҗасы булмаганда, дәүләт инициативасы программалары бервакытта да көтелгән нәтиҗәләр бирмәячәк. Авыл җәмәгатьчелеге, бигрәк тә эшмәкәрләрне дәүләт җитәкчелеге көче һәм инициативасы белән мин бу мәсьәләне тормышка ашырып була дип саныйм.

Форсаттан файдаланып, татар конгрессына, Диния нәзарәтенә, хатын-кызлар җәмгыятенә хатын-кыз буларак, бигрәк тә “Ак калфак”, татар

гаиләләре, мөслимә хатын-кыз иҗтимагый оешмаларына ихлас рәхмәтемне ирештерәсем килә. Безнең эшебезне җанландыруда нәтиҗәлерәк һәм мәгънәлерәк итүдә аларның булышлыклары бәя биреп бетергесез.

Безнең яшәвебезнең девизы шундый булырга тиеш – гомереңне шәм яки лампа кебек тик бер өйне яктыртуга сарыф итмә. Кояш кебек һәр тәрәзәгә нур иңдер. Барчагызга да уңышлар телим. Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

**Рөстәм Миңнеханов**: Бик зур рәхмәт! Гөлсинә ханым бик дөрес мәсьәләләр күтәрде. Әлбәттә, һәр авылның тарихы булырга тиеш. Менә күрсәттеләр китаплар. Мин күрсәтмә бирдем бу авыллар турында передачалар эшләргә. Авыллар турында гына түгел, кешеләр турында. Күренекле, шушы авылдан чыккан кешеләр турында, тарих турында сөйләсәң, ул бик кирәк.

Икенчедән, мин сезнең белән риза. Әгәр дә сезнең нигезегез юкка чыга икән, аннары ул бит инде нәрсә дигән тарих. Шуңа күрә эшмәкәрләрнең генә мөмкинлеге бар. Нигезне сакларга, анда кайтып йөрергә һәм мәктәпкәме, авылгамы ярдәм күрсәтергә. Аннан беребезнең дә акчасы да кимеми, рәхмәттән башка, саваплы эш.

Әлбәттә, мин сезнең белән риза, мәчетләрдә бик оста, халык ярата торган имамнар булырга тиеш. Безгә укыту һәм бүтән мәсьәләләрне карарга кирәк. сезнең чыгышыгыз бик эчтәлекле, бик урынлы. Кул чабыйк әле матур итеп.

**Васил Шәйхразиев:** Бик зур рәхмәт, Рөстәм Нургалиевич! Хөрмәтле милләттәшләр, кичә без барыбыз да Әлки районында булдык. Һәм беләбез инде анда ике бертуган Шәйхетдиновлар бик тырыш эшлиләр. Бу безнең өчен күренеш уникаль. Аларның ике аерым фермалары бар, шунда эшлиләр. Иң мөһиме менә шушы безнең ике милләттәш 200дән артык эш урыны оештырып, бүгенге көндә халыкка эшләргә мөмкинлек бирәләр. Безнең төп мөнәсәбәт, эшмәкәрләр җыелдык. Хактан да, без халкыбыз өчен эш урыннары ясыйбыз һәм аларга үзләренең эшләргә мөмкинлекләрен биреп, хезмәт хакын түләп, авылда калырга мөмкинлекләр бирәбез.

Без хәзер чыгыш ясарга аларның берсен чакырыр идек. Аның төп чыгышы **“Авылның социаль-икътисадый нигезен булдыруда эшмәкәрлекнең роле”**. Рәхим итегез!

**Дамир Шәйхетдинов:** Исәнмесез, хәерле көн, хөрмәтле Рөстәм Нургалиевич, хөрмәтле Президиум, чакырылган кунаклар! Мин Дамир Әсхәт улы Шәйхетдинов Әлки районы егете. Әлки районы Түбән Әлки урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, 1989нчы елда югары белем алу теләге белән Казанга килдем. 1994нче елда Казан авыл хуҗалыгы институтын уңышлы тәмамлаганнан соң, туган якларга юл тоттым. Максатым – туган якта эшләү, яшәү иде.

Эшмәкәрлегем 1995нче елда башланды. Баштан Газель, аннары КамАз алу бәхетенә ирештем. Шул машиналар белән төрле урыннарга, авылларга, хуҗалыкларга продукция, икмәк ташый башладым. Казакъстан төбәгеннән бертуган абыем Альберт белән авыл хуҗалыгы өчен бик кирәк булган К-700 тракторлары алып кайттык. Аны гаражда ремонтлап, әкрен генә эшебез китте. Үзебезнең Түбән Әлки авылында бик күп сельхозтехника булгач, К-700ны белә торган эшмәкәрләр бар иде.

Кызык килеп чыкты әле ул. Без аны Казакъстаннан сүтеп алып кайттык та һәм тараттык аны. Тараттык та, иртән торып чыксак, турыда сап-сары бөтен әйбер. Бөтен авыл халкы килә. Килә дә, көтү куалар алар, һәм карыйлар: “Нәрсә бу? Нәрсә бу?”, - дип. Без әйтәбез: “К-700лар алып кайттык”, - дип. Шуңа күрә безнең шул башлап китүебез шулай килеп чыкты.

Түбән Әлки авылында урнашкан сельхозтехника оешмасы таркалганнан соң, хуҗасыз калмасын диеп, бу оешманы без үзебезгә сатып алырга булдык. Бүгенге көндә бу биналарда бөртек саклау складлары, бөртек киптерү, көнбагыш мае сугу цехлары, сөт кабул итү пункты, бетон заводы урнашты. Шуларда йөзгә якын кеше эшли. Эшләүчеләрнең 70% яшьләр безнең. Күрше авыллардан, чит төбәкләрдән безнең юк, үзебезнең егетләр эшли. Безнең Әлки районы шул хәтле бай эшчеләргә. Шуңа күрә бик тырыш халык эшли бездә.

Авылыбыз, районыбыз киләчәге мине бик борчый. Шуннан чыгып, ярдәм кирәк булган фермерларга булышырга тырышам. Мәсәлән, Әлки районында 2 ферманы аякка бастырдык. Берсе Түбән Колчуринда, икенчесе күрше Әхмәт авылында. Нурлат районы Әлмәт авылында йөз баш сыерлы фермага капиталь ремонт ясадык, Чирмешән районы Лашман авылында фермага капиталь ремонт ясадык. 8 районда: Әлки, Спас, Норлат, Аксубай, Чирмешән, Яңа чишмә, Лаеш районнарында ответ-хранениегә 68 суыткыч куйдык. Алар Ковров шәһәрендә җитештерелгән.

Ә инде Түбән Әлки авылына күчсәк, анда да күп эшләр эшләдек. Мәсәлән, авылның мәчетенә капиталь ремонт ясадык, 800 метр асфальт, 500 метр бетон юллар салынды. Сез үзегез дә кичә килгәч күрдегез инде безнең күпме хезмәт түккәнне. Ел саен Сабантуй бәйрәмнәре оештырабыз. 2017нче елда Түбән Әлки урта мәктәбенең 100-еллык юбилеен уздырдык. Шундый матур, шундый зур бәйрәм килеп чыкты ул. Искитмәле булды ул.

Авылыбызда 2 миллион сумга төшкән хоккей мәйданы бастырдык. Шунысы шатландыра, анда 50 яшьлек ир-атлар да хоккей уйнарга чыгалар. Бүгенге көндә анда һәр көн диярлек хоккей ярышлары үтә. Яңа ел бәйрәмнәрендә һәр елны авыл уртасында бик зур чыршы бизибез. Яңа ел төнендә төрле авыллардан җыелган халык рәхәтләнеп бәйрәм итә. Шундый матур итеп үтә ул безнең. Анда тавы да, клубтагы кызлар матур итеп уеннар оештырып, бик матур үтә.

Мин үземне бик бәхетле кеше дип саныйм. Беренчедән, кешеләрне шатландыру үзе бер бәхет. Икенчедән, тулы гаиләм, хатыным, балаларым бар. Минем бизнеста иптәш Гөлнара бик каты булыша. Без бер малай һәм ике кыз тәрбиялибез. Киләчәгем дә өметле. Малаем минем КФУның бизнес-информатика факультетында укый. “Әти, исән булсак, мин дә кайтырмын, мин дә булышырмын”,- дип тора. Шулай ук, яратып, бөтен барлыгымны биреп эшли торган эшем бар. “Эше барның – ашы бар”, - ди халык. Эшләп яшим. Кешеләргә кирәклегемне тою яшәү мәгънәсе бирә. Әйе, мин бәхетле кеше, сезгә дә шундый ук бәхетләр телим.

Хөрмәтле Рөстәм Нургалиевич! Безнең сезгә бик зур үтенечебез бар. Кичә кунаклар килде дә, сорау бирәләр: “Авылыгызның мәчете бармы?”, - Мәчет бар. Суның теге ягында. – Анда эләгеп буламы? – Булмый. – Ничек инде булмый?”. Анда безнең 38 ел тому назад тимердән басма ясалган иде. Ул хәзер аварийный состояниедә. Без абый белән инде барабыз да шушы күпергә карап торабыз, барабыз да карап торабыз. Бөтен эшне эшли алабыз, ләкин күпер төзи белмибез.

Шуңа күрә бик зур үтенечебез, безнең авылда 280 хуҗалык, 807 кеше яши. Бер сатылырга йорт юк. Балалар мәктәп тулы, балалар бакчасы тулы. Авыл матурая, көннән көн ямьләнә. Но күперебез юк. Зинһар өчен булышыгыз инде безгә шул күперне төзергә. Без инде кая гына барып бәрелмәдек, булдыра алмадык. Сез булдырсагыз гына.

Аннары, Рөстәм Нургалиевич, беркөнне Төркиягә барып кайттым. Мин анда су бар да, ташлар да, урман юк икәнен белә идем инде. Ләкин эшмәкәрлек шуның хәтле развитый анда. Средний, мелкий, зур бизнес. Стамбул тирәсендә карап кайттык. Һәм без бер кафега эләктек бер авылда. Ул кафеда 50 метрлы үзенең музее да бар, бәлки булганыгыз да бардыр. Һәм иң матур җирдә Эрдоган белән үзенең төшкән фотографиясе бар.

Мин хыялланып утырам, мин әйтмәм дә дигән идем инде. Рөстәм Нургалиевич, мин сезне руслар әйтмешли, вживую беренче тапкыр күрәм. Минем инде хыялым – шушы күперне төзегәч, бергә өчәү басып фотографиягә төшеп, үзебезнең эштә иң матур җиргә шушы фотографияне куясым килә.

Рәхмәт бик зур барыгызга да! Кичәге өчен дә рәхмәт. Шундый матур итеп килдегез, матур итеп киттегез. Безнең Әлки районы шау-гөр килеп торды инде. Без инде шул хәтле шатландык. Абыйга әйтәм: “Абый кичә шундый рәхәт иде, геройлар идек, ә бүген кул тирләп утыра”. Шуңа күрә, бик матур булды. Килегез, аралашыйк, сөйләшик. На самом деле, безнең сөйләшәсе сүзләр күп. Эшмәкәрләр аралашырга тиеш. Без инде менә монда

утырып, 3 көнгә Казанга килеп яисә каядыр барып, бернәрсә дә югалтмыйбыз. Табышлар гына күп булачак.

Безгә өченче көнне Әстерханнан 3 егет килгәннәр иде. Сөт буенча сөйләшәбез инде. “Дамир, а почему вы так хорошо живете?”, -ди. Мин әйтәм: “Знаете почему, у нас Президент сильный, как в рекламе, Республика сильная и народ работящий. У нас если один человек гараж 6-метровый построит, то сосед обязатель 7-метровый сделает”, -димен. – Поэтому мы везде процветаем и все про нас знают”.

Бик зур рәхмәт барыгызга да! Исән-сау булыгыз.

**Рөстәм Миңнеханов:** Менә суны да эчеп китте. Бер әйберне дә югалтмый. Күпер дә төзе, су да эчерт аңа. Булдыра! Юлчылар бармы безнең монда? Минтранс бармы? Ленар, менә фотографиягә бергә төшәсең инде, күпер ясыйсыз да. Быел күпер ясагыз. Яхшы, сөйләштек.

**Васил Шәйхразиев:** Бик зур рәхмәт, Рөстәм Нургалиевич! Хактан да, егетләр нык тырыш, авыллары нык тырыш, сезнең ярдәмегез бик вакытлы булыр. Бик зур рәхмәт! Чыгыш ясау өчен сүз Курган өлкәсе “Кургансемена” фәнни-җитештерү агрохолдингы директорлар Советы рәисе, икътисад фәннәре докторы **Исламов Марат Нури** улына бирелә. Аның темасы **“Игенчелек тармагын үстерүдә “Кургансемена” фәнни-җитештерү агрохолдингы” тәҗрибәсе”**. Рәхим итегез!

**Марат Исламов:** Исәнмесез, хөрмәтле Президент, форум делегатлары! Я буду говорить по-русски. Немножко расскажу о своей фирме, о научно-производственном агрохолдинге “Кургансемена”. Мы занимаемся селекцией зерновых, зерно-бобвых семеноводством, зерновых, зернобобовых и масличных культур. Производим растительное масло, муку, занимаемся элеваторной деятельностью, зернотренингом.

Имеем 23 тысячи гектаров пашни. Емкости складские под зерно 250 тысяч тонн. 800 работающих. Из них 14 научных сотрудников, 4 доктора наук, 6 кандидатов. 9 производственных объектов расположены в 8 районах области. И нынче 18 марта в день выборов нам исполняется 30 лет.

Своим научным центром мы разработали оригинальную систему регионального семеноводства, адаптированную к рыночным условиям. Ведем собственную селекцию, занимаемся агротехнологией. Наш объем производства и реализация семян вышсих репродукций 20 тысяч тонн ежегодно. Потенциальная возможность 40 тысяч тонн. Поставляем семена в более чем в 30 регионов России, в Казахстан, Монголию.

По данным Минсельхоза России мы являемся лучшей частной семеноводческой компанией России. Участвуем в работе международных семеноводческих сетей. Являемся авторами 13 сортов. Мы разработали оригинальную влагосберегающую технологию для засушливых условий. У нас современная посевная и уборочная техника. Технологические процессы находятся под автоматическим контролем. Имеем сев завод по производству 20 тысяч тонн семян.

Наш агрохолдинг является площадкой для обучения. Ежегодно мы проводим "День семеновода", который посещают более 500 человек. Провели за этот год 5 научно-практических конференций и семинаров. Нынчы будем проводить шестую научно-практическую конференцию, посвященную 30-летию научно-проивзодственного агрохолдинга "Кургансемена" под эгидой также Минсельхоза России.

Занимаемся производством растительных масел. Наши производственные мощности по переработке 45 тысяч тонн, суточные 150 тонн. Это по сырью. Емкости хранения масла полторы тысячи тонн. Годовая производительность 16,5 тонн, суточные 55. Имеем 2 линейных элеватора Курганский и Моргашинский. Также собственные железнодорожные пути, которые позволяют ежедневно отгружать до 50 вагонов.

Приемка в год у нас порядка 200 тысяч тонн. 500 тысячный комплексный ежегодный грузооборот. В год мы отгружаем до 3 тысяч вагонов. Имеем собственный вагонный парк, 30 зерновозов, 15 зерновозов автомобильных. Занимаемся зернотрейнингом. За год отгружаем порядка 100 тысяч тонн зерновых, ежемесячно порядка 8 тысяч тонн. Поставляем

продукцию в Уральский федеральный округ и в европейскую часть России. Имеем награды: 15 золотых медалей Всероссийских выставок "Золотая осень", 13 региональных премий имени нашего земляка, академика Терентия Семеновича Мальцева. Являемся базовым предприятием Курганской сельскохозяйственной академии имени Т.С.Мальцева.

Мы включены в реестр ведущих научных организаций России. Имеем свою корпоративную культуру. Это собственный гимн, флаг, лозунг, логотип, газета и интернет сайт. Не могу не озвучить здесь свой лозунг - "Качественные семена, стабильные высокие урожаи – богатая Россия". Финансовые показатели за прошлый год. Наша консолидированная выручка 2,2 миллиарда рублей. Рентабельность 12%. Объем инвестиций был выложен 220 миллионов рублей.

Сейчас я хотел бы перейти к сути своего доклада и рассказать о роли семян. Зачастую это недооценивают. Семена – самый дешевый фактор получения стабильных высоких урожаев с хорошим качеством. Только при посеве качественными семенами можно получить наибольшую отдачу от удобрений и агротехники. В этом случае мы получим урожай с низкой себестоимостью и наивысшую прибыль.

При посеве некачественными семенами ни один агротехнический прием не поможет устранить потери, если даже вы позолотите почву. Качественные семена, районирование сортов стоят на первом месте по формированию урожая. Их доля составляет более 40%. Семена по этому показателю обходят удобрения. Доля удобрения в урожае составляет максимум 35%.

Чтобы быть успешным, надо семенам уделять особое внимание, соблюдать сортосмены и сортообновления. И мы рекомендуем сеять семенами не ниже третьей репродукции. Если будете сеять семенами низких репродукций, то не получите тот эффект от семян, о которых я говорил выше. Потому что в семенах с годами накапливается болезни. Идет

расщепление, засоряется сорняками и вредителями. В результате теряются урожайные свойства.

Мы поставляем семена от Калининграда до Сахалина и Камчатки, в Казахстан и Монголию. Нынче будем отгружать в Киргизию. Наши семена на Российском рынке по качеству и цене конкурентноспособные. У нас элита стоит в зависимости от культуры и сорта от 12 до 16 тысяч рублей за тонну. Наши семена славятся своим качеством благодаря тому, что мы в отличие от других семеноводческих фирм работаем в первичном семеноводстве по классической схеме.

Да, это сложно, тяжело, но зато мы имеем очень качественные семена. А это имя, это рынок. Сорта, с которыми работает наш агрохолдинг: Пшеница мягкая, яровая – сорт №1 в России среди яровых, мягких пшениц. Отличается высокой пластичностью, засухоустойчивостью, формирует высококачественное зерно. Средне-ранний, устойчив к неблагоприятным природно-климатическим условиям. Районирование по Волго-Вятскому, Средне-Волжскому, в Татарстане и Западно-Сибирском регионах и в Республике Казахстан.

Пшеница Тобольская, высокоурожайная, засухоустойчивый сорт. Районирован по Уральскому, Западно-Сибирскому и Восточно-Сибирским регионам. Средне-поздний. Отлично выдерживает июльскую засуху и за счет растянутого периода всхода и колошения во время которого формирует интенсивную корневую систему.

Урало-Сибирская – сорт интенсивного типа. Районирован по Волго-Вятскому, Средне-Волжскому, Уральскому, Западно-Сибирскому и Восточно-Сибирским регионам, а также в Республике Татарстан. Максимальная урожайность 67 центнеров. Сорт устойчив к засухе, полеганию, болезням, имеет повышенную устойчивость к неблагоприятным факторам среды. Обладает высокой озерненностью. Формирует высококачественное зерно.

Урало-Сибирская-2. Новый сорт. Будет предложен рынку реализации под урожай 19го года. По сравнению с сортом Урало-Сибирский имеет более короткий период вегетации. Вместе с тем обладает более высоким потенциалом урожайности и устойчивости к болезням.

С высокой трибуны хочу передать слова благодарности от татар, проживающих в Зауралье Вам, Рустам Нургалиевич, за оказанную помощь в сумме 5 миллионов рублей на ремонт областного культурного центра татар. Ремонт будет завершен к 1 июля. Кроме того, вами был нам подарен автобус, он нам очень был нужен. В декабре у нас успешно прошли Дни татарского просвещения. И к нам приезжала делегация во главе с Вице-премьером, министром образования.

Летом 14 июля при поддержке Президента Татарстана Минниханова Рустама Нургалиевича и губернатора Курганской области будет проходить Всероссийский сельский Сабантуй. И для проведения этого праздника из бюджета Курганской области на благоустройство райцентра и праздничной площадки выделено 44 миллиона рублей. Чакырганыгыз өчен рәхмәт! Сау булыгыз!

**Рөстәм Миңнеханов**: Рәхмәт! Яхшы итеп Сабантуйны әзерләгез. Как работает на земле, чтобы так и Сабантуй хороший был.

**Марат Исламов:** Мы постараемся, Рустам Нургалиевич! Действительно, для Курганской области большая честь и огромная ответственность. Спасибо вам за это.

**Рөстәм Миңнеханов:** У вас губернатор большой молодец. Он очень заинтересован. Поэтому ваша поддержка нужна. Рәхмәт сезгә!

**Васил Шәйхразиев:** Рәхмәт! Татарстан Республикасы Әгерҗе районы крестьян фермер хуҗалыгы башлыгы **Сәхипов Илшат Малик** улы залда утыручыларга яхшы таныш. Безнең алдагы җыеннарда катнашып, үзенең эшчәнлеген җәелдергән эшмәкәр ул. Бүген ул үзенең эшчәнлеге белән таныштырып китәчәк. Аның темасы **“Әгерҗе районының Ямурза авылы мисалында татар авылын саклап калу чаралары”.** Сүз аңа. Рәхим итегез!

**Илшат Сәхипов**: Хөрмәтле Рөстәм Нургалиевич, Марат Готович, килгән кунаклар! Барчагызга да Аллаһы Тәгаләнең сәламе, рәхмәте һәм бәрәкәте булсын. Мин мондый җыенга инде 5нче тапкыр килүем. Беренче тапкыр чыгыш ясадым 14нче елда, үзебезнең эшләгән эшләребез турында сөйләдем, авылны саклау буенча нинди чаралар күрүебез турында сөйләдем.

Без Әгерҗе районы Ямурза авылында бер олы семья булып яшибез. Ике малай, бер кыз үстердек. Алар тормышка чыктылар, тормыш кордылар. Авылда бергә яшибез. Бүгенге көндә 9 онык үстерәбез. Аллабирса, әле бу соңгы сан булмас. Аллаһы Тәгалә сәламәтлек бирсен аларга һәм балалар бәхете бирсен. Бер елны кызым кияүгә чыккач, кызымнан интервью алырга килгәннәр иде. “Ничә бала алып кайтырга җыенасыз?”, -дигәч, кияү уйлап та тормады, - җидене”, -диде. Кыздан сорадылар, кыз риза диде. Нишләп 7 санын әйттегез дигәч, минем әтиемнәр җидәү булган диде.

Менә шушы фикердә яшәп, авылыбызда эш оештырабыз. Иң беренче без Шыгырдан, Урмай, Тукай авылларына барып кайттык. Халыкның бик нык диндә икәнен күреп кайтып, иң беренче фикер чыкты минем олы улым Ильнурдан. Ул башлап йөрүчеләрдән булды. Шулай итеп авылны дингә чакырып, дингә тартып, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешергә тырышып, эшебезне дәвам итә башладык.

Сөйләдем инде беренче чыгышымда авылның мәктәбен ремонтлап чыктык дип, садик ачтык, мәдрәсә төзедек, мәчетне ремонтладык дип. Алга таба без халык өчен тагын нинди файда китерә алабыз дигән фикерләр белән йөри башладык. Әйбәт фикерләр Аллаһы Тәгаләдән, начарлары шайтаннан килә диелә. Менә шушы яхшы фикерләребезне туплап, җыелышып, киңәшләшеп, тагын бер чара уздырырга уйладык. Авылыбызда мөселман садигы ачып җибәрдек. Ул быел беренче ел гына эшли.

Монда безнең укытучыларыбыз бар, педагогия белемле хатын-кыз, намаздагы хатын-кыз. Шулай ук тәрбиячеләр бар, ашатучылар бар, гыйлем бирүчеләр бар. Бүгенге көндә авылыбызда, Аллага шөкер, гарәпчә сөйләшә белә торган, любой гарәп белән фикер уртаклаша торган укымышлы

хәзрәтебез бар. Тагын бер хәзрәтебез бар, аның җәмәгате бар. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән, авылда мондый мохтаҗлык юк.

Безнең төп таләбебез – балаларга әдәп, әхлак дәресләре бирү, кешеләр белән аралашу, олыларны хөрмәт итү. Алар берсеннән берсе ярыша-ярыша Коръән сүрәләре ятлыйлар. Минем 6 яшьлек оныгым 30 сүрәне яттан белә хәзер. Әле мин намаз укып, бер 8-9ны гына беләм. Бер көнне ушны алды. Әбисе бабаңа Коръән укып күрсәт әле дигәч, Коръән китабын ачты да уртасыннан, гарәп акценты белән чиста итеп Коръән укый. Олы оныгыбыз хәзер Коръән ятлый. Без уйлыйбыз, безнең эшләребездән Аллаһы Тәгалә разый булыр микән дип.

Безнең авылыбызга кергән чагында олы плакатка язылган Аллаһның Коръәндәге сүзләре язылып тора. Анда бик матур һәм аңлаешлы итеп әйтелгән: “Авылларда, шәһәрләрдә яшәүчеләр иман китерсәләр, тәкъва булсалар, без күкләрдә һәм җирдән бәрәкәт ишекләрен ачарбыз”, - дип әйткән Аллаһы Тәгалә.

Безнең авылда соңгы елларда башлангыч мәктәптә ике класска бер укучы или бөтен мәктәпкә 1-2 укучы була торган чаклары бар иде. Бүгенгесе көндә Аллага шөкер, башлангыч мәктәбебездә 10 бала укый. Мәктәпкәчә хәтле яшьтә авылыбызда 30 бала бар. Безнең авылыбызга да Аллаһның бәрәкәте иңә башлады дип сөенәбез. Авылыбызның киләчәге бар. Без шул киләчәкне күз алдына китереп, сөенеп, Аллаһы Тәгаләгә шөкерләр әйтеп, эшләребезне алып барабыз.

Бер шундый хәл булды. Минем оныгым, ул чагында 2нче класста укый иде, мин бер басуда туры килеп, агрофирма басуыннан кузаклы борчак җыеп алып кайттым да, өстәлгә бушаттым, әбисенә әйттем: “Оныклар килсә, ашатырсың”, - дидем. Килгән Фәрхать, әбисе борчак белнә сыйламакчы булган. Онык алган да бер кузакны, ачкан да, сорый башлаган: “Бабай кайдан җыйган моны?”, - әбисе әйткән: “Басудан”. “Басуның хуҗасыннан рөхсәт сорап җыйганмы бу борчакны?”, - дип сораган. Әбисе аптыраганнан әйткән инде: “Басуда булгач, сорап тора алмагандыр инде”, - дигән. Ачкан борчагын

да ашамыйча куеп, әби, бу миңа хәрәм, мин хәрәм ашамыйм дип чыгып киткән.

Менә без олы яшьтәге кешеләр аны бик уйлап та бетермәдек. Бала-чага бәләкәй чагында ничек тиз әләктерә, нәрсә эшләргә ярый, нәрсә эшләргә ярамый икәнен. Ул аны үлгәнче онытмый, хәтерендә кала ул. Мин дә әнинең өйрәткән аятьләрен, сүрәләрен хәзер дә хәтерлимен. Аллага шөкер, безнең авылыбызга хәзер инде күченеп кайта башладылар яшь гаиләләр. Безнең авылыбзыда балаларга тәкъвалык буенча, әдәп, әхлак буенча дөрес итеп тәрбия бирү мөмкинчелеге бар дип, гаиләләр күченеп буш өйләрне ала башладылар. Бер урыс гаиләсе күченеп кайткан безнең авылга. Сорыйлар икән алардан, авыл кешесе кызыксынучан бит инде. “Сез, урыс кешеләре, нишләп татар авылын сайладыгыз? - дигәч, - алар матур итеп аңлатып әйткәннәр, - сезнең авылыгызда 5 вакыт азан әйтелеп, мәчетегездә намаз укыла, сездә иманлы халык яши, шуның өчен кайттык”, -дигәннәр.

Безнең икенче тармак, игенчелек, терлекчелек. Бүгенге көндә безнең 350 баш терлегебез бар. 1 мең гектар җир эшкәртәбез, 100 баш савым сыерыбыз бар, 70 баш калмык сыерыбыз бар. Басуларда игеннәр, ашлыклар үстереп, печәннәр үстереп, авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнәбез.

1870-1919нчы елларда бу авылда 700 хуҗалык булган һәм 3811 кеше яшәгән. Бер гасыр чорда авыл бетте. Узган ел, өченче елда шушы авылда бер бала да тумады. Без ул авылда шулай ук шөгыльләнергә уйлыйбыз, Аллабирса, Ходай насыйп итсә. Хәзерге вакытта безнең хәзрәтләребез анда атнага бер барып кайталар. Менә шушы авылны әзрәк кенә иманга чакырып, тәкъвалыкка чакырып, дөрес юлга бастырып, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирешеп, авылыбызны саклап калырга тырышабыз.

Форсаттан файдаланып, Рөстәм Нургалиевич, минем бер соравым бар. Бу авылга әзрәк кенә этәргеч булыр иде. Арендная программа дигән программа бар икән өйләр төзү буенча. Шуның буенча безгә әзрәк ярдәм итәлсәгез, бик рәхмәтле булыр идек без. Калган эшләребезне үзебез эшләп,

ярдәм итеп авылга, бу авылна да саклап калуга бик зур өлешләр кертеп, яшәр идек.

Менә шушы чыгышымнан, тагын минем мөрәҗәгать итәсем килә. Минем алда чыгыш ясаган ханым да бик матур итеп сөйләде. Менә эшмәкәрлек – ул бит Аллаһтан килгән сәләт һәрберегезгә. Ул сәләттән дөрес итеп файдаланырга кирәк. Бар зәкать дигән нәрсә. Ул ислам диненең бер баганасы. Гыйлемлеләр гыйлемнәрен таратмасалар, байлар зәкатьләрен мохтаҗларга бирмәсәләр, бу авыл, бу өлкә, бу төбәк бетүгә таба бара дигән. Менә шуңа күрә һәр эшмәкәрнең үз туган авылы бар, үзегезнең зәкатегез хисабыннан шушындый эшләр эшләп, булышсагыз, эшләмәгән мәчетләрегез эшләп китсә, Аллаһы тәгалә бу авылга бәрәкәт ишекләрен ачар иде. Алланың рәхмәте белән авылларыбыз торгызылыр иде. Бүтәннәргә үрнәк булсын диеп, сез дә булдырганча шундый эшләрне эшләсәгез, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешеп, эшләрегезгә уңышлар насыйп итсә иде Аллаһы Тәгалә.

**Рөстәм Миңнеханов:** Рәхмәт! Бу сез әйткән авылның исеме ничек?

**Илшат Сәхипов**: Салагош.

**Рөстәм Миңнеханов:** Без ул авыл турында өйрәнербез. Яхшы, кызыксынырбыз.

**Васил Шәйхразиев:** Бик зур рәхмәт, Илшат әфәнде! Хөрмәтле милләттәшләр, менә безнең 10 җитәкче шундый киң итеп, чыгышларын ясадылар. Президентыбыз Рөстәм Нургалиевич әйтте, регламент буенча, ләкин чыгышлары шундый тирән, мәгънәле булгачтын, мин рәис буларак, вакытны бик кысмадым. Әгәр дә мөмкин дип тапсагыз, без хәзер туктар идек. Безнең Президентыбызның әле бүтән совещанияләре бар. Шуңа күрә хәзер сүзне Татарстан Республикасы Президенты **Рөстәм Нургали улы Миңнехановка** бирәбез. Рәхим итегез, Рөстәм Нургалиевич!

**Рөстәм Миңнехановның сәламләү сүзе:** Барыгызга да хәерле көн! Бик зур рәхмәт! Менә шулай җыелырга мөмкинлегебез бар. Әлбәттә, һәммәгезнең ниндидер тарихы бар, ниндидер тәҗрибәсе бар. Бер-берегез белән аралашасыз, безнең өчен дә бик мөһим сезнең белән сөйләшү. Нинди

мәсьәләлә борчый, ничек итеп ул мәсьәләләрне хәл итеп була. һәрбер чыгышның эчтәлеге бик зур. Мин уйлыйм, берничә чыгыш әле калды. Аларның ничек тә чыгышларын алып, туплап, ниндидер бер фикергә килергә кирәк була.

Менә монда җитештергән товарларыгызны китердегез, күрсәттегез. Быел без хәләл тормышы турында “Казань-Саммит” үткәрәбез. Бу ризык кына түгел, бу косметика да, укыту да, бу здравоохранение дә. Шуңа күрә менә монда күп кенә әйберләрне күрдек без. Аны безгә Рәсәй күләмендә генә түгел, чит илгә дә чыгару өстендә эшләргә кирәк. Менә безнең Сабадагы коллегалар сөйләделәр. Интернет-торговля дигән әйбер бар. Хәзер Америкада меңләгән кибетләр ябыла, чөнки интернет-торговляга күчеп бара. Шушы юнәлешне алсак, без үзебезнең продукция белән күп илләргә чыга алабыз.

Бу чыгышларның күбесе милләт турында, авыл турында, тел турында, дин турында. Әлбәттә, сез һәммәгез дә тормышта үзегезгә үзегез күрсәткән кешеләр. Үзегезнең өлкәләрегездә, авылларыгызда танылган кешеләр. Минем әйтәсе килгән сүзем шул. Безнең барыбызны да милләтнең киләчәге борчый. Нишләрбез без, нәрсә булыр безнең белән. Татар милләте өчен генә түгел, һәр милләт өчен дә авыл нигез булып тора. Безнең Республикада күп кенә программалар бар. 37 программа былтыр булды, быел 38 программа. Күбесе аның авыл халкына, авыл кешесенә дип эшләнә торган программалар.

Әлбәттә, без аны хөкүмәт хисабына гына эшли алмыйбыз. Монда эшмәкәрләр дә кирәк, төрле формаларын да табарга кирәк. Менә бу самообложение дигән нәрсә, 1 сумга 4 сум бирү формалары да. Бүтән өлкәләрдә нинди юллары бар, аны эзләргә кирәк. Беренче чиратта, ничек авылны саклау. Икенче чиратта, ул авылларда әгәр дә сезнең кебек эшмәкәрләр булмаса, ул авылның киләчәге һәм тормышы юк.

Телебезне саклау өчен без үзебезнең телебез белән үзебез кулланырга тиеш. Менә бүген күп кенә чыгышлар татарча булды. Бик зур рәхмәт! Васил Гаязович бераз ялгышыбрак әйтте, сукалау түгел. Кемнең нинди мөмкинлеге

бар, ул татар телендә чыгыш ясады. Аннан оялырга ярамый. Безгә һәммәбезгә дә тырышырга кирәк өйрәнергә шушы юлны үтәргә. Кыска гына булса да, әгәр чыгышлар татарча булса, бик әйбәт була инде.

Сез бит безнең үрнәк. Татар халкының булган егетләре. Сезгә карап бүтәннәр дә үзгәрәчәк. Әгәр дә без үзебезгә үзебезнең телебезне кирәк дип таба алмасак, кемгә кирәк ул. Шуңа күрә беренче чиратта үзебезгә кирәк. Разил Валиевка барыбер сөйләп булмый. Үзең булдырганча, матур итеп, үзеңнең фикереңне әйтә алсаң, бик әйбәт. Кайсыдыр сүзләрне белмәсәң, урысча әйтсәң дә, барыбер русча аңлыйбыз. Теләгебез булырга тиеш.

Авыл тормышы, авылда яши торган кешенең тормышы бөтенләй икенче. Андагы гаиләләр икенче. Балалар эшне яратып үсә, эш күреп үсәләр. Сезнең кебек үрнәк кешеләрне безгә күрсәтергә кирәк. Беренче чиратта, татар авыллары турында программа-передачалар булырга тиеш. Монда ТНВ гына түгел, безнең ГТРК да бар Татарстан эчендә.

Икенчедән, бөтен җирдә дә мәктәпләр юк. Мәктәп булса да, менә бу татар теле өйрәтү мәсьәләсендә без бөтен өлкәләр белән эшләргә риза, ләкин анда укытучылар кирәк. безгә укытучылар әзерләргә кирәк. Әгәр дә сез безгә Татарстанга педучилищеларга үзегезнең кешеләрегезне җибәрсәгез, без аларны кабул итәрбез һәм укыту процессларына ярдәм итәчәкбез. Анда бит кеше җибәрә алмыйбыз. Шуңа күрә үзегезгә карарга кирәк.

Ничек итеп шушы татарлар яши торган авылларда, җирлекләрдә тел өйрәнү мәсьәләсен хәл итү. Аны бергәләп без оештыра алабыз. Иң уңае – безнең мәчетләребез. Татар имамнары булган мәчеттә, безгә менә шул мәсьәләне оештырырга кирәк. Шуңа күрә мәчет – ул безнең дин генә түгел, әле ул безнең гореф-гадәтләрне һәм башка мәсьәләләрне хәл итә торган урын. Шуңа күрә бу әйбергә игъитбар бирергә кирәк.

Барсын да эшләргә була, ләкин акчасыз эшләп булмый. Әгәр дә сезнең бизнесыгыз әйбәт барса, әгәр дә табышыгыз булса, әгәр дә зәкатьне вакытында тапшырсагыз һәм дөрес юлда кулланылса ул, әлбәттә, без күп кенә эшләр эшли алабыз.

Менә безнең мондый җыелу формасы ул бик яхшы. Әгәр дә без менә бу сөйләшүләрне бер русча әйтмешли итоговый документ, резолюциягә чыгарабыз. Менә үзебезнең вице-премьер дәрәҗәсе булсын өчен кайсыдер өлкәләргә барганда безнең Татарстанның вәкиле. Конгресс татар – Ринат Закиров, ә инде хөкүмәт тарафыннан Шәйхразиев.

Шуңа күрә без бө мәсьәләләрне аңлыйбыз. Кайбер чакта безнең яктан да ниндидер этәргеч кирәк. Шуңа күрә без бу мәсьәләгә игътибар бирәбез. Әлбәттә, без ул мәсьәләне сездән башка хәл итә алмыйбыз. Без сезгә нигезләнәбез. Менә сез үзегезнең тамагыгызны гына түгел, сез анда күп кешеләргә эш урыны да оештырасыз, налог та түлисез, мәчеткә дә ярдәм итәсез, авылга да ярдәм итәсез. Шуңа күрә сезгә таянып, киләчәктә дә шулай җыелып, ничектер Татарстанда да бюрократия бар икән, сезнең ниндидер мәсьәләгез бар икән, сезгә ярдәм күрсәтеп, менә бу укыту мәсьәләләре, дин әһелләрен әзерләү мәсьәләләрендә без ярдәмне күрсәтәчәкбез.

Барыгызга да эшегездә уңышлар! Матур итеп балалар үстерегез. Иң мөһиме, безнең Татарстан артырга тиеш. Шуңа күрә һәммәгез дә бу мәсьәләгә зур игътибар бирегез. Күп балалар булсын, бәхетле булсыннар. Шуңа күрә демография мәсьәләсенә дә игътибар бирергә кирәк.

Тагын бер әйтәсе сүзем бар. Менә тормышта иң мөһиме тынычлык. Әгәр дә тынычлык була икән, бизнес та була, балаларны да үстереп була, бүтән мәсьәләләрне дә планлаштырып була. 18 се сайлау көне. Шуңа күрә бу сайлауларны матур итеп үткәрергә кирәк. Россия дөнья күләмендә үзенең сүзен әйтергә тырыша. Әлбәттә, ул күп кешеләргә, күп илләргә ошамый. Менә ахыргы Президентның чыгышын тыңласагыз, ул аны җепләп-җепләп сөйләп бирде.

Россия көчле булырга тиеш. Россия эшенә бер кеше дә тыгылырга тиеш түгел. Шуңа күрә көчле лидер кирәк. 18 көнне без дөрес итеп сайлауларны үткәрергә тиешбез. Мин сезгә мөрәҗәгать итәм. Минтимер Шәриповичнең әйткән сүзләрен ишеткәнсездер инде. Ул безнең иң аксакал абзыебыз. Шуңа күрә сезгә дә мөрәҗәгатем шул.

Сезгә һәммәгезгә дә зур рәхмәт! Уңышлар! Килгәнегез өчен, күрсәткән хезмәтегез өчен, тырышлыгыгыз өчен сезгә рәхмәт.

**Васил Шәйхразиев**: Бик зур рәхмәт, мөхтәрәм Рөстәм Нургалиевич! Илебезнең төрле төбәкләрендә яшәп, халкыбыз мәнфәгатьләре өчен күп хезмәт куйган, авыл хуҗалыгын үстерүдә һәм эшмәкәрлек өлкәсендә зур нәтиҗәләргә ирешкән милләттәшләребезгә **Татарстан Республикасының бүләкләре тапшырыла.**

*(Президентның бүләкләү турындагы фәрманын Данис Шакиров укый)*

**Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә**

1. Республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Әлки муниципаль районы Түбән Әлки авылының шәхси эшмәкәре Шәйхетдинов Альберт Әсгать улына Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале тапшырыла.
2. Авыл хуҗалыгын үстерүдәге казанышлары һәм намуслы хезмәте өчен «Татарстан Республикасының Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» **дигән мактаулы исем** Әлки муниципаль районы Түбән Әлки авылының шәхси эшмәкәре Шәйхетдинов Дамир Әсгать улына бирелә.

**Татарстан Республикасы Президенты Боерыгы нигезендә**

1. Татар милли мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә зур өлеш кертүләре өчен шәхси эшкуар, «Киров өлкәсе төбәк татар милли-мәдәни мохтарияте» иҗтимагый оешмасы әгъзасы Әсхәтҗанов Ренат Рәшит улына Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте белдерелә.
2. «Уралагротехсервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры, «Башкортостан Республикасы татар конгрессы» төбәк иҗтимагый оешмасы әгъзасы Зарипов Рәсим Миңнефәрит улы

бүләкләнә.

3. «Курган өлкәсе татар конгрессы» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе урынбасары, шәхси эшмәкәр Морадыймов Газинур Гомәр улы бүләкләнә.
4. «Загот-Сервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры, «Башкортостан Республикасы татар конгрессы» төбәк иҗтимагый оешмасы әгъзасы Нәфиков Вилсур Марат улы бүләкләнә.
5. Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, татар халкының рухи-әхлакый һәм мәдәни традицияләрен саклап калуга һәм үстерүгә зур өлеш кертүе өчен Бөтендөнья татар конгрессының Республика иҗтимагый фонды директоры Зиннәтова Сәрия Фәйзелхак кызына Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерелә.

Бүләкләнүчеләрне тагын бер алкышлыйк. Котлыйбыз!

**Рөстәм Миңнеханов:** Әлбәттә, бу бүләкләр һәммәгезгә дә тиеш. Чират кына җитмәгән. Монда язучы Шәйхразиев. Шуңа күрә күпме язып бирделәр, шуның хәтле кул куйдым. Барыгызга да уңышлар! Рәхмәт сезгә!

**Васил Шәйхразиев:** Бик зур рәхмәт, мөхтәрәм Рөстәм Нургалиевич! Хөрмәтле коллегалар! VII Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләре җыенын тәмамлыйбыз. Чыгышларда күтәрелгән мәсьәләләр буенча сезнең игътибарыгызга резолюция проектын тәкъдим итәм. Безнең теләкләр буенча, Рөстәм Нургалиевич күп кенә фикерләр әйтте. Шуларны без язып, кабул итәрбез. Бүтән фикерләр юкмы? Шушы резолюцияне, каршылар булмаса, кул күтәреп раславыгызны сорыйбыз. Кемнәр резолюцияне кабул итә кулларыгызны күтәрегез.

*(Резолюция укыла)*

Төшерегез.

Каршылар? Юк.

Битарафлар? Юк.

Бердәм кабул ителде. Рәхмәт!

## - РЕЗОЛЮЦИЯ КАБУЛ ИТЕЛӘ

**Васил Шәйхразиев:** Кадерле милләттәшләр! Без икенче елга март аенда шушы сан белән барыбыз да җыелырбыз. Темалар бар, практикалар бар. Яңа гына безнең Президентыбыз Рөстәм Нургалиевич 18 март турында әйтте. Әйтәсем килә, безнең Рөстәм Нургалиевич ул Татарстан Президенты гына түгел, ул бөтен татарларның Президенты. Аның Указы буенча без күп кенә өлкәләрдә булдык, татар автономияләре җитәкчеләре белән очраштык.

Әйтәсем килә, Рөстәм Нургалиевич, бөтен җирдә дә аңлау бар. Рәсәй буенча 5 миллион татар халкы яши. Шуңа күрә 18 март көнне үзебез гаиләләребез, дусларыбыз, күршеләребез белән барып, матур итеп сайларга тиешбез. Без аны Милли Шура Президиумында да кабул иттек. Барыбызга да тынычлык кирәк, барыбызга да өмет кирәк.

Тагын бер кат бик зур рәхмәт! Иң зур рәхмәтебезне әйтәсем килә үзебезнең Президентыбызга Рөстәм Нургалиевичка. 2 сәгатьтән артык монда булып, шушындый матур сүзләр әйткәнегез өчен һәм безнең белән һәрвакытта да булганыгыз өчен. Бик зур рәхмәт!

**Рөстәм Миңнеханов:** Андый-мондый татар канлы булган дусларыгыз, иптәшләрегез булса, аларга да әйтегез безнең сүзләребезне.

**Васил Шәйхразиев:** Бик зур рәхмәт! Шуның белән Пленар утырышны тәмамлыйбыз.

“Крестьян фермер хуҗалыклары”

дискуссион мәйданчыгы

*1 март, 2018 ел* *IT-парк, Петербург ур. 52*

**Модератор:** Байтемиров Камияр Миҗагит улы - Татарстан фермерлары һәм крестьян хуҗалыклары ассоциациясе рәисе.

*Видеоряд.*

**Камияр Байтемиров:** Менә шулай яшибез әкрен генә. Анекдот белән әйткәндә, бер эшмәкәрдән сорыйлар икән: “Ничек син торасың, ничек яшисең?”, -дип. Ул әйтә ди: “Абхазиядән 3 сумга мандарин алам да, 5 сумга сатам, - ди. – Шулай 2% кайта”, - ди. Бездә шулай торабызмы? Бер-беребезнең уйларын тыңлыйбызмы?

Биредә Сведловск өлкәсеннән Бархаева Фидания Шәйхулла кызы утыра. Рәхим итегез.

**Фидания Бархаева**: Хәерле көн, мөхтәрәм милләттәшләр! Мин Свердловск өлкәсе Әртә районы Әртә Шигер авылыннан Бархаева Фидания Шәйхулла кызы булам. Яшь, энергияле чак. Үз эшебезне куанып, яратып, рәхәтләнеп эшкә тотындык. Россиядә булган хәлләр, проблемалар безне дә урап узмый. Совхоз бетә, эш бетә. Көннәрдә бер көн авыл халкын шаккатырып, совхоздан барлык малны техникага төяп авылдан алып чыгып киттеләр. Кая барырга? Әле һәркемнең балалары бар. Кайсы мәктәптә укый, кайсы балалар бакчасына йөри. Һәркемнең үз хәле хәл.

Халык эш эзләп шәһәргә агыла. Анда урнашып эшли башлыйлар. Анда колач җәеп көтеп тормыйлар. Яшәү җирен, балаларны укыту эшен җайларга кирәк. Шәһәр бит барсын да сыйдыра алмый. Әле ата-аналарны да булышчысыз калдырасы килми. Шуларны уртага салып уйлаша торгач, без авылда туып үскән авыл балаларының шәһәргә китәсе килмәде. Өч бертуган шундый фикергә килделәр – үзебезгә тырышырга кирәк.

Совхоздан калган җир пайларын үз исемнәренә күчереп куйдылар. Авылдашлардан, туганнардан җыеп алып, җир мәйданнарын арттырдылар. Җир алу – ул эшнең башы гына. Аны бит эшкәртәсе, эшкәртү өчен техникасын да булдырасы бар.

3 гаилә бергә тотынгач була икән. Бар булганын бергә салып, булмаганын җыеп, техника алдылар, тотылган техникаларны җайга салдылар. Алган белемнәре менә шунда ярады да инде. Шулай итеп Бархаевлар 3 туган бергә җиң сызганып эшли башладылар. Белгәнегезчә, авыл хуҗалыгы ул бит лоторея билеты сыман. Йә отасың, йә отыласың. Быел уңыш алсаң, икенче елга кереме чыгымыннан күп тапкыр аз, яки булмавы да мөмкин.

Шулай итеп 3 туган төрле юнәлештә эшли башлады: мал асрау, үлән үстерү, бәрәңге утырту. Моның белән генә эш бетми бит әле. Алган продукцияне каядыр итәргә дә кирәк. Сатып-алучылар табарга кирәк. Интернет челтәре аша газетага белдерүләр язып, аларын да таптык. Ит һәм бәрәңгене шәһәрдән килеп алалар. Аның проблемалары да туа бара. Ел саен солярка хакы да арта бара, техника хакы. Иске техникага запчастьләр дә кыйммәтләнә. Ләкин тапкан клиентларны, сатып-алучыларны югалтасы килми.

Хәрәкәттә бәрәкәт дип, тагын бер һөнәр уйлап таптык. Ир-егетләр үзләре утын яргыч эзләп табып, аны җыештырып, утын яру белән шөгыльләнә башладылар. Авылда эш булгач, халык кире кайтып, авылга эшкә урнашалар. Яшьләр яңа йортлар төзеп, йортларга эссе һәм суык сулар да кертелгән, ванналары да бар. Авылдагы йортларда да шәһәрдәге сыман яшәргә була.

Авылыбыз зурая, матурая. Күбесе хәзер маллар да асрый башлады. 2009-2011 елларда авыл халкы мал карарга омтылмый иде. Соңгы елларда мал асрарга уйлаган халык сизелерлек күтәрелде. Халык саны арта бара. Авылда мәктәбебез дә, балалар бакчасы да бар. Бүгенге көндәшундый авыр

заманага карамастан, мәктәптә 3 сәгать татар теленә бирелде. Туган телебезне саклап кала алдык. Шуңа без бик шатбыз.

Үзебезнең өлкәдән, күрше өлкәдән туристлар кабул итәбез. Аларны үзебезнең авыл тарихи, милли йолаларыбыз белән таныштырабыз. Татар халык ашларыннан авыз иттерәбез. Әби-бабайларыбызның гореф-гадәтләрен саклау өстендә эшлибез. Язгы җир эшләре беткәч, һәр елны авылыбзыда сагынып һәм котлы булуын теләп алынган иң хөрмәтле бәйрәм-туй – Сабан туе уздырыла. Сабантуйга мәйданны, спорт җиһазларын эшләү шушы егетләр җилкәсенә төшә.

Авылда 2005 нче елда Мәдәният йорты янды. Күп кенә бәйрәмнәр мәктәп бинасында үткәрелә. Яңа ел бәйрәмен үз капка алдында уздырабыз. Зур чыршы агачын китереп утыртып, аңа зур гирляндалар элеп, халык күңелен күреп, чыршы бәйрәмен дә уздырабыз. Авылга кечкенә булса да бәйрәм кәефен кертергә тырышабыз.

Һәр көнне безне эшкә өндәп, күңелләрне тетрәндереп, мәчет манарасыннан азан әйтелә. Җомга көннәрне әби-бабайларыбыз, яшьләр дә үз теләкләре белән мәчеткә йөриләр. Дини бәйрәмнәр уздырыла: балага исем кушу, яшь гаиләләргә никах укыла. Алдагы көндә дә авылыбыз гөрләп торыр дип ышанабыз. Мондый егетләр булганда эш тә алга барыр, авыл да яшәр, мәктәп тә булыр. Мәктәп булса, үз тедебезне дә саклый алырбыз. Балаларыбыз чын татар телендә сөйләшә алырлар. Бөек татар шагыйрьләре Тукаебыз, Җәлилебез шигырьләрен чын татар телендә укырлар. Милли бәйрәмнәр дә үткәрелер. Менә шушындый теләкләр белән үз авылыбызда яшибез. Рәхмәт!

**Камияр Байтемиров:** Зур рәхмәт! Башкортстан Республикасы, **Әминов Рәфис Фәрит** улы мондамы? Рәхим итегез! Әйдәгез, тыңлап алыйк әле күршеләрне.

**Рәфис Әминов**: Исәнмесез, кадерле милләттәшләр! Башкортстан Республикасы Әлшәй районында 10 яшьтән эшли башладым колхозда, то

силоста, то тракторда эшләтәләр иде мине. Шулай итеп мин колхозда эшләгән кеше.

Мәктәпне бетергәч, нефтяной институтка поступать иттем. Аны бетереп, 15 ел нефть өлкәсендә эшләдем. Аннан инженер булып эшләдем, начальник базы булып эшләдем. Аннан соң 18 ел буе газопроводлар буенча Уренгойда начальник участка булып эшләдем. 10 ел Бүрзән, Билярск районнарында газопровод үткәрдем.

Пенсиягә чыкка нәрсә эшләргә? Ял итәргә привычка юк, берәр эш табарга кирәк иде. Башта 2 ат алдым. Аннары күбәйтә башладым. Икенче елны 10 баш булып китте. 2006 нчы елны минем 49 баш булган иде инде. Шул атлардан кымыз ясыйбыз бит инде. Атлар тоту, кымызны ясау бик җиңел эш түгел, әлбәттә. Безнең Әлшәй районында кымыз ясый башлагач, ул вакытта  кымызның 1 литры тора иде 30-40 сум.  Көненә 200 литр кымыз ясый идек.

Без кымызны ел буе эшлибез. Безнең бияләр май аена хәтле саудыра. Шуңа без кымыз эшләүне туктатмыйбыз. Менә инде 13 ел аны туктаткан булмады. Сөт күп булса, без аны Юматау санаториясенә илтәбез. Анда аңардан порошок эшлиләр. Мин порошоктан кумыз эшләмәдем беркайчан да. Ничектер мин бу порошокка каршы булдым үзем. Бия сөте бик кирәкле азык. Ул бүтән малларның сөтенә караганда файдалырак.

Ат сөтендә белок һәм май әз, сыерныкына караганда. Витамин С берничә мәртәбә күбрәк. Бүтән сөтләр белән чагыштырсаң, ат сөте ана сөтенә якынрак. Белок 2%, аксым инде, мае – 1,2-2,8% почти ана сөте кебек. Һод саны 101. Ат сөте балаларны кирәкле сөт. Витамин С бик файдалы туберкулездан файдаланырга.

Ат сөте белән дәвалану турында изге Коръәндә дә язылган. Безнең эрага хәтле греция галимнәре кымызның файдасы турында язганнар һәм бүтән дарулар алдында беренче урында торган. Европа илләрендә дә ат сөте белән дәвалануны кулланалар. Бөтен Россия белән чагыштырганда безнең Башкортстанда кымызның 80% әзерләнә. Бигрәк тә безнең Әлшәй

районында. Бездә курорт Шафраново, элек курорт дип атала иде. Хәзер санаторий Шафраново. Санаторий Чехова һ.б. - барсы да туберкулезга каршы санаторийлар.

Атларның саны безнең Әлшәй районында 2016 елда 2680 баш иде. 2017 елда 3091 баш. 148% ка үсте. Ә кымыз 2016 елда безнең Әлшәй районында 3255 центнер иде, ә 2017 елда 3631 центнер. Кымыз – ул бия сөтен әчетеп әзерләгән, күбелеп торган ак төстәге эчемлек.

Россиядә кымыз белән дәвалау санаториясе "Шафран" санаториясе баарлыкка килгән 1890нчы елларда. Аксаковның баласының баласы аны төзегән. 1892нче елда Шафран тимер юлы тирәсендә корпуслар төзелә, кымыз белән дәвалану көчәя. Дөресен әйткәндә, бүтән җирдә кымыз эшләү безнең Башкортстандагы кебек, безнең Әлшәй районындагы кебек тәмле булып чыкмый. Бигрәк тә тәмлелеген көчәйтә безнең тау битендә үскән кыр үләне.

Кымызны төрле савытта эшләргә була. Бигрәк тә әйбәт килеп чыга юкәдән эшләнгән гөбедә. Пыяла банкада да эшләргә була, кавырсын савытта да була. Без бияләрне 3 сәгать саен савабыз. Кымызны әчеткесенә кушып болгыйбыз. Бу эшне эшләгәндә нык чисталык кирәк. Савытлар, гөбеләр, таяклар һәрвакыт чистартып, юып торырга кирәк. Кәгазьләрне, лабораторный анализларны алып барырга кирәк.

Гөбедә кымызны бутагач, бутылкаларга салу алдыннан 1 сәгать кала гөбедә. Ул күпереп торырга тиеш. Сөт белән кымызның эчеткесе 26-28 градуста булырга тиеш. Бутылкаларга салганнан соң суыткычларга куела, температура анда булырга тиеш 2-4 градус. 20 сәгатьтән соң аны эчәргә мөмкин. 5 көннән соң кымыз үзгәрә башлый.

Аның спирт өлеше йомшакларда була инде, 1 доля, уртача – 1,5 доля, көчлесе спиртосодержание була 3 доля. Кислотность 80, 100, 120. Бия сөтен, кымызын нык җылытырга ярамый. Уфа-Чишмә-Кыргыз-Миякә юлында бар безнең кымыз кибете. Шул кибет аша үткән кешеләрне без ашатабыз.

Кымыздан башка без буза ясыйбыз. Буза эшләнә солы оныннан. Хатыным кафеда эшли инде повар булып. Эшне ул алып бара инде. Пиво, вино анда сатмыйбыз. Сәләмәт яшәү рәвешен тотабыз. Татар халкы бит инде үтеп китә, намаз укырга урын кирәк диләр. Шунда кереп намаз укып чыгалар. Тәҗетдин хәзрәт тә кереп чыккан иде, ахуннар кереп чыгалар. Шунда намаз укый торган бер бүлмә эшләп куярга исәбем бар, Аллабирса.

**Камияр Байтемиров:** Рәфис Фәритовичка сорауларыгыз бармы?

**Залдан сорау.**

**Рәфис Әминов**: Срогы аның 5 көн санала. Ләкин мин аны 8-9 көн торганын эчкәнем бар. Менә дигән шулай ук. Ә болай технология белән әйтелгән инде, 5 көн.

Элекке эшләгән кымыздан әчеткене эшлибез инде.

**Камияр Байтемиров:** Бер сорау бирим әле, Рәфис Фәритович, сезгә ничә яшь?

**Рәфис Әминов**: Әтиемне сугыш алдыннан алганнар армиягә учить артиллеристов. Латвия янында Балтийский полк белән ул каршы алган уже сугышны. Бер ай өйрәткән һәм сугыш башланган. Бер айдан соң пленга эләккән. 2 мәртәбә концлагерьдән качып, кыйналган. 3нче мәртәбә качып, американский фермерга очраган. Һәм ул фермер әтине алып киткән Америкага. Алып китеп, ул анда конюх булып эшләгән.

Аннан соң сугыш беткәч, безнең якларга таба кайта башлаган, Әлшәй районына. 1945нче елны кайткан да, 4 ай торган да, үлгән. Шуңардан мин калганмын.

**Камияр Байтемиров:** Сораулар бармы тагын? Юк. Рәхмәт сезгә! Татарстаннан бер егетне-фермерны тыңлыйк әле. **Милаев Шакир Мөхәммәтҗанович** Әлмәт районыннан. Рәхим итегез!

**Шакир Милаев:** Хәерле көн! Мин инде үзем Әлмәт районыннан. Әлмәт районында гомум алганда 122 мең гектар җир санала. Шуның 10 мең гектарын эшкәртәбез. Проблемалар җитәрлек. Ипинең бәяләре төште. Ипине алучы юк. 16нчы ел белән чагыштырганда карабодайга күчте күп фермерлар.

Карабодайны былтыр Бөгелмәгә сдавать иттек 28 сумнан. Былтыр бодай 8 сум булса, быел инде 4 сум. Елыйсылар килә инде мондый бәягә.

Где-то 7 сумнан сатып кала алдык, әзрәк кредитларны капладык. Бүгенге көндә әзрәк арпага спрос китте. Карабода бәяләре 5, 50-6 сумга калды. Безнең районда инвесторлар бик юк. “Союз-агро” гына инде. В основном фермерлар һәм колхозлар инде. Обществолар в основном животноводство.

Минем үзем җитештергән продукция – ул бодай, арпа, карабодай, арыш. Авылларда калдырам үземнең визиткаларымны. Әбиләр чыга, шалтыраталар. “Ларгус” машинасы бар инде безнең грузовой. Әбиләргә сатып кайтам инде 6 сумнан. Шулай итеп ай саен җыелган бурычларны капларга бара.

Бүгенге көндә үзебез үстерәбез, үзебез эзлибез клиент. Мин инде 2001дә башладым фермер булып эшләргә. Ул вакытта бодай тора иде 5 сум килосы 2001-2003дә. Топливо тора иде тоже 5 сум. Расход буенча проблема юк иде. Бүген күреп торасыз, 40 сум. Әйтәләр инде, язга таба 1 долларга җитәргә мөмкин дип. Сәләрнең бәясе арта. Язгы чәчү проблема булып тора инде.

Былтыргы запаслар белән быелгы чәчүне башкарып чыгарга можем. Уборкага хәлләр әйбәтләнмәсә инде, Аллаһ кулында инде. 2 ел подряд шундый булса, чыннан да, авыр була. Тагын нәрсә әйтәсе килә, 5% кредит предлагать итәләр, конечно. Аласы килә. Аның өчен документлар да күп җыярга кирәк. Техникалар җыйган идем, түләп барам анысын. Пока Аллага шөкер.

Бүгенге көнне кредит алырга куркыта. Ни өчен дигәндә, чөнки ипи амбарда шул килеш. Считай, ул кредит бит инде амбарда дигән сүз. Әгәр дә аны 4-5 сумнан сатсаң, бүген кредит алмыйча да язгы чәчүне башкарып чыгарга була. Быел Аллаһы Тәгалә испытание биргәндер инде 2018 гә. Бер ел түзәргә. Бер елдан соң әйбәтләнер дибез. Гел болай бармас. Шуңа күрә бөтенебезгә дә теләк – ипиләрнең бәясе булсын. Әз генә корылык бирсә дә

ярый. 2010гы кебек корылык бирсә, авыл хуҗалыгының әзрәк белерләр иде кадерен. Шуның өчен әз генә корылык та кирәк. Әз дә булмасын, күп тә булмасын, средний булса, безгә җитә шул.

Барыгызга да сәламәтлек. Исән-сау эшләргә язсын. Сәламәт булыйк барыбыз да. Һәм хатын-кызларны киләчәк 8 март бәйрәме белән котлыйм!

**Камияр Байтемиров:** Рәхмәт! Нинди сораулар бар Шакирга? Шакир бәләкәй генә булса да, ул кандидат мастера спортамы или мастер спортамы?

**Шакир Милаев:** Мастер спорта СССР мин по вольной борьбе. Член Сборной СССР идем кайчандыр. 10 ел көрәштем. СССРда 5нче урында калдым, Россиядә 3нче урында калган идем инде. Хәзер 30 ел була инде шушы авыл хуҗалыгында көрәшәм.

**Камияр Байтемиров:** Шуңа күрә, урысча әйткәндә, мал золотник да дорог. Әйдәгез әле, тыңлыйк әле Новосибирск өлкәсеннән Мөхәмәтҗанов Госман Исмәгыйль улын. Рәхим итегез!

**Госман Мөхәмәтҗанов**: Хәерле көн! Мин уже икенче поколениедә сибиряк. Яшьләр китә городка, калып бара картлар. Шулай булса да, безнең авылда мәчет бар. Җомга намазлары укырга анда җыелышалар.

Безнең районда 15 мең ярым кеше яши. Шулар арасында якынча 800 татар кешесе яши. По численности без, татарлар, икенче нация районда. Районыбыз зур түгел. Фермерские хозяйства. Кайсы занимается растениеводством. У кого-то мясное направление. Сөт белән почти никто не занимается. Шул ук проблемалар инде на закупочные цены. Теге елны 24 сум иде, хәзер 18гә төште.

Россиядә 2 беда – урожай һәм неурожай. Үткән елны беда урожай булды бездә. Хәзер яңа губернатор назначили анда. Старается, как можно больше өлкәдән зерно отправить за пределы района. Субсидируется часть стоимости до 40%. Животноводство белән заниматься иткәндә до 50%.

Мин занимаюсь растениеводством. Рискованное земледелие дип әйтсәм дә була. Ограниченность ресурсов тепла. Важно вакытында чәчәргә. Иртә чәчсәң, салкынга эләгергә может. Чөнки ул тиз генә чыга алмый.

Соңрак чәчсәң, уборка усложняется. Шуңа күрә важно подобрать чәчү вакытын. Стараемся применять энергосберегающие технологии. После пара, бер-ике ел можем сөрмәскә, сөрмибез.

**Камияр Байтемиров:** Бер сорау бирим әле. Монда себерне Кытай ала диләр. Дөресме ул юкмы?

**Госман Мөхәмәтҗанов:** Кытай пока безгә җитмәде. Но в основном уңе алып бара диләр. Үзләре килмиләр әле, ләкин агач бездән алалар. Дальний Востокта уже басып баралар.

**Камияр Байтемиров:** Ярар, рәхмәт! Сораулар тагын бармы? Юк. Рәхмәт! Башкортстан Республикасыннан **Гыйльманов Дамир Фәнүзовични** тыңлыйк әле.

**Дамир Гыйльманов:** Фермер хуҗалыгыбыз Башкортстан Республикасы Кушнаренко районының 300 еллык тарихы булган Батыр авылында урнашкан. Хуҗалыкны без 2004нче елны банкротка дучар булган элеккеге “Урал” колхозы нигезендә оештырдык.

Баштагы елларда без 800 гектар гына мәйданда чәчү, урып җыю эшләре белән генә шөгыльләнсәк, бүгенгесе көндә сөртенте һәм чәчүлек җирләре 2700 гектарны били. Без соңгы елларда элек обороттан чыккан, агач баскан басуларны чистартып, тәртипкә китереп, яңадан чәчүлек җирләренә әйләндерә барабыз.

Шулай ук соңгы 7-8 елда малчылыкны да торгыза башладык. Мин инде әзрәк секретларны ачам. Әлеге вакытта 300 баштан артык эре мөгезле терлекләр. Шуларның йөздән артыгы савым сыерлары. Соңгы елларда атларга да зур әһәмият бирә башладык. Әлегә безнең хуҗалыкта 200 баш ат исәпләнә.

Үткән елның җәй айларында конкурста катнашып, “Семейное животноводство” программасына кердек. Әлеге вакытта шушы программаны тормышка ашыру өстендә эш алып барабыз. Кредитка 50 баш таналар алдык. Үзебезнең көч белән савым станокларын алдык, фермада ремонт эшләре

алып барабыз. Әлбәттә, авыл хуҗалыгы продукциясенә булган хакларның түбән булуы арытаба үсү өчен зур кыенлыклар тудыра.

Үзегез беләсез, "Семейное животноводство" программасының 60% акчасы хөкүмәтнеке булса, 40% үзеңә табарга кирәк бит. Ул, әлбәттә, аз сумма түгел. Бигрәк тә авыл хуҗалыгына булган хаклар белән. Әгәр 10 миллионлык грант аласың икән, аның кырына 6 миллион 600 мең сум үз акчаң булырга тиеш. Әле ул гына да түгел, ай саен кредит түләргә, хезмәт хакы бирергә, налоглар түлисе бар. Хуҗалыкны алып барыр өчен көндәлек чыгымнар тотарга кирәк.

Әмма барлык авырлыкларга карамастан, хуҗалыкны дөрес һәм файдалы итеп алып бару нәтиҗәсендә, без елдан ел басучылык өлкәсендә дә, малчылык өлкәсендә дә продукция җитештерүне арттыра барабыз. Үткән елның февраль ае белән чагыштырганда көндәлек савым 400 литрдан артып китә. Үткән ел бу вакытта 600 литр сауган булсак, әле мең литрдан артык сөт савабыз.

Төп җитештергән малчылык продукциясен итне, сөтне, каймакны, эремчекне, шулай ук пилмән, манты, голубцы, вак бәлеш, казылыкны авыл магазинында һәм район үзәгендә дә сата башладык. Кымыз җитештерергә дә ниятлибез.

Иптәшләр, алдагы сөйләүчеләр дә әйтеп китте бит инде, хакларга килгәндә, без инде хаклар төшсә дә, хакларны бик төшерергә тырышмыйбыз. Бездән дә сорыйлар, 3 сумга да, 4 сумга да, 5 сумга да сорыйлар регионнар. Но мин үзем 7-8 сумнан кәм саткан юк арпа белән бодайны. Ә сөтне инде без 18 сумга да сатабыз, дөресен әйткәндә, 28 сумга да сатабыз.

Шулай ук безнең республикада да бу кооперативлар оештыру өлкәсендә эшләр алып барыла. Безнең авылда да халык белән сөйләшүләр булды 2 тапкыр кооперативлар оештыру буенча. Бу өлкәдә дә без эш алып барабыз. Безгә бүгенгесе көнне ныклап үсәргә нәрсә мешать итә барыбызга да? Әлбәттә, читтән кергән продукция. Әгәр дә киләчәктә дә шул ук яртышар ел саклана торган сөтләребез кибетләрдә сатылса, шулай ук ите булмаган

колбасалар сатылса, үзебезнең продукцияне арттыру һәм җитештерү кыен булачак. Менә шуның өчен барыбызга да җыелышып, Рәсәй хөкүмәтенә мөрәҗәгать белән чыгарга кирәк, менә шушындый продукцияләрне тыю мәсьәләсе буенча.

Чыннан да, колбаса ул бит инде иттән эшләнә торган ризык. Ә кайбер колбасаларда ит вообще да юк. Бер көнне бер егет килеп керде. Мал сорап йөри мясокомбинатка. Мин моңардан сорыйм: “Ничек эшлисез колбасаны?”, -дип. “Абый, -ди, - 3 төрл порошок”, -ди. “3 төрле порошокны кушып ботыйсың да, -ди, - шуннан шушы массаны тутырасың колбаса ясап”, -ди. Менә шулай булгач, үзегез беләсез инде калганын.

Безнең хуҗалыкта эшләүчеләр саны елдан ел арта. Чит районнардан да килүчеләр бик күп. Аларга инде без торак йорт оештырдык. Җәйге чорда 4 тапкыр, ә кыш айларында 4 тапкыр бушлай ашату оештырылган. Әлеге вакытта эшкә килергә теләгән яшь гаиләләргә торак мәсьәләсен хәл итү өстендә эшлибез. Килгән кешене эш белән тәэмин итеп, вакытында хезмәт хакы бирергә тырышабыз.

Иптәшләр, безне иң борчыган мәсьәләләрнең берсе булып, авылларны саклап калу, мәктәпләрне, балалар бакчаларын саклап калу тора. Бүген ил буенча эш эзләп, ягъни эш булган очракта да, эшләп алган хезмәт хакының бер өлеше квартираларга түләп торучылар да бихисап. Әгәр без авыл җирлегендә төрле производстволар ачып, эш урыннары булдырып, аларны торак белнә тәэмин итсәк, бу проблеманы хәл итү булыр иде.

Беренчедән, күреп торасыз, шәһәрләрдә елдан ел халык саны арта, техникалар арта, йөрергә мөмкинчелек кими, пробкалар барлыкка килә. Шәһәр халкының эш таба алмыйча, квартирага түләп торган өлеше авылга юнәлсә, мәктәпләр дә, балалар бакчалары да ябылмас иде. Монда да эш урыннары сакланып калыр иде. Авыллар да яңа сулыш алып, җанланып, яңарып китәр иде, илебезнең аркасы ныклы булыр иде. Чөнки илнең терәге – авыл.

Әлегә кадәр без авылыбызда 11 еллык мәктәпне саклап кала алдык. Бу җиңел генә булмады. Мәктәп коллективы, аның директоры Аюпов Зәбир Хәмәтшариф улы белән белән берлектә, мин үзем ата-аналар комитеты рәисе буларак, күп көч салырга тырышырга туры килде. Әле Казанга килер алдыннан район советы депутаты белән берлектә мәктәп укучылары арасында “Теле барның – иле бар” дигән бәйге үткәрдек. Бу бәйгедә 40тан артык бала катнашып, татар шагыйрьләренең шигырьләрен сөйләделәр.

Бу бәйгедә район газетасыннан мәдәният һәм мәгариф бүлегеннән, “Кызыл таң” газетасыннан, Бөтендөнья татар конгрессының Башкортстандагы Башкарма комитеты әгъзасы Локманов Алик Харисович һәм ТНВ каналы да катнашты. Бу зур бәйрәм булды. Килгән кунаклар, жюри әгъзалары укучыларның яттан сөйләгән шигырьләренә зур бәя биреп, бүләкләр тапшырдылар. Бәйгедә катнашкан һәр бала бүләк алды.

Үткән ел безнең мәктәптә 11 класс укучылары ЕГЭ нәтиҗәләре буенча иң югары күрсәткечкә ирештеләр. 7 укучының 5се медальгә тәмамлады, 2се 4 һәм 5 билгесенә тәмамладылар. Мәктәптән 2 укучыбыз Мәскәүнең югары уку йортында, 2 укучыбыз Казанның хәрби танковое училищесында, 3 укучыбыз Башкортстанның югары уку йортларында укыйлар.

Күпмилләтле Россиянең тарихы – ул безнең тарихыбыз, безнең ата-бабаларыбызның тарихы. Без үзебезнең тарихыбызны яхшы белеп, анда булган начарлыкларны, хаталарны кабатламыйча, уңай нәтиҗәләрне югалтмыйча, онытылганнарын тергезеп, илебезнең, халкыбызның ныклыгы, бердәмлеге, сәламәтлеге, иминлеге өчен бөтен көчне, мөмкинлекне биреп эшләрбез һәм җир шары күләмендә ныклы урын алырбыз дип ышанасы килә.

Без Татарстан Республикасының уңышлары һәм казанышлары белән горурланабыз. Татарстан Президентына рәхмәтлебез. Татарстан халкына, аның җитәкчеләренә сәламәтлек, иминлек һәм яңадан яңа уңыларга ирешүләрен телибез.

**Камияр Байтемиров:** Рәхмәт! Нинди сораулар була?

Залдан сорау.

**Дамир Гыйльманов:** Аның 18 дигәне молокозаводларга җыеп тәкъдим итүчеләргә инде. Без анда 28, 24 белән дә сатабыз. Район магазиннарында, Уфага да җибәрәбез. Менә шуның өчен безнең төрле хак килеп чыга. Сөткә субсидия почти юк дисәм дә була. Әле без сөткә субсидия алмадык. Мин инде районда, наверно, беренче булып чәчүгә 100% кредитны алдык. Аны сайлауларга кадәр алып өлгерсәк иде дип уйлыйм инде.

**Камияр Байтемиров:** Дамир әфәнде, ничек сездә кредитлар ягы? 5% кредитлар.

**Дамир Гыйльманов:** 5% кредитны без быел чәчүгә алдык. Гыйнвар аенда башлаган идек инде, без менә әле аны алып өлгердек.

**Камияр Байтемиров:** Сезнең организационно-правовая форма нинди?

**Дамир Гыйльманов:** Фермерское хозяйство.

**Камияр Байтемиров:** Инвестиционныйны алдыгызмы яисә короткосрочныйнымы?

**Дамир Гыйльманов:** Короткосрочныйны.

**Камияр Байтемиров:** Рәхмәт! Башкортстаннан **Идиятуллин Хәсән Сәгыйтҗәнович** мондамы? Рәхим итегез!

**Хәсән Идиятуллин:** Саумысыз! Советлар Союзы заманында ук фермер булган кеше. Бу залда утырган кешеләр, егетләр, иптәшләр, туганнар, милләттәшләр, безне барыбызны да бер сыйфат берләштерә. Без барыбыз да 10-11 яшьтә колхозга эшкә чыккан кешеләр. Шулай бит? Кем көтү көткән, кем грузчик булган. Кем тырма артыннан йөгергән, кем печән җыйган. Барыбыз да 20, 30, 40 ел авыл хуҗалыгында эшләгән кешеләр.

Иң мөһиме бүген әйтелгән сүзләрнең – ягулык 40 сумга җитте һәм сайлаулардан соң, җәйгә таба 50гә, 60ка да җитә дигән мәгълүмат ишетелде. Менә, егетләр, колхоз-совхоз заманында без җитештергән ит, сөт үз кыйммәтендә, май-ягулык 1,5-3% кына били торган иде. Бүген чагыштырмача сан 65-75кә җитте.

Бүген авыл хуҗалыгында фермермы, аерым хуҗалыкмы, зур мәйдан биләгән күмәк коллективны җыйган хуҗалыкмы, барысы да эшләп, яшәп

кил. Русча әйтәм, не благодаря, а вопреки. Без барыбыз да Совет дәүләте заманында белем алганбыз. Чыныкканбыз, ныгыганбыз. Менә без сөйрәп алып киләбез. Без дә мәңгелек түгел.

Шуның өчен менә милләтебез, авылыбыз, мәктәп дип миннән алда чыгыш ясаган иптәшләр әйтеп киттеләр, дөрес, барысы да кирәк. Балалар да кирәк, аларны өйрәтергә кирәк. Шунысыз безнең сөйрәп килгән авыр йөкнең бер көнне тәртәсе өзелеп торып калырга мөмкин.

Мин үзем нәрсә белән генә шөгыльләнмәдем, нәрсә белән генә шөгыльләнмим. Нәрсә белән генә шөгыльләнсәм дә әлегә тиклем булган шөгыльне берсен дә ташлаганым юк. Ат үрчетәм икән, үрчетәм. Сыер үрчетәм икән, ат минем алдан бара. Сыер малы үрчетә башладым икән, үрчетәм, сарык-кәҗә алдым икән, алдагылары алдан бара.

Гомер кыска кешенең. Бүген басучылык, иртәгә елкычылык. Гомер үткәнен сизми дә калабыз. Мин сезгә киңәш итеп әйтәм. 20-30 ел элек булган Рәсәй күләмендәге мал саны, сыермы, атмы, дуңгызмы, кәҗәме – дөем алганда колхозда, совхозда, аерым хуҗалыкта, бүген ничә проценты бар? Юк шул 20. Башкортстанда 5-8%. Күзгә күренми. Без урамда көтү-көтү йөргән сыерларны оныттык. Иртән сәгать 6-7дә апалар, әнкәйләр, әбиләр көтү куып чыгаралар иде авыл башына. Оныттык.

Игенне игәргә кирәк, Әйе, ак тамырны да үстерергә ярамый, каенны да үстерергә ярамый. Малны үрчетүе кыенрак. Мал кирәк. Менә бүген икмәк сатылмый. Дәүләттә икмәк сатылмый. Дәүләттә икмәк күп түгел, егетләр. Дәүләттә мал юк икмәк ашарга. Соңгы 25нче Съездга тиклем кабул иттеләр Совет гражданинының һәркайсына 1 тонна икмәк җитештерергә дип. Нигә ул 1 тонна икмәкне кайсы ашап бетергән.

1 тонна икмәк елына бетә, калмый. Чөнки ул икмәкне тавык та чүпли, йомырка бирә, сарык-кәҗә дә ашый, йон бирә, мамык бирә ,сыер да ашый, каймак бирә, сөт бирә, май бирә, ит бирә. Икмәк тә пешерәбез. Менә шулай итеп 1 тонна бетә торган иде.

Бүген Рәсәйдә күпме безнең икмәк җыелды? 70-80 миллион җыелдымы? Бу бит 1 тонна килеп чыга икмәк. Ә нигә без аны кайтара белмибез? Менә шуның өчен мал булса, икмәккә урын була. Әлеге дә баягы, ә нигә мал асрый алмыйбыз? Чөнки безнең батюшка бар. 10 мең тонна ит азыклата безгә тәүлегенә кирә. Без бит инде Аргентина, Бразилия, Голландия белән ярыша алмыйбыз. Алар бит безнең кебек кышны күрмәгән, көндез түгел, төшендә дә. Бездә 9 ай кыш.

Килер бер көн, күңелләрем сизә, булмас ул тонналаган 10 мең. Малны карарга кирәк, малны асрарга кирәк. Бүген барча булган малны сакларга кирәк. Шул сәбәпле без үзебезнең җитештергән икмәкне, бәлки, урнаштырып, урын табып, үзебез малчылык аша эшкәртеп, хакын күтәреп, бәясен күтәреп, һаман булса да аяк басымын ныгытырбыз дип уйлыйм мин.

Минем үземнең хуҗалыкта мал күп: меңнән артык елкы, 60-70 сарык, кәҗә малы, башка күп төрле мал, кош-корт. Иң мөһиме шул – бар мал да сыйфат. Менә без рынок дибез бит инде. Ул бит инде рынок базар түгел. Семечки сатып утырган әбиләр түгел бит инде. Рынок – ул конкуренция. Шуның өчен сыйфат. Минем хуҗлык килә бары тик шушы сыйфат аркасында. Атлар сыйфатлы, сыерлар сыйфатлы бөтен мал сыйфатлы.

Хуҗалыкта бөтен нәрсә сыйфатлы дип әйтәм дә, үземдә генә сыйфат юк дип куям. Шуның өчен без татар җанлы халык, микрофонны кулга тоткач, ат турында сөйләмичә китсәм, аңламассыз. 10 яшь булгандыр инде миңа ныклап аякка басып, атка атланып чаба башлаганга. Ә беренче тапкыр атка утырганда мәктәпкә бармый идем әле. 5-6 яшь. Менә ни тикле гомер минем багышланган атка түгел, үзебезнең татар җанлы, татар токымлы атка. Атка түгел.

Бу турыда мин китап чыгарырга бик күп мәгълүмат җыйдым. Аллабирса, исән булсак, сау булсак, 1 ел-ел ярым эчендә ул китап дөнья күрер дип ышанам. Шуның өчен без татар җанлы булгач, ир булгач, без ир дип әйтергә яратабыз, күпләребезнең уллары бар, кызлары бар, Сабантуйлар үтә, Сабантуйларда чаптырабыз.

Менә хәзер без 3нче ел була инде, Аллабирса, Олы Теләктә матур итеп Сабантуй үткәрәбез. Сабантуй түгел, Башкортстанда яшәгән бөтен татарларның татар конгрессының Сабантуе итеп үткәрәбез. “Конгресс татар Республики Башкортстан” дип зур итеп язып куябыз без аны. Бу гореф-гадәткә керде. Кешенең теленә керде, күзенә керде. Ә быел без аны, бәлки, конгресс түгел, ә бөтен татарлар конгрессы Сабантуе итеп үткәрербез.

Анда без чаптырабыз татар токымлы атларны. Рәхмәт, үткән елда Миңнеханов, без бит инде аны әйтәбез: “Ул сезнең генә Президент түгел, ул бөтен дөнья татарлары Президенты”, - дип. Шуннан өстәп куябыз: “Безнең Президентны югалта күрмәгез”, -дип. Исемен сыздыра, юдыра күрмәгез. Мин ул сүзләрне әйттем. Бүген дә кабатлыйм.

Менә шулай итеп 2 тапкыр машина куелды, 20-25 тәкә куябыз. Сабантуй бик матур үтә. 50-60 ат катнаша. Самолетлар оча. Халыкка бәйрәм ясыйбыз. Туймазыда булды Ык буе авыллары Сабантуе. Анда язылган иде “Ык буе авыллары Сабантуе. Рәсәйдә яшәгән бөтен милләтләрнең дуслык күпере” дип. Менә сабантуйларда шушы безнең девиз булырга тиеш.

Сабантуй – ул татар телендә генә, ул татар милләтендә генә. Туй үткәрер өчен кулга сабан тотарга кирәк, җирне сөрергә кирәк, иген игәргә кирәк. Иген икмичә, җирне сөрмичә бүләк кенә була. Ач карынга Сабантуй үткәреп булмый. Менә шулай итеп “Бөтен милләтләрнең дуслык күпере” дип язып, барысын да чакырып, Сабантуйны үткәрергә без максат һәр елны максат куйганбыз инде. Ягъни үзебезгә үзебез йөкләмә алып, шулай итеп яшәп ятабыз.

Монда бит безнең туганнар Ырынбурдан, Сарытаудан, Новосибирскидан, төрле өлкәдән. Аның бернәрсәсе дә юк. һәр өлкәдә, Ырынбур өлкәсенең татар конгрессы Сабантуе дип үткәреп буламы? Бернәрсәсе дә юк, бер авырлыгы да юк. Сезнең Ырынбур өлкәсендә мин беләм Ак барс дигән бик шәп безнең татар егетләре бар. Сез беләсездер аларны. Алар Башкортстан белән границада гына яшиләр. Ерак түгел. Аларга күп җир дә кирәк түгел инде. Көтүлек җире дә ярый, буш яткан җир дә ярый.

Шунда матур итеп багана утыртасың, кадак кагасың. Һәр елны бер җирдә үткәрсәң, ул үзеннән үзе килә дә чыга.

Бу безнең эшләвебезне, гореф-гадәтләребезне, ничек эшли алганыбызны, ничек ял итә алганыбызны һәм башка милләттәр белән ничек без матур итеп, дус булып яши алабыз, эшли алабыз һәм ашый-эчә, җырлый алабыз икәнен күрсәтә. Дөнья булгач эш кенә түгел, җыр гына да түгел, бию генә дә түгел, барысы да булырга тиеш.

Менә әйтеп китәсе килә кымыз турында. Чынында, кымызны эчәргә кирәк аны. Минем янда гына Рәсим Зарипов утыра. Миндә атлар күп, аныкы минекеннән 3-4 мәртәбә күп. Конезаводлары да бар. Бердән-бер кеше Башкортстанда 365 көн кымыз ясаган кеше. Буранмы, 40 градус суыкмы – кымыз ясый. Кымызның саклау вакыты күпме дигәнгә генә әйтәсем килә, кымызның начары булмый.

Нинди кымыз да яхшы. Аның саклау вакыты нинди температурада ясалган, ничек сакланган, нинди савытта сакланган, кайсы айда ясалган. Августта, сентябрьдә, октябрьдә ясалса кымыз, алай булса да бер ни эшләми ул. Октябрьдә, ноябрьдә ясалган кымызны нигә 2 ай син сакламыйсың. Кеше өчен аның бер сыйфаты да кимеми. Кымызны ясарга кирәк, атларны булдырырга кирәк, игеннәрне чәчергә, игәргә, балаларны үстерергә.

Менә үткән елны бәйрәмгә мин алып килдем үземнең улымны, внукларымын алып килдем. Бүген инде улымны алып килә алмадым, чөнки эш күп бит инде хуҗалыкта, йә ул калырга тиеш иде, йә мин калырга тиеш идем. Ул калды атлар белән. Әле атлар урманда. Быел Аллага шөкер. Былтыр 3 метр кар булса, быел 10 гына сантиметр. Ягъни безнең өчен кар юк дигәнне аңлата инде.

Менә без әйтәбез инде, безгә 30 см кар юк, кыш юк кебек. Кабатлап китәм, бер дә кыш күрмәгән илләрдә итне үстерергә нәрсә инде. шул ук Австралиядә ничек үстергәнен беләсез бит инде. Елына бер мәртәбә вертолет белән куып китерәләр дә резервациягә, сайлап алалар да эреләрен, куып та чыгаралар. Бөтен эшләре шул.

Шуның өчен, монысы кызганычрак, куркынычрак, рөхсәт итсәгез. Мин инде политикага бик кысылырга тырышмадым, тырышмыйм, но все равно эчке табигать үзе төртә бит ул. Әгәр дә дөньялар бозылып китсә, бездән сорап тормаслар. Синең авылың 300 еллык булганмы, 3 мең ел булганмы – сорап тормаслар. Бердәм булырга кирәк. Хәзер телефон белән күреп утырасың, сөйләшеп утырасың. 20-30 ел элек без аны күз алдына китерә алмый идек.

Законотворчество дигән нәрсә бар бит ул. Бик әшәке нәрсә ул. Кемнәрнедер җыеп тегендә хокук кабул итәләр дә, без каян аны беләбез. Без аны белү генә түгел, без аны укып та бернәрсә дә белмибез. Мисал, 1993нче елны Конституцияны кулга тотып барыбыз да укыдыкмы, аңладыкмы? Ә килеп Конституцияны сайладык та, үзебез үзебезне астык.

Шуның өчен дөньяда әллә нинди хәлләр булырга может. Борчылмагыз, уяу булыгыз, сак булыгыз, сүзләрегезне теркәгез, киңәйтегез, зурайтыгыз, арттырыгыз. Аңладыгызмы мин нәрсә әйтергә теләдем? Аңласагыз аңладыгыз инде, мин ярып кына салмадым. Аңламасагыз инде, мин сезгә ярып салсам да аңламыйсыз.

Конституцияне үзгәрттек тә 93нче елны. Гафу итегез. Менә мин бүген үземне кол хөкүмендә хис итәм. Нигә? Ә миннән кем нәрсә сораганы бар. Киләм дә, пистолетны алып, 40 сумга заправить итәм. Киләм дә, 60ка да заправить итәрмен мин аны. Сөтне 18 белән дә саталар, 20 белән дә, 10 белән дә саталар. Кем бездән сораган? Җирнең казылма байлыкларын, егетләр, үзебез бирдек. Үз кулларыбыз белән тотып ящикка салдык. Шуның өчен моннан кире сайлаган чакта, сайлауга барган чакта, сез акыллы, аңлы егетләр. Башкаларга да акыл-аң бирегез.

Безнең Чишмә районында Ярми Сәете дигән кеше булган Сталин заманында. “Килер бер көн, хәерчеләр йөрер төркем-төркем. Бүген 40 миллион работающие нищие. Иллә мәгәр ул вакытта баганалар таш булыр. Ә бу дөньяга, ялгышкан ул бер сүзне, диваналар баш булыр”, -дигән. Баш булган кешеләр дивана түгел. Менә безнең язмыш бүген кем кулында?

Уйлагыз, уйлагыз, уйлагыз. Язмыш безнең үзебезнең кулда. Но тартыш бара, кем җиңә.

Гафу итегез, сезне борчысам. Олы Теләк ясаган Сабантуйга килегез. 7 июльдә Сабантуй була безнең. Тагын бер нәрсә әйтеп куям. Башкортстанда бу билдәле көн. Аны түрәләр беләчә. Олы Теләктә Сабантуй июль аеның беренче субботасына туры килә. Иглин районы. Килерсез, күрерсез, өйрәнерсез. Бәлки без сезгә Сабантуйга, сез безгә Сабантуйга килерсез. Бердәм булыйк, бергә булыйк. Рәхмәт!

**Камияр Байтемиров:** Рәхмәт, сезгә! Нинди сораулар бар?

**Залдан сорау.**

**Хәсән Идиятуллин:** Сайлауларга барам. Сайлауларга барырбыз ла ул. Мин үзем, гафу итегез, сезгә бер нәрсәне әйтергә оныткантмын. Без татар токымлы атка атланып, Казан, бәлки Кремль яныннан, быел 18нче елны мартның 22се, 25ләрендә хаҗга юл тотарга уйлыйбыз.

Без татармы, безнең атлар бармы? Без ирләрме, егетләрме? 6-7 ел элек без җибәрдек экспедиция Кытайга. Бардык, җиттек Пекинга. Ул якка барырга җиңелрәк. Чүлне генә үтәргә кирәк. Анысы гына авыр. Теләүчеләр булса тарихка керергә рәхим итегез. Менә моны мин сезгә әйтеп китәргә чак кына онытып китмәгәнмен.

Нигә быел? Мине үгетлиләр, мине үгетлиләр Татарстан түрәләре. Чөнки 17нче елны атеистлар властька килгәч, 100 ел үткән. Аннан кире безнең ата-бабаларыбызның ислам динен кабул иткәнгә 1025 ел үткән. Бу ике датаны бүген бәйләмәсәк, киләсе елга русча әйткәндә алтара, ни полтора. Кемнәр безнең белән хаҗга барырга риза, кул күтәрегез әле. Дөрес, җиңел эш түгел. Уйлагыз. Рәхмәт!

**Камияр Байтемиров:** Ярар, зур рәхмәт! **Гайса Зәкиуллович** мондамы? Рәхим итегез!

**Гайса Сәгыйдуллин:** Мин үзем Башкортстаннан, Гафури районыннан, Мәҗит Гафури туган районнан. Мин үзем фермер. Сыер малы тотсаң, сөтле буласың, бозаулы буласың һәм 40%ка якын кайтарып бирә

акчасын. 5 миллионга алган идем, шуның миллион 800 кире кайтты. Хөкүмәт биргән ярдәмне безгә кулланырга кирәк инде.

Минем үземдә где-то 17 кеше эшли. Бар бухгалтер, ветврач, доярка бар, телятница бар. Бу беткән хозяйство иде. Ул банкрот булды. Авыл халкы белән яшибез, шулар белән эшлибез. Мәктәпкә ярдәм сорасалар всегда пожалуйста. Анда күп сорамый бит инде. Медпункты бар авылның бәләкәй генә булса да. Төрле бәйрәмнәр үтә инде. Яңа ел бәйрәме традициягә әйләнде. Ел саен салют атам 100 заряд белән. Бөтен клуб шыгрым тулы була инде. Тирә яктан да киләләр.

Менә шулай итеп яшәп, тырышып ятабыз. Сөтне җитештерергә өйпәндек без, малны асрарга. Тәүдә сөтне сдавать итә идек 22 сум 50 тиен белән. Ә хәзер 1 марттан сөтне 17 сумга калдырдылар. Бүгенге көнне мин савам где-то полторы тонны, җәйгелеккә ул хәзер 2 тонна ярым була. Государство уйларга тиеш инде моны.

Солярка бит үзебездә чыга. Без каяндыр алмыйбыз бит аны. Хотя бы крестьяннарга әзрәк льгота булырга тиеш. Менә безнең Салават шәһәреннән Газолин дигән горючий алып киләләр. Аны как самогонный аппарат кайнаталар һәм саталар. Башнефть һәм Татнефть заправкаларына түгел, ә частный заправкаларга. Менә моны безнең хөкүмәт караса әйбәт булыр иде.

Хатын-кызларны якынлашып килгән 8 март бәйрәме белән котлыйм. Барыгызга да исәнлек-саулык, тазалык-бәхет, ә ир егетләрне инде үткән бәйрәмнәр белән.

**Камияр Байтемиров:** Нинди сорауларыгыз бар?

**Залдан сорау.**

**Гайса Сәгыйдуллин:** Эшләгән рабочийлар һәрберсе зарплатасын ала. Иң кәме 10нан 20гә тиклем. Точный данные әйтмим, налогын түлим, пенсионныен түлим.

**Камияр Байтемиров:** Рәхмәт, Гайса Зәкиуллович! Учитывая, что скоро 8 марта, давайте предоставим слово женщине – Гимрановой Альфире Заентиновне, Пермский край.

**Әлфирә Гимранова**: Мөхтәрәм милләттәшләр, бөтен Россиядән килгән делегатлар, ир-атларны шулай ук үткән бәйрәм белән тәбрик итәм һәм үзебезгә кагылган теләкләрне дә кабул итәбез. Рәхмәт сезгә барыгызга да. Организаторларга зур рәхмәт!

Мин җир дә сөрмим, ашлык та үстермим, но 25 ел бизнеста. Әлеге дә баягы налоговый кодекс чыкмас алдан, безнең Федеральный закон о предприятиях и предпринимательской деятельности булган вакытны безнең налоговая инспекцияләр килеп чыкты. Ул вакытта мине налоговая инспекциягә чакырып алдылар. Чөнки аңа кадәр мин иң беренче кооперативлар башланып киткән вакытта эшли идем.

Налоговая инспекциягә килгән эшләргә урнашкан работникларны да эшләргә өйрәттем, үзем дә шунда эшләдем. 93нче елны безнең путча булды. Менә шушы путча мине тудырды. Налоговая инспекциядә эшләгән вакытта мин бик күп предпринимательләргә, колхозларга, совхозларга зыян килгән вакытта, миңа шундый уй килде. Ул вакытны единстенно бер газета белән кулландык "Экономика и жизнь" дигән. Шунда укып утыра идем перечень аудиторов.

Мин әйтәм: "Бу нинди профессия?" Шуннан тегендә кереп, моннан укый башладым. Оказывается анда с высшим образованием, с опытом работы или главным бухгалтером, или юристом или специалистом налоговой инспекции. Моңа күз салып аттестоваться иттем дә, предприниматель булып эшли башладым. Аннары лицензия алдым Министерство финансовта. Независимый аудитор булып эшләдем, т.е. ярдәм күрсәтә башладым предпринимательләргә. КФХларга, организацияләргә.

Шул вакытта минем менә нинди хәл булды. Колхозларны яба башладылар. Мәсәлән, бер колхоз турында сөйлим. Специалистлар калмады, яшьләр чыгып китә башладылар. Колхозлар ябыла башладылар. Шуннан бер безнең предпринимательне сельхозуправлениега чакырып алып, колхоз поручать итәгә уйладылар. Ул предприниматель килеп, миннән дә обслуживаться итә иде. Бухгалтерский учетын алып барам.

Аннары килде дә, мин әйтәм бу хозяйствоны ал дим. Алдык. Ярый, эшли башлады. 2 атна үткән иде, моны чакырып алдылар да, бу колхозны банкротить итәбез диләр. Нәрсә эшләргә? Хәзер без җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять формировать иттек тә, параллельно эшли башладык.

Банкротить иткән хозяйстволарның бер нәрсәләре дә калмады бит инде. Аларны арбитражный специалистлар алып китә алмадылар, фермаларының ташлары белән шул килеш торып калды. авылдашлар аны таратып, ташып бетерделәр. Ә бу авылда без аны болай итеп эшләдек. Договор создавать иттек бер-берсе арасында. Бер-берсенә эш эшләп, просто искусственно без наращивать иттек долгларны. Безнең бөтен имущество торып калды ООда. Хәзергә чаклы ул хозяйство безнеке эшли.

Мин бу ИП белән генә торып калмадым аудиторлыкта. Мин общество с ограниченной ответственностью ачтым. Специалистлар набирать иттем. Хәзерге заманда без 5 специалист эшлибез. Безнең 200 КФХ, ИП и ОО, ну и все остальные прочие. Шуларга барысына да ярдәм күрсәтәбез, бухгалтерский учетларны алып барабыз. Сез үзегез уйлап карагыз, 17 работникка 1 бухгалтер тотасыз. Ә безнең бухгалтер 50 шундый кешене обрабатывать итә.

Безнең зур программа. Пенсионный, хәзер пенсионныйны, правда, налоговыйга передавать иттеләр, фонд социального страхованиягә, статистикага. Бөтен җирләргә отчетларны без программада җибәрәбез. Менә шулай итеп, бөтен районнагы хозяйстволарга булышлык күрсәтәбез. Миндә 3 портфель. Мин председатель Совета по развитию малого бизнеса при администрации района, мин председатель татаро-башкирской общественной организации, директор ОО “Эксперт аудит”. Эшләргә тырышабыз.

Тырышабыз үзебезнең татар халкы өчен, телебезне саклап калырга, гореф-гадәтләребезне саклап калырга. Мәктәпләрдә 1 сәгать татар теле укытырга рөхсәт иттеләр. Татар авылында, татар мәктәбендә 1 сәгать дәрес белән нинди телне саклапк алырга була? Шуның өчен без район күләмендә тырышабыз районный мероприятияләр үткәрергә. Декабрь аенда үткәрдек

татарча чыршы бәйрәмен. Бөтен татар авылларыннан балаларны җыештырдык, 70ләп бала җыештырдык.  Шунда конкурс игълан иттек. 3 кенә бала татарча шигырь сөйләделәр.

Сөйләр сүзләр күп. Әле зарплатагызны тыңлап утырам. Конечно, зарплатагыз бар инде, агы да бар, карасы да бар. Но агыныкының коелмасын чүбе карасына. Шуннан карасыннан агына килеп чыгарга можетлар һәм агыннан карасына. Шундый киңәшем бар минем сезгә. Прокуратура сезнең зарплатагызны тоже тикшерә. Барыгызга да шундый йөкләмә эшләр бирелә прокуратура сезнең артыгызга чыкмасын диеп.

Безнең хәзер бар МРОТ. Зарплата не должна быть меньше МРОТ. Например, если шул МРОТны алып, 12 айга тапкырлап, сез определять итсәгез годовой фон. Это не нарушение, шулай бит. Шуны сез 1 ел эчендә түләп бетерергә тиешсез. Безнең бар плановые рабочие часы в году. Менә шушы фондны плановые часыга бүлгәч, сез исходя из МРОТ, бер сәгатьнең хакын табасыз.

Сезнең работникларыгыз бүген чыга, ә сез стараетесь более дешевую рабочую силу использовать. Ул вакытта сезгә болай эшләргә була. Табель учета рабочего времени. Анда ограничение юк. Договор син заключать итәрсең, работнигың синең может 2 генә сәгатькә килә, мин больше синең белән эшләмим. Договрны шулай итеп заключать итсәгез дә була. Менә шушы фактически отработанные часы можете умножить на этот часовой тариф. Это никакое не нарушение.  Это не криминал. Аңладыгыз?

**Камияр Байтемиров:** Нинди сораулар?

**Залдан сорау.**

**Әлфирә Гимранова**:  Аны индивидуальный предприниматель үзенең доходыннан түли. Работникларныкы түгел, ә монысы сезнең аерым доходыгыз. Шуннан 300 меңне алып бәрәләр, быел үзгәрттеләр. Тариф безнең 32 меңгә мендеме. Правительство шулай решает бит. Бернәрсә дә эшләп булмый.

**Камияр Байтемиров:** Тагын нинди сораулар бар? Сезне кунакка чакырачаклар.

**Әлфирә Гимранова**: Борай районында лесхозга булыштым. 8-908619386 – Әлфирә апа. Рәхмәт барыгызга да.

**Камияр Байтемиров:** Рәхмәт! **Балтаев Әлфиз Хәмис** улына сүзне бирик әле. Рәхим итегез!

**Әлфис Балтаев**: Исәнмесез! Мал алсаң, малга ашатып, ничектер эшләргә була алга таба. Миңа как раз туры килде 2013 елда килдем, монда күрдем. КФХага алып бардылар инде безне. Кайсы районга икәнен әйтәлмим хәзер. Ул үзе 25 сыердан башлаган. Ташланган ферманы алган инде ул. Шуңа карадым да, мин әйтәм: "Без булдыралмыйбыз мени, бездә дә авылда шул өй".

Мин Пермь крае Барда районы, Бардабаш авылында туып үстем. Бу авылның ямен, тәмен, төсен бетерәсе килми. Шуңа күрә шуннан кайттым да, как раз безнең шул елны семейная молочная ферма дип грантка теләк белдердем мин. Молочная фермага безнең крайда әле язучы юк иде. Мин первобытный булдым инде. Мин яздым, семейная молочная ферма на 50 голов со шлейфом.

Токымлы башмаклар алып кайтып, 14нче елны мин ачык басуга җир алып, шунда ферма төзедем. Хәзерге көндә 50 баштан 90ны узды инде. Аллага шөкер, эшләп ятабыз. Мин инде уйламыйм, быел печәнемне кая сатам дип, игенемне кая итәм дип. Монда абзыйлар сөйлиләр 4 сум да ничә сум дип. Мин әйтәм, игенне чәчмәсәм дә сатып алып кайтырга була икән дип 4 сумга. На самом деле үзебез чәчәбез, урабыз, Аллага шөкер.

Сөтнең бәясе бездә дә 19 сумга төште. 22 сум иде. Хәзер инде солярка бик кыйммәт. Хәзер Лукойловскидан белешә башладык. Хәзер язгы чәчүләргә безгә дә кирәк инде. Уйлар күп. Монда сенаж дип башладылар инде. Алга таба шул сенаж ясыйсы килә инде, сенаж в упаковке диләр инде аны. Сөтнең качествосын арттырасы килә.

Рәхмәт әйтәсем килә шушы чараны оештыручыларга. Алга таба шулай үсәргә, яшәргә кирәк. Мин 7 класста уже әти белән басуда механизатор булып, 9 класста миңа трактор доверять итеп, шулай үскән кеше. Авылны ташлыйсы килми бер дә. Аллага шөкер, матур гына яшәп ятабыз.

**Камияр Байтемиров:** Рәхмәт сиңа, Әлфиз Хәмисович! Безнең арада яшь егетләр дә бар. Безнең эшне бездән соң алып баручылар. Сорауларыгыз бармы? Юкмы. Молодец әйтәбез инде үзенә.

**Залдан сорау.**

**Әлфис Балтаев**: Мин 2007 дә башлагач, 2013тә әкрен генә җирләрне үземә ала башладым. Колхозчылар саталар, әби-бабайлар. Пай җирләрне сатып алып, 4,7 гектар инде. 1 пайда 4,7 инде.

**Камияр Байтемиров:** Рәхмәт! Кемнең тагын сүзләре бар?

**Фәрит Халитов**: Хәерле көн! Мин Удмуртиядән, Фәрит Халитов. Мин инде сөйләп киткән идем монда бәрәҗгенең бәясе юк дип. Бәясе 25кә, 30га хәтле барып җитте. Минем фермерское хозяйство бар 1993нче елдан. 2008 елны мине чакырдылар колхозга. Менә 10ныe ел инде колхозда эшлим.

Үзем торам Кизләрдә, әтиләр килделәр 59нчы елны Кукмара районыннан күчеп. Без 3 бала шунда тудык инде. Менә 2008нче елдан 10 ел эшлибез инде. 432 баш сыер иде колхозда. Шулай ук колхоз булып калды ул советский системада ук. Бүген инде 560 сыеры гына.

**Камияр Байтемиров:** Гафу итегез. Бездә дә шундыйлар бар. Колхоз булып калды диләр. Организационно-правовой формасы нинди соң? Колхоз исеме бар.

**Фәрит Халитов:** Коллективно-частный.

**Камияр Байтемиров:** Андый организационно-правовая форма юк. Или ЗАО, или ОО, или кооператив.

**Фәрит Халитов:** СПК - сельхозпроизводственный кооператив безнең. Пайлары, шулай ук имущественный пайлары калды. Шулай ук. Шулай ук җирләре бар, кем оформлять итә.

Минем нәрсә әйтәсем килә. менә без бит Татарстанга локомотивка дип карап торабыз. Менә хәзер бәясе төште бит сөтнеке. Бик каты төште бит. Без үзебезнең республикада тоже тавыш чыгарабыз. Миңа бик ошады күптән түгел, 2001 нче елның КВНын караган идем. Беләсезме, бүген проблеманы тыңларга яратмыйлар, ә проблеманы әйтергә кирәк. Проблему надо решать.

Президентка бик зур рәхмәт. Без бит үзебезнең главага тоже обращение ясадык. Безнең главаларга әйтергә кирәк әле, авыл булырга тиеш, җир булырга тиеш, кеше булырга тиеш дип. Продукт питания диләр. Ул бит лекарство. Бүген дөрсе әйтте Башкириядән, безнең бит суррогат күп хәзер. Безнең бу Всемирный конгресс татар. Мин моннан шатланып китәм. Бүгенге секциядән резолюция булырга тиештер. Обращениене законодательно принимать итәргә кирәк.

Дөрес әйттегез, быел чыдасак ярый, ә икенче елга нәрсә була? Быел принимать итәргә кирәк решение. Бик зур рәхмәт җыйганыгыз өчен! Бездә әйтәләр: “Зло процветает до тех пор, пока добро молчит”, - дип. Монда зло дип әйтәсе килми. Бар әйбәтлек, бар әшәкелек. Әшәкелек каты китә ул, әйбәтлек сүз әйтмәсә. Шуңа күрә, әшәкелеккә юл бирәсе килми. Рәхмәт сезгә!

**Камияр Байтемиров:** Рәхмәт! Әкрен генә эшебезне тәмамлыйбызмы? Хәзер 5-6 минут сөйләшеп алабыз. Менә монда бөтенебез бер тиңнәр. Мин уйлыйм, музыкаль кешеләр дә монда бардыр. Без бер музыкаль рәттә эшлибез, уйлыйбыз да шулай. Бер музыкальная волнада барабыз. Шуңа күрә мондагы сөйләгән сүзләр, монда уйларга да кирәкми, әйтергә кирәк, чын күңелдән чыккан сүзләр.

Без борчылабыз, ләкин әйтик, без илдә торабыз. Государствода торабыз. Ә государство защищать итәме соң безне? Кайсы җирдә ул государство безне кайчагында оныта, кайчандыр, әйтик, субсидия бирә. Дөрес микән, юк микән. Шуңа күрә мин уйлыйм, безнең түгәрәк өстәлдә сөйләгән сүзләрне сез дөрес әйттегез, ничектер нормализовать итәргә кирәк. И может быть обращение дә ясарга кирәк.

Обращение ясарга кирәк дөрес итеп безнең җитәкчеләргә, Мәскәүгәме, регионнаргамы. Может быть регионнарга да сүзне җиткерергә кирәк, чтобы алар кырыйда басып тормасыннар. Аларны Президентмы куйган, без сайлаганмы җитәкче итеп. Шуңа күрә безнең баштан килгән фикерләрне җиткерсәк, менә Хәсән әфәнде дөрес әйтте, күп сөйләде, күбесе бездән тора.

Если без эшлибез икән, без җанны, күңелне биреп эшлибез бит. Кем өчен без эшлибез? Үзебез өчен беренче. Әйтик, эшмәкәр сообществоларыбыз Икенчедән, Сабантуйлар ясыйбыз, халыкның дәрәҗәсен күтәрәбез. Авылда кая чокыр бар, күмәбез, кая юл юк, юл ясыйбыз. Шулай бит инде. Шуңа күрә мин уйлыйм, монда җыелган кешеләр алар особыйлардыр.

Мин Чиләбе өлкәсендә булган идем. Сүздән сүз китте дә, мин әйтәм: “Мин Татарстаннан. Фермер”. Карыйм, татарлар татарча сөйләшәләр, но сөйләүләре икенче төрлерәк. “Бу Челябинские, бу безнең җир, - ди. – Без Ермактан калган татарлар”, -ди. Шуңа күрә үзләрен анда хуҗа дип саныйлар. Эшлиләр шунда, матур итеп торалар, үзләренең телләрен саклыйлар.

Миңа бик ошады беренче чыгыш ясаган иде Фидания. Чын татар теле белән, күңел белән үзеңнең торган җирләреңне сөйләп, эшләреңне күрсәтеп. Шуңа күрә матур итеп безгә торырга булсын! Без эшләгән эшләр, сөйләгән сүзләр ул истәлектә калыр. Тагын бер кабат әйтәм, без үзебез өчен генә тормыйбыз. Үзебез өчен генә тырышмыйбыз. Без государтсво өчен тырышабыз. Шуңа күрә без государстводан ниндидер үзебезгә юлны да сорарга тиешбез.

Выборлар була. Һәрберегезнең үзегезнең күңелдә ниндидер уйлар бардыр. Хәсән әйтмешли, уйлашыгыз, бер-берегездән сорашыгыз ничек голосовать итәргә икәнен. Сез күрдегез. Кичәме әле күрсәттеләр телевизордан. Соң гына безнең кандидатлар выступать иттеләр. Бер-берсе белән ярыштылар.

Монда нинди сүз сөйләсәк тә, без бер-беребезгә стакан белән су сипмәдек, ошыймы-юкмы. Кемдә дисциплинамы, кемдә нинди уй, таза уймы, начар уймы. Нигә без кемгәдер су сибәргә тиеш. Хотя әйтик, сез дә, мин дә

төрле елларны уздырдык, төрле кеше безнең белән эшләргә тырышты. Кайсы бер төрле, кайсы икенче төрле. Ләкин безнең дәрәҗә, безнең уй зуррак та, күбрәк тә. Шуңа күрә бетергәндә минем әйтәсем килә үзегезгә исәнлек, саулык. Без алда очрашырбыз. Зур рәхмәт сезгә!

“Шәхси ярдәмче хуҗалыклар
дискуссион мәйданчыгы”

*1 март, 2018 ел* *ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Федосеев ур., 36*

**Модератор**: Р.Р.Хәбипов – ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары.

Р.Г.Муллагалиев – Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының баш референты.

**Ришат Хәбипов:** Хәерле көн! Татар эшмәкәрләренең конгрессын актив рәвештә Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан без хуплап каршы алабыз. Сезнең белән бергә үзебезнең тәҗрибәне уртаклашабыз. Сезнең яхшы тәҗрибәне без чыгышларда тыңлыйбыз. Минем исемем Хәбипов Ришат Рәшитович. Мин үзем Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында икътисадый һәм кече эшмәкәрлек эшләре буенча министрның урынбасары булып торам. Үзем чыгышым белән Баулы районыннан. Ул безнең көнчыгышта тора. Оренбургтан яртысы, Самарадан бер өлеше, Башкортстан белән бер өлеше янәшәдә.

Без үзебезнең күпмилләтле республикабызда матур итеп яшәеше, төрле милләт халыкларының дус, тату яшәүләре белән горурланабыз. Һәм инде бүгенгесе көндә барыгызны да мин тәбриклисе килә язның беренче көне, беренче март, кояшлы көн. Ләкин Кыш бабай әле обещать иткән, әле 8 мартта да хатын-кызларны тәбриклим дип. Ничек кенә булмасын, яз настроениесе барыбер икенче. Даталары булса да куанабыз.

Бүген үзебезнең Президентыбызның туган көне. Ул бүген Мәскәүдә. Без инде бөтен тәбрикләү сүзләрен Рөстәм Нургалиевичка җибәрдек. Аның җавапларын алдык, рәхмәт сүзләрен. Бүген Владимир Владимирович Путинның обращениесен телевизордан күрсәтәләр. Без инде һәрдаим көтеп торабыз үзебезнең Мәскәүдә Президентыбыздан яхшы карарлар чыксын дип,

халыкка ятышлы, халыкны яклый торган, экономикабызны күтәрә торган, илебезнең бәйсезлеген раслый торган карарлар булса, без һәрвакытта да эшчән халкыбыз белән горурлана алабыз.

Инде сүзнебашлап киткәчтен, башка чыгышларга күчкәнче, без монда шәхси хуҗалыклар белән ничек эшлибез, фермер хуҗалыкларга ничек ярдәм итәбез, шулар турында сөйләшербез дип монда җыелдык. Шулай бит. Безнең әле чыгышыбыз булачак Академия Наукта. Шуңа күрә хәзер безнең әзерләнгән кечкенә генә видеосюжет бар. Шуны карап китсәк, аннан соң фикерләрне уртакка салып, чыгышларны бергә тыңлап китәрбез.

*Видеосюжет.*

**Ришат Хәбипов:** Фәрит Хәйруллович Мөхәммәтшин, Марат Готович үзебезнең вице-премьер белән ел саен без менә шундый нәтиҗә ясыйбыз. Безнең конкурс бар “Иң яхшы фермер”, “Иң яхшы шәхси хуҗалык”, “Иң яхшы авыл җирлеге”, “Иң яхшы кооператив”ка. Һәр районнан җиңүчегә 50шәр мең премия бирәбез. 100 премия ел саен тапшырыла.

Бүген инде миңа әйттеләр, нинди тема белән чыгыш ясарга дип. Ул инде шәхси хуҗалыклар темасы буенча. Шулай бит инде. Шәхси хуҗалыкта ничек терлек асрап, үзеңнең бакчаңда, үзеңнең сараеңда мал асрап, ничек тормышны алып барырга. Һәм Татарстанда нинди тәҗрибә бар, шәхси хуҗалыкларны үстерергә.

Безнең сайтны күрсәгез була. Безнең Татарстанның агросәнәгать характеристика. Авыл җирлекләрендә безнең 1 миллионга якын халык яши. Һәм авыл җирлекләре башлыклары белән без бүгенге көндә перепись мәгълүматлары бар. Шәһәр халкы, авыл халкы белән бергә без карасак ,501 мең безнең ЛПХ дип әйтәбез, шәхси хуҗалык бар.

Менә ул шәхси хуҗалыкларда бүгенгесе көндә 110 мең савым сыеры асрала. Әгәр дә илдә сыер бар икән, авылда тормыш бар, аның бозавы була, сөте була, мае, каймагы. Менә шул күзлектән чыгып, авыл тормышын җайландыру өчен безнең программа кабул ителде. Ул үзебезнең Дәүләт

Советы кабул иткән шәхси хуҗалыкларны үстерергә юнәлтелгән закон нигезендә. Ул закон эшли инде 3нче ел.

Без ел саен Россия Федерациясендә булган программаларда катнашып, фермер хуҗалыкларын үстерәбез. Ул федераль программаларга хәтле, безнең Республика программасына карсагыз, Республика программасы бар, семейная ферма программасы бар. Шул ук программа нигезендә, кемнәр сөтчелек белән шөгыльләнәләр, савым сыерлар белән шөгыльләнәләр, 24 башлы ферма төзегәннәргә 1 миллион сум грант биргән идек. Кемнәр инде откорм белән шөгыльләнә, кемнәр башка төрле эш белән шөгыльләнәләр, сарык үстерү, дуңгыз үстерү булсынмы, менә аларга бирдек без 5 миллион сум күләмендә грант.

2 ел булды ул программа. Бу программаны сафка бастырган кешеләр бик актив рәвештә эшләделәр. Һәм без шул 2 ел эчендә фермаларны төзекләндереп, төзеп, оборудование биреп, аларны сафка бастырдык. Моннан тыш, гранттан тыш субсидияләр бирелде терлек алганга, савым аппаратларына. 40ка якын программа бар республикада. Оборудованиены программалар субсидия рәвешендә кире кайтарып бирделәр.

2012нче елда эшли башлады федераль программа. Шул федераль программа кысаларында без актив рәвештә “Начинающие семейные фермы” программаларына кереп киттек. Бүгенгесе көндә без сумманы җиткердек 250 миллион сумга, грант суммасы гына. Начинающийга 250 милион сум һәм семейный фермага 250 миллион. Кооперативка тоже 250. 750 миллион сум быел грантларга бирелгән акчалар.

Бу безгә мөмкинлек бирә ел саен, ни өчен сумма шул хәтле арттырылды, ел саен күпмедер конкурста катнашучы кешеләребезне канәгатьләндермичә кала идек. 1 урынга 3-4 заявка була торган иде. Менә инде суммаларын да арттырдык без. Начинающий фермерга 3 миллион сумга хәтле, кем сөтчелек белән һәм мөгезле эре терлек белән шөгыльләнә. Ә инде гаилә фермаларына 10 миллион сумга хәтле грант. Кире кайтара алмый торган, бушка бирелә торган грант.

Бу программа нигезендә бер ел эчендә төзеп бетереп була ферманы да, терлекне дә алып була. Тәҗрибә шул хәтле матур күрсәтә, безнең авыллар җанланып китте. Бүгенгесе көндә һәрбер авылда 3-4тәр, 5шәр гаилә фермасы булган авылларыбыз бар. Авылның социаль-икътисадый һәм мәдәни эшчәнлекләре, юлны чистартумы, Сабантуй үткәрүме, мәктәпкә ярдәм итү, детсадлар – бу әйберләр бөтенесе дә бер-берсе белән аралашып баралар.

Һәм инде безнең тотылган акчалар менә монда күрсәтелгән. 2017 елдан субсидия бирелми. Элек 700 мең сумга хәтле акча алып була торган иде. Аңарга субсидия бирелә иде.

Менә бу безнең шәхси хуҗалыкларга нинди ярдәм белән үзебез аларга булыша алабыз. Беренчесе, безнең бик күп гаиләләр катнаштылар “Мини фермалар төзү” дигән программада. Нәрсә ул? Без шундый программа кабул иттек. Кемнең бар ике сыеры, әгәр гариза язып, шәхси хуҗалыкта эшләгән апамы, абыймы бирәләр икән гариза, мин сыер санын 5кә җиткерәм дип, ул бер ел эшли дә, 8 айдан да, вакыты каралган, ул ала 120 мең субсидия.

Яки яңа сарай төзегән булырга тиеш 5 башка или 8 башка. Ул сарайның 50% төзелеп беткәч, башкарма комитеты раслый документны һәм безгә реестр белән управление китерә. Шул управление китергән мәгълүмат белән без акчаны управлениега күчерәбез. Управление бирә инде шәхси гражданнарга кире кайтарып субсидия рәвешендә.

Кемнең 3 сыеры бар һәм тагын да 5кә арттырам дип гариза яза икән, аларга субсидия бирәбез 200 мең. Быелгысы елны без карадык, кемнең 5 сыеры һәм аңардан күбрәк бар, тагын 5кә арттырам ди икән, аларга субсидия 300 мең сум түләнелә. Әйтәбез, сыерның шлейфы да бар. Аның бозавы туа бит, аңарга да урын кирәк.

Менә бу әйберләр эшләнде безнең күпмедер уйланулардан соң халыкны ничек эшле итәргә. Әйе, бөтен кешене дә сыер тотарга, сыер асрарга бүген мәҗбүр итеп булмый. Әгәр ул сыерны бер бетергән икән, кире алмый инде ул аны. Ләкин шул вакытта авылда да күпләр сыер асрарга теләүче кешеләр. Менә шуларга ничек ярдәм итеп була?

Президент белән безнең сөйләшү бар. Шәхси хуҗалыкларга сораган әйберләрне Президент ел саен хуплап, карарлар кыла. Хатларга уңай карар кабул итеп, без акчаларын бирәбез. Безнең сыер саны ел саен кими иде 5 мең, 6 мең, 7 мең башка шәхси хуҗалыкларда. Ике ел дәвамында без сыер-сарык киметүне туктата алдык шәхси хуҗалыкларда. Менә бүгенгесе көндә статистика мәгълүматлары бар. Реаль мәгълүмат бар, ветеринарлар бар. Алар кан алганда һәрберсенең башын язып баралар бит инде. Шул саннан әкрен-әкрен генә 3 ел эчендә бөтенесе дә тигезләштеләр. Шуның өчен безнең бер генә дә ялган сыерыбыз юк. Бөтенесе дә учетта. Без белеп торабыз. Чөнки апамы ул абыймы, 3 мең сум субсидия биргәндә, килә, үзенең сыерын күрсәтә. Без бит әле моңардан тыш һәрбер сыерга 3 мең субсидия бирәбез.

Быел Президент карар кабул итте, кемнең бер сыеры бар 2 мең акча бирергә, кемнең 2 сыеры бар – һәрбер сыерга 3 мең, кемнең 3 сыеры бар һәм аннан да күбрәк сыеры булганнарга һәрбер сыер башына 4 мең сум субсидия бирелә. Без субсидияне бирәбез мартның 10нан, 15нән.

Ул ни өчен эшләнелгән? Бер сыерлы кеше бит инде сөтен үзе куллана, күршесенә, туганнарына биреп бетерә. 2 сыерлы, 3 сыерлы алар барыбер саталар. Саткач, сатып алу бәяләре 3 сумнан алып, 5-10 сумга хәтле төшкән җирләр бар диләр. Шуны компенсацияләү хисабыннан без менә шундый карарны кабул иттек. Ул барыбер бер литрга 3 суммы, 4 суммы бәя дигән сүз. Шулай бит. Сыерга суймасыннар өчен, сыерны киметмәсеннәр өчен эшләнелде.

Икенче программабыз бар безнең. Сыер янына тана алган кешеләргә субсидия бирәбез бер башка 15 мең күләмендә. Читтән алып кайталар икән, чит субъекттан, Марий Элдан, Чувашиядән, Башкортстаннан, без разрешение бирәбез бер башка 30 мең сум күләмендә. Ул күпмедер рәвештә безгә мөмкинлек бирде уртача елга мең ярым, 2 мең баш терлекне яңадан үстерергә.

Куйган программалар барсы да эшлиләр. Безнең программа буенча субсидияләр бирәбез атларга. Алар өчен субсидияләр “На кобыл” дип атала.

Президентның карамагы 3 мең сум күләмендә. Ул мөмкинлек бирә атлар санын стабильләштерергә. Шул вакытта безнең эшли, аның суммасы 500 сум күләмендә тавык чебиенә. 50% ка хәтле язылган сатып алу бәясе.

Ул субсидияләр авылда эшләгән кешеләрне эш белән тәэмин итәргә. Бүген инде беркемгәдә гаҗәп түгел, әгәр дә зур җиһазлы техника, киң сеялкалар, зур тоннажлы машиналар бөтен кешегә дә бүгенгесе көндә мөмкинлек бирми авыл җирендә эш белән тәэмин итәргә. Шуның өчен без шунда яшәгән кеше авылдан китмәсен өчен бу программаларны инде ел саен камилләштереп барабыз.

Киләсе елны уйлап торабыз законга үзгәреш кертергә кыйммәтле теплица тоталар. Аларга теплицаның квадрат метрына 500 сум күләмендә субсидияне бирергә һәм аларны орлык белән тәэмин итеп, эшләргә.

Иң күләмле эш башкарылды безнең кооперативлар буенча. Безнең бит инде крестьяннар янына барсаң, алар әйтәләр: “Сез безне өйрәтмәгез ничек икмәк үстерергә, ничек терлек тотарга, ничек удобрение кулланырга”, -дип. Сез әйтегез безгә, көз көне без үстергән әйберне, зерноны, малны кем нинди бәягә сатып ала. Сездә дә шулайдыр?

Крестьян һәрвакытта да яраклаша нинди дә булса кырыс условияларга, йә булмаса табигатькә. Сөтне дә сатып булмый бит. Бүген сатып булмый сарык итен, йонны, бални кая куярга урын юк. Шуның өчен без кооперативлар аркылы бүгенге көндә продукцияне эшкәртү, аны сәүдә челтәрләре таләпләренә туры китереп сөйләштек.

Менә монысын карап китә аласыз. Менә мин әйткән фермалар – 5 сыерга, 8 сыерга, 10 сыерга. Алар бик күп хәзер. Бүгенге көндә 1031 шундый гаилә фермасы төзелде. 2 ел эчендә ул бик күп.

Без Казан шәһәрендә һәм Чаллы шәһәрендә төзедек шатровый ярмарка площадкаларын бушка. Крестьян-фермер хуҗалыгы әгъзалары җитәкчелре килеп, үзләренең продукцияләрен бернинди налог түләмичә, сату урынына акча түләмичә, үзләренең продукцияләрен сата алалар. Обедка хәтле алар сата, аннан соң инде эшмәкәрләр керәләр. Менә шуларны оештырдык. Безнең

7 шатровый площадка Казанда төзелде. Аңардан тыш безнең 10 урында бар ярминкәләребез. Ул ярминкәләрдә без ел саен матур итеп эшләдек. Декабрьнең азагына хәтле без сентябрьдән алып ярминкәләр үткәрдек.

Бүгенге көндә шатровый площадкаларыбыз көн саен эшлиләр. Ярминкәләрне без суббота-воскресенеье үткәрәбез. Менә шундый безнең чараларыбыз бар. Әйе, бөтенесе дә камил булмаска мөмкин. Бөтенесе дә бик чиста, пөхтә итеп эшләп тә бетерелмәгәндер. Кемдер алдаучылары да бар. Субсидияне бит инде тиз генә тикшереп бетереп булмый. Шуның өчен безнең авыл җирлекләрендә хәзер уйлыйбыз законны үзгәртеп бетерергә. Авыл җирлеге башлыгы шулай бит инде, тизрәк күрә, тизрәк аңарга ярдәм итү мөмкинлеге туа.

Менә шул күзлектән эшне алып барабыз. Әгәр сорауларыгыз булса, без инде үзебезнең сайтта бөтен мәгълүмат куелган, agro.tatarstan.ru сайтында. Без ул мәгълүмат белән уртаклашабыз. Безгә бик ошады уңай мәсьәләләр Липецк өлкәсендә. Бик уңай мәсьәләләр бар безнең Ульян өлкәсендә. Безнең коллегаларыбыз барып кайттылар анда форумга. Һәм шул вакытта без Чувашия белән, Пенза өлкәсе белән, Самара өлкәсе белән, үзебезнең эшмәкәрләр белән эш итәбез.

Әле менә 13-15 җыенабыз Башкортстанга. Анда Халыкара форум үтәчәк. Анда да яхшы тәҗрибәләр бар. Безнең башкорт коллегаларыбыз әйттеләр 100 грамм бирәчәкләр өчәр миллионнан кечкенә кооперативларга. Ул безне кызыксындыра. Менә шуның турында сөйләдем. Әгәр дә кызык булса, яңадан калып та сөйләшеп була. Фикерләрне туплап, тагын аралашып алсак әйбәт булыр иде. Тыңлаганыгыз өчен бик зур рәхмәт!

**Радик Муллагалиев**: Инде бүген беренче эшләү көнегез. Мин уйлыйм, сезнең өчен үзара танышуыгыз да шактый мөһим нәрсә. Менә шуңа күрә бүген үзебезнең мәйданчыкны танышуга багышлыйк әле. Беренче сүзне без Башкортстан Республикасыннан **Бәкиров Ирек Гомәр** улына бирәчәкбез. Рәхим итегез!

**Ирек Бәкиров**: Хәерле көн милләттәшләр! Безгә бит инде күренеп тора, авылда яшәгәч нинди проблемалар бар икәне. Башта инде йөреп чыктым авыл советын. Әйттеләр: “Эй, абый, бер ике ел алдан башлаган булсаң, сөтне кая куярга белмәдек”, - диләр. Шуннан соң инде президентыгыз диләр, глава дигәнне кабул итмиләр, чөнки республика ул, дәүләт ул. Менә безне Рөстәм Нургалиевич җыйгач инде, анда да шуны сөйләделәр. Сыер асрарлары бар, сыер юк. Сыер саварга куллары бар, сыер алырга акча юк.

Без сөйләшә алдык. Аларга шушы ук абзарларны эшләтә алдык. Безне бик каты өметләндереп киттеләр. Димәк, алар сыерларны алып бирәләр безгә, без инде аларны сөт белән каплап, 3 елда каплап бетереп була, хәтта көн дә 2 литр сөт бирсәң дә.

Икенчедән, бер мисал китерәм. Үземнең гаиләнең 3 кибете бар. Менә шушы өч 9 булган кибет иң уңышлысы эшли. Шуннан бу шатлык күпкә җитми. Карар кабул итеЛә. Кооперативлар 9% җыйса, значит механизм кала. Шуннан соң тагын нәрсә бар. Әлбәттә, авылда бернәрсә калмады. Эш урыннары гына җитми, аларга бит тору урыннары да кирәк. аларга бит мәктәбе дә кирәк. Кызганычка каршы, мәктәпләр дә ябылган, балалар бакчасы дә кимеде бит инде.

Бу юнәлештә республика җитәкчеләре тырышалар. Республиканың бюджеты җитми дә. Халык белә бит. Кризис башланды. Авыл җирлеге белән Мәскәүне чагыштырып булмый бит. Анда бит доходлар космические. Регионнарның стимулы кими.

Советлар Союзында булды бит инде милли мәктәпләр өчен кыскартылган иде рус теле. Менә шулар бөтенесе бик мөһим мәсьәлә. Алар безнең кәефне боза. Шуннан соң тагын бер нәрсә бар, мен пай җирләре дидек. Пай җирләре бирелде. Хәзер инде гел шул яктан киләләр дә, җирләрне сатып алалар. Менә моңа ничек каршы торырга? Алар шушы җирне алачаклар да. Шуннан соң хәзер җирсез дә калсак дибез.

Барыбыз да уйларга тиеш. Бер Миңнеханов кына түгел, бөтне татар халкы уйларга тиеш. Менә мин Казанга килгән саен гел шуны сөйлим.

Сугыш вакытында безнең бабабыз беренче Парижга килә. 2 орден ала ул.сугышларда безнең милләт кирәк, ә тыныч тормышка күчсәк, без онытылабыз. Без бит шушы ук гражданнар. Безнең дә мәдәниятебез бар, безнең дә тарихыбыз бар, безнең дә телебез бар, безнең дә җиребез бар.

Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

**Ришат Хәбипов:** Ирек Гомәрович, рәхмәт! Нишләтәсең, ул аның йөрәге аркылы үткән инде. Ул проблемалар барыбызда да бар. Кемдер кычкырып йөри, кемдер күпне сөйли, кемдер бөтенләй сөйләми. Ләкин төрле төбәктә ул мәсьәләләрнең хәл итү юлларын табарга тырышалар.

Менә җир пайлары турында сез әйттегез бит. Белград өлкәсе ел саен үзләренең бюджетларыннан җир пайларын сатып алырга акча караганнар иде. Аны бит инде барыбер кеше сатканчы, хөкүмәткә хәбәр бирергә тиеш, мин җир паен сатам дип. Бүген Савченконың командасы бөтен җирләрне сатып алып, дәүләтне киптереп, арендага бирәләр. Кем яхшы эшли, аренданы озайталар ,кем эшләми – өзәләр.

Бу бирелгән иде төрле төбәкләргә дә. Кемдер аны кабул итте, кемдер итмәде. Ләкин яклау чаралары кирәк. Дөрес әйтәсез, Татарстанда безнең бер генә гектар җиребез дә буш түгел. Бөтенесенең милектәге хуҗалары бар, шәхси хуҗалыклар, яки фермерлар, инвесторлар. Шуның өчен 3 миллион ярым гектар безнең сөрү җирләребез эшлиләр. Былтыргы елны без 5 миллионнан артыграк уңыш җыеп алдык. Җирең булмаса, уңыш җыялмыйсың бит инде.

Шуның өчен сезнең шәхси хуҗалыкларны үстерү буенча әйткән сүзләрегез безне кызыксындырды. Без Башкортстанга барганда сездән сорыйсыбыз килә, татар бит инде тотып карамыйча ышанмый диләр, кайда тотып карап була шул эшләгән шәхси хуҗалыкны. Шәһәр бизнесменнары килеп, сыер алырга акча бирделәр дисез бит  Бөтенебезгә дә бу кызык. Шулай бит инде. Балконда бит инде сыер асрап булмый.

Шәһәр кешесе, бүгенге көндә безнең шундый практика бар, акча биреп авылдагы фермердан яки шәхси хуҗалыктан, Казанда да шундый

эшмәкәрләр бар. Сыерны асрарга терлек азыгы әзерләргә, акчасын бирә, ә продукциясен килеп алалар. Андыйлар бар.

Кемдер үрдәк үстерә. Ул әйтә, миңа комбикорма ашатмыйча гына үлән ашатып кына каз үстердем дип әйтүчеләр бар. Бик кызыклы әйбер ул. Дәвам итәбезме.

**Радик Муллагалиев**: Әйе. Безнең кунагыбыздан Рөстәм Әминовны чакырабыз. Әйдәгез, кыскача гына таныштырып җибәрегез Томск шәһәре турында. Рәхим итегез!

**Рөстәм Әминов:** Мин үзем Иркутск шәһәрендә, Иркутск өлкәсендә тудым. Томск – ул отдаленное место ссылки каторжан. Мин үзем фермер. Пока начинающий гына. 9 баш мал үземдә. Бик авыр, конечно, бездә северда. Мин 5 километр Томскидан тотам. Безнең якта тоже бик күп татарлар. Яшьләр бик күп туа. Кирәк поддержка тоже. Дулкынланам бераз. Бик зур рәхмәт!

**Ришат Хәбипов:** Татар кешесе молодец! Томскидан ерак түгел инде, 5 километр. Но бөтен әйберне сатып була бит инде анда. Шуның өчен выгодное условие дә, әгәр 9 баштан күбрәк, эле Кытай сезгә якын. Шуңа күрә без борчылмыйбыз. Авыл хуҗалыгы продукциясе бервакытта да югалып калмаячак ул.

**Радик Муллагалиев**: Киләсе сүз **Иванов Василий Алексеевич**, Марий Эл республикасыннан. Рәхим итегез!

**Василий Иванов**: Мин Марий Эл иленең кечкенә генә керәшен авылыннан килдем. Без бүгенге көндә кәҗә асрау белән шөгыльләнәбез. Безнең Россиядә иң зур кәҗә фермасы безнең Мари илендә. Анда бүгенге көндә 5 мең баш кәҗә асрала. Сөт, сыр продуктлары җитештерү белән шөгыльләнәләр.

Без үзебезнең сөтне шунда алып барабыз инде. Башта без 40 кәҗәдән башлаган идек. Бүгенге көндә безнең 120 баш кәҗәбез бар. Ни өчен кәҗә? Чөнки бездә юллар сездәге шикелле юк. Юл булмагач сөтне ничек ташыйсың. Кәҗә сөте күп түгел.

Фермабыз бар 120 башка. Бүгенге көндә аны үз кулыбыз белән эшләдек. Анда бик уңайлы. Кәҗәләрне аппарат белән савабыз. Кәҗә белән эшләве күңелле. Әгәр дә без киләчәктә дә эшне шулай алып барсак, без кәҗә санын арттырырга телибез. Билгеле инде, бу бәя кәҗә сөтенә бик кәнәгатьләндереп бетерми.

Без монда сезнең хөкүмәтнең Татарстандагы фермерларга, авыл хуҗалыгы кешеләренә булган ниятләрне күреп, шак катып утырабыз инде. Сездә бит инде сыер санына сыер башы төшми. Аннан соң мин Татарстанда булам, күп җирләрдә кешеләр белән очрашам, сөйләшәм. Күбесе әйтәләр инде бүген сөтнең бәясе бер төрле, иртәгә ул төшеп китә, берсе көнгә күтәрелеп китә шикелле.

Менә минем Татарстан хөкүмәтенә дә әйтәсем килә. Татарстан бит инде ул Россиядә алдынгы. Әйдәп баручы республика. Шулай бит. Менә булсын иде авыл җирлегендә государственный заказ дигән нәрсә. Менә син тотынгансың икән эшкә, синең сөтеңне алучы, нинди бәядән алучы, күпме акча түләүче – ул бөтенесе билгеле булсын иде алдан ук. Менә шушы эшне эшләп буламы?

**Ришат Хәбипов**: Только кооператив аркылы. Башкача булмый. Эшкәртүче кооператив кирәк. Без бит инде һәрберебез бикләнгән зур забор артына. Шыгырданга барсаң, анда күрәсең, Чувашиядә безнең татар авылы бар зур гына. Анда заборлардан тыш капкасы тагын да зуррак.

Ни өчен? 10 гектар җирең бармы, сиңа МТЗ-12, 21 тракторы обязательно кирәк. Без бит берләшә белмибез. Һәрберебез чыгым чыгарабыз, шуны тотабыз, ләкин берләшик. Менә бу берләшү өстендә эшләнгән программалар бар, кооператив төзү. Дәүләт акча бирә. Без менә 4 кооперативка быел бирәбез 70 миллион акча, оборудование алырга, техника алырга, эшләтү цехын алырга.

Башкача булмый. Ул бит инде берләшкәч, кооператив эшкәртә дә, продукциясен сата. Ә сырьены бүгенгесе көндә безне унижать итеп очсыз бәягә алалар.

**Василий Иванов**: Аннан соң минем тагын бер мөрәҗәгатем бар иде. Әгәр дә бездә Мари җирендә яшәүче татарлар кәҗә сөтен сез эшкәртә алырга берәр төрле производство төзи алмассыз микән. Ни өчен дигәндә, бүгенге көндә Россиядә бердәнбер монополист. Алар бәяне нинди куялар, кибеттә бәя шул.

**Ришат Хәбипов**: Мин килешәм. Сез белсәгез, Сабада безнең бер предприятие бар бит инде. Безнең анда 2 меңнән артыграк кәҗә бар. Тагын бер шундый зеркальный проект ясасак, безнең зур производство була. Кәҗә сөтен эшкәртү өчен уртак бер завод ясарга кирәк. Кооперативный завод ясыйбыз. Аны берничә субъект белән ясарга була бит инде.

Безнең бар кечкенә генә фермерларыбыз. Лаеш районында да бар. Аларның продукцияләре в основном или күршеләргә или базарга сатылып бетеп бара. Берсе дә калмый. "Бәхетле" магазины системасына кердек. Ул магазинны беләсез бит инде. Анда менә кәҗә сөте бар безнең. Мин килешәм. Эшкә алыгыз, яме. Рәхмәт сезгә!

Без Россия күләмендә иң күп сөт җитештерүче субъект. Без беренче урында торабыз. 1 миллион 800 мең тонна сөт җитештердек былтыргысы елны. Һәм сөт бәяләре шулай төшкәч, безнең коллегия булды үзебезнең авыл хуҗалыгы министрлыгында. Чыгыш ясаган хөкүмәт башлыклары, эшмәкәрләр Президентка мөрәҗәгать иттеләр Путинга яки Медведевка хат язарга дип.

Безнең Рөстәм Нургалиевич хат белән Сочида булган форумда чыгыш ясады. Путин мөрәҗәгатьне ишетеп, Дворковичка команда бирде сөт бәяләре белән кызыксынырга һәм аның кимүен туктату буенча эшне башларга. Димәк, февральнең 6нчы числосыннан Белоруссиядән кертелә торган сөт продукцияләренә эмбарго дибез, кертмәскә диделәр. Анда сөт кенә керми, сухое молоко керә, коры сөт керә, сыр, май.

Әйтәләр, Россиягә бер еллык коры сөт кергән дип. Бүгенгесе көндә коры сөттән кире ясалган, восстановленное молоко дип әйтәбез, аның бәясе 10 сум. Шуңардан ясыйлар сыр, каймак, май һәм шуны без эчәбез. Ул бит инде

350 градуста киптерелгән сөтнең нинди кыйммәте калсын. Без шуның белән балаларны ашатабыз. Ладно без инде үскән, но балалар бар бит.

Шуның өчен Аллаһы Тәгалә боерса, без уйлыйбыз инде сөт бәяләре торыр дип. Профессорыбыз Нигъматуллин язган, бүгенгесе көндә сөт бәяләре солярка бәясеннән кыйммәтрәк булырга тиеш. Солярка безнең 42 сумга җитте хәзер заправкада. Ә сөтне бездән алалар 14-16 сумга. Бергәләп, үзебезнең форумда да аны карарга кирәк.

Безнең бүгенге көндә шундый программа бар. Кем 2 мең 200 тонна сөт көн саен савып сата, аларны Президент тарафыннан карарлый ул районга 200 миллион сум премия. Бүгенге көндә 3 шундый район бар. Көн саен 200 тоннадан артык сөт җитештерәләр. Уже претендентлар бар. Өстәлде тагын 7 район, шул позициягә чыгабыз диләр. Ферма төзү, мал санын арттыру. Ул бит инде сөт кайда җитештерелсә дә барыбер, шәхси хуҗалыктамы, фермадамы, кооперативта буламы  яки хуҗалыкта буламы. Тоже бер стимул эшләргә, шулай бит.

Бюджеттан, Дәүләт Советы карары белән. Бюджетка үзгәреш кертелә һәм дополнительный доходтан кергән акчаны без җибәрәбез. 200 миллион районга бирелә. Разовая премия бу. Анда җиттең дә төштең түгел. Ел дәвамында көн сае 200 тонна сөт сауса. Монда безнең керде Кукмара, Балтач, Әтнә.

**Радик Муллагалиев**: Хәзер Ульян өлкәсеннән **Яфарова Камилә Наил** кызын сорыйбыз. Рәхим итегез!

**Камилә Яфарова**: Хәерле көн кадерле дуслар! Без килдек бүген Ульяннан. Немножко биографическую характеристику дам. Случилось так, что всю свою жизнь мне пришлось связать с сельским хозяйством. Работала на кафедре защиты растений, преподавала пчеловодство. Работала агрономом, ветеринаром, зооинженером.

Были у нас и свои пчелы. Карпатская порода была. Занимались районированием итальянских пчел. Получали пчелиный яд, маточное молочко. Было у нас до 70 пчелиных семей.

Жили также в селе, держали пчел, был огород, все в основном для своих нужд. Работая в школе, также у нас там был кружок пчеловодства. Дети очень интересовались, и я ввела этот кружок.

У нас есть сортовые саженцы плодовых деревьев, ягодники, малина. Построили внутри теплицы, на которых выращивают томаты, огурцы, перец, баклажаны. Стараемся привозить хорошие семена, где мы бываем. Например, семена томата грушевидные и бычье сердце мы привезли из Болгарии, семена томата баклажанного и клубники – из Турции.

Хорошим спросом пользуются томаты Болгарский грушевидный, а также желтые и розовые турецкие. Их в основном берут для консервирования. Перец болгарский, к сожалению, берут плохо, т.к. их массовый завоз из южных областей по дешевой цене. А так продавать нам не выгодно. Хотя по вкусовым качествам наши намного лучше. С баклажанами та же самая история, реализации никакой. Теплицы у нас пока не отапливаемые. В планах постепенно их сделать отапливаемыми.

7 лет назад почти рядом с домом построили вышку сотовой связи. И хотя в журналах пишут, что сотовая связь не влияет на пчел, но это не правда. Потому что мы знаем как за ними ухаживать. Мы все знаем о пчелах. За эти годы пчелы, вероятно, накопили в себе отрицательную какую-то энергию что ли. Возможно, на них влияют и другие какие-то факторы, естественно, в том числе и экология.

Есть много нерешенных вопросов, связанных с реализацией меда. Трудно продавать свой настоящий мед. Так как приезжают медовые ярмарки с разнообразными, иногда с не существующими сортами меда. Читаешь и удивляешься, как они его получают, как пчелы выбирают именно этих растений, не понятно.

Но есть, к сожалению, и порядочные пчеловоды, которые продают с сертификатом. Но, конечно, фальсификаты продают намного дешевле. А наш настоящий мед по такой цене продавать не хочется. У нас в Ульяновске есть общество пчеловодов, курсы пчеловодов, где мы проводим занятия с

начинающими пчеловодами, с начинающими любителями. Желающих, конечно, очень много.

Работая в своих теплицах, мы стараемся не использовать никакие ядохимикаты. Делаем подкормки с золой, с дрожжами, простоквашей, зеленкой, йодом, луковой шелухой, настоем трав. С болезнью вредителей тоже стараемся бороться народными средствами.

Построили курятник. Пока на 200-250 кур. Птицей у меня в основном занимается муж Аскар. Хочется иметь экологически чистую продукцию, которым мы обеспечиваем своих детей, внуков, родственников, знакомых. Полученные доходы стараемся вкладывать в развитие подсобного хозяйства. Т.е. планов у нас еще очень много. Ходай саулык бирсен, дөньяга тынычлык. Тагын көрешергә насыйп булсын. Рәхмәт игътибарыгыз өчен!

**Радик Муллагалиев**: Рәхмәт! Сезне киләчәк хатын-кызлар бәйрәме белән. Сау булыгыз. Чувашия республикасыннан катнашучылар бармы безнең арабызда? Кемнең чыгыш ясыйсы килә, кемнең теләге бар, әйдәгез, рәхим итегез.

**Делегат:** Мин Башкортстанның Кыйгы районыннан. Монда менә Чувашия турында әйттеләр. Мин Чувашиянең Шыгырданыннда 4 мәртәбә булдым. Урта Әләзәндә Пензада тоже ничә мәртәбә булдым. Әзрәк дин әһеле буларак, менә мин шулай уйлыйм.

Быел яңа елдан соң без Чувашиягә Башкортстаннан Министерство сельского хозяйство белән 40 кеше делегация алып барырга тиеш идек, чувашлар безне кертмәделәр. Менә шушы вакыйгны мин менә бу трибунадан әйтәсем килә. Ә нигә кертмәделәр алар? Мин Чувашиянең мөфтие белән дә таныш, администрация башлыгы белән дә таныш. Алар түгел, ә предпринимательләр кертмәделәр.

Хәзер менә уйлыйм. Татарстанның бөтен районнарыннан да килделәр. Ә аларга нинди польза от этого. Аларның бит бер авылда гына 4 убойный цех эшләп тора. Һәр көнне иң әзе 25 баштан алып 45 башка хәтле мал суялар. Анда барсы да потокка куелган һәм бердигән эшлиләр.

Мин үзем животновод түгел, көчле фермер да түгел. Ә болай мин бәрәңге белән заниматься итәргә уйлыйм. Бөтен җирдә дә бардыр инде. Мин идеяләрне әйтәм главаларга, ә алар миңа 50 на 50 ди. “Прибыль булса, 50% бирсәң, мы тебя будем поддерживать”, -диләр. Шуның аркасында без тавыш күтәрәбез инде. Шуңа менә хәзер тагын возиться. Хотя министерствода әйтеп торалар, әйе, бу кирәк нәрсә, крахмал, мин бәрәңге крахмалы турында хәзер әйтәм.

Потому что мин хәзер отчетность буенча беләм, безнең республикада гына 462 мең тонна кирәк. Хоть Башкирия бер кайдан да сорамый. Татарстан тоже сорамый крахмалны. Россия чыгара 13% гына. Менә безнең монда Чишмә районыннан фермер бар. Алар садикларга, мәктәпләргә кисель эшлиләр. Ә кисель бит ул крахмал. Ә ул крахмал аларның искусственный крахмал. Ә без әйтәбез бит инде оздоровление нации дибез.

Ә безнең менә бу крахмал булса үзебездә бөтенләй икенче төрле булыр иде. Мин менә шуның артыннан йөреп ятам. Монда да нәрсәдер ишетермен дип киләм. Бөтен җирдә булырга тырышам. Ә теләгем шул – менә безгә Чувашиянең Шыгырданы, Урта Әләзән кебек яшисебез килсә, алардан үрнәк алып, аларча яшәсәк, безнең киләчәгебез бар. Ә болай, әллә нинди кооперативлар создавать итсәк тә, если анда эшләргә кеше булмаса, халык булмаса, булмый ул. Менә минем теләгем шул – алардан үрнәк алып, алар тәҗрибәсен бөтен җиргә җиткерергә кирәк. Уңышлар сезгә!

**Ришат Хәбипов**: Хөрмәтле дуслар, бик матур теләкләр! Әйе, Шыгырдан авылында безнең татарларыбыз яши. Бүген инде бер генә мәчет түгел. Былтыр барган идем, алар анда бишенче мәчетне салдылар инде. 2нче урта мәктәпне салдылар. Бик матур эшләп киләләр. Аларның делегацияләре килгәндер, әлбәттә, конгресска. Без күрешербез.

Мине үземне кызыксындырган мәсьәлә – шәхси хуҗалыклар менә бу льготаларны ничек эшлиләр. Аннан соң алар Татарстаннан да терлек алалар. Ночной директорлар бездә тоже бар. Алар эшмәкәр булып йөриләр, көндез выписывать итәләр, төнлә алып китәләр. Аңлыйсыздыр, нәрсә әйткәнемне.

Авылда халык бетә дигәнгә үзебезнең баш аркылы үткән тәҗрибә бар иде. Мин үзем хакимият башлыгы булып эшләдем 12 ел. Авыл хуҗалыгы районында, промышленностьтә бер нәрсә дә юк. Бүгенге көндә шул авылда эшләп ята зур завод. Без эшләп башлап җибәргән завод ул. Сеялкалар күргәнегез бардыр бит инде, чәчкечләрне? Агромастер.

Менә шул заводны эшли башлаганда барып кергәндә 3 кеше идек, башлап китүчеләр. Бүгенге көндә анда 400гә якын кеше эшли. Миллиард ярымлык продукция җитештерелә. Бер авыл өчен җитә бит инде? Теләсәң, любой әйберне эшләп була. Теләк кирәк, уй кирәк.

Зур проблема булды безнең авылдагы ир-атларны бәхетле итү. Санап китсәң, Мөслим районында мин ул вакытта эшләгәндә, 10нчы елларда 4 меңнән артыграк буйдак ир бар иде. Өйләнмәгән егетләр. Аның кайберсенә 60 яшь җиткән инде. Бер тапкыр да өйләнмәгән. Сездә дә ул бармы? Тагын бер авылда 84 ир-ат бер тапкыр да өйләнмәгән. Зур авыл. Ничек аларны өйләндерергә?

Тарихка кире кайтып, без инде тикшердек муллалар белән, тарихчылар белән сөйләштек. Аның бит инде бергә ияләштерүче кешеләре була. Яучы карчыклар дип аталган. Аксакка аксакны, чукракка чукракны, әпәгә әпәне булса да ияләштергәннәр. Күрше авылда кемдер үлгән, яки хатыны вафат булган. Әйдәгез, бер-берегезгә туры киләсез дип, апа килгән оештырган.

Хәзер ул карчыклар юк. Интернет бар, мулла бар. Муллага әйтәм: "Әйдәгез, хәзрәт, үтик әле авыл буйлап. Менә бу егет бит инде агроном булып эшли. Бер дә өйләнмәгән". Ул бит эчә, нишләп мин аның кырына керим. Мин әйтәм: "Ул бит инде безнең кеше, эчсә дә синең җәмгыятьтәге кеше", -димен.

Бүгенгес көндә ул егет өйләнде. Без буйдаклар клубы ясадык. Исеме ямьсез, ләкин атна саен клубка җыя идек тә 40-50 кешене, хатын-кызлар кызыксынып килә. Алар да күп икән, кияүгә чыкмаганнар. Бер очрашуда бер гаилә барлыкка килде, ике, өч. Бүгенге көндә шул агрономыбыз, аңа хәзер 60 тулып киләдер инде 2 баласы бар. 50 яше тулгач өйләнде. "Безнең шул эшне

эшләүче кешебез юк”, - ди. Мулла үзенчә уйлый. Авыл советы үзенчә уйлый. “Бу минем эш түгел”, - ди. Хуҗалык җитәкчесе хәзер калмады. Партком секретаре юк, яучы карчыклары юк. Интернет бар, службы знакомств бар. Фотографиясен карый да, бу миңа ошамый, тегесе ошамый ди.

Мин егетләрдән сорыйм: “Ник өйләнмисез? – димен. – Шунда бар, кочакла, үзеңә алып кит”. “Абый, -ди, - мин оялам бит, сүз әйткәндә каушап калам”,-ди. Аның бит әле тәҗрибәсе бар. Т.е. бөтен кеше дә ямьсез характерлы түгел, ямсез фикерле түгел бит инде. Хәмдүнә әйтә бит инде, ир атны бит инде ничек кенә булмасын, аның әзрәк битен кырсаң, кырындырсаң, юындырсаң, киендерсәң, ул бит ир-ат. Безгә менә шуның өстендә эшләргә кирәк.

Без продукцияне җитештерәбез, ә авылда бит балалар юк. Ни өчен мәктәп ябылуы турында сөйләдегез бит хәлләрне. Безнең һәрберебезнең гаиләдә уртача ничә бала? Кемдә 5 бала бар? Миндә 2 малай, 3 кыз. Иң күп алга киткән илләрнең бүгенгесе көндә Индиядә уртача бер гаиләгә туры килә 6 бала. Кытайда, кызганычка каршы, без белмибез, анда әйтәләр уже икенче бала туганга рөхсәт бирделәр. Тагын кемнәрнең әйтәсе сүзләре бар?

Тигез тормыш бирсен барыгызга да. Әле мин сүземне күәтләп, нәрсә әйтәсем килә. Сезгә кергәнче генә, без Республика конкурсын үткәреп кердек. Безнең династияләр бар бит инде, гаиләдә эшне дәвам итүчеләр. Фермерлар династиясенә конкурс үткәрдек. Иртәгә безнең фермерларыбызның съезды була. 5 гаилә династиясе безнең йөзәр мең сум премия белән бүләкләнәчәкләр. Кемнең династиясендә этисе, бабасы фермер, малае или оныгы фермер булса, шундый гаиләләрне без барлыйбыз. Һәм алар эшләрен шулай дәвам итсеннәр дип шундый бер чара кулланыла.

**Усманов Рүзәл**: Хәерле көн, кадерле Татарстан җитәкчеләре, кадерле кунаклар! Рөхсәт итсәгез, минем дә сезгә бер-ике сүз әйтеп китәсем килә. Мин Марий Эл Республикасыннан. Безнең анда татарлар оешмасы бар. Шунда без яшәп ятабыз инде. Исемем минем Усманов Рүзәл. Үзем эшлим мин водоканалда.

Мин проблемалар турында нәрсә әйтәсем килә. Без смешанный халык булгач, гаиләләр кушыла инде. Бик зур инде безнең районыбыз. Безнең татарларның күбесе күчеп килгән халык инде. Без киңәштек тә, татар оешмасы булдырыйк дидек. Татар оешмасы татарлардан башка була алмый. Шулай бит. Смешанный группалар булгач, общение рус телендә инде.

Мәчетебезне салып чыктык. Яшь имамны алып килдек. Шуннан башлап киттек инде никах чараларын. Халык шул хәтле хөрмәт итеп килә анда, җомга намазларында халык күп була, Корбан гаетләре матур итеп үткәрелә.

Әлбәттә, Татарстан көчле инде. Бездә көнләшү дә бар инде. Татар халкы көнче халык  инде. Без ачы итеп көнләшмибез инде, ә чын күңелдән сезнең өчен шатбыз. Сезгә бик зур рәхмәт!

**Ришат Хәбипов**: Рәхмәт! Көчлесез, егетләр. Муса Җәлилнең шигыре бар бит

Мин күп күрдем филдәй кешеләрне:
Киң күкрәкле, тимер бәдәнле.
Тик күрәсе иде эше белән
Кеше булган иң чын адәмне.
Кем сокланмас көчкә, тимер сынса
Һәм су чыкса баскан эзеңнән.
Тик ни файда, көчең филдәй булып,
Эшең булса чыпчык тезеннән.
Барыгызның да уңышлы эшләр булсын!

**Радик Муллагалиев:** Зур рәхмәт катнашуыгызга! Шушы дискуссион мәйданчыкның нәтиҗәсе булып, без алда булачак пленар утырышка үз фикерләребезне тапшырырга тиешбез.

1. Урындагы татар оешмалары аркылы шәхси хуҗалык эшен алга алып бару. Безнең эшебез күбрәк пропаганда дигән нәрсә бит инде. Менә безнең яныбызда журналистлар бар бит инде. Менә шул журналистларны юкка чакырмыйбыз бит. Сезгә дә алар белән бергә информацион эш алып барырга кирәк. Реклама дигән нәрсә инде ул, дөресен генә әйткәндә.

Русча әйткәндә, через местные татарские организации сельской местности, средства массовой информации активно популяризировать деятельность личных хозяйств, как вид эффективных как вид самозанятости граждан неподвергаемые налогообложения. Сез шуны аңларга тиеш, шәхси хуҗалыклар салымга керми бит. 112 нче закон буенча ул предпринимательство дип саналмый.

2. Государственным ведомствам, работающим в области сельского хозяйства, способствовать в преобразовании наиболее эффективных личных хозяйств, фермерские предприятия. Дөрес аңласак, менә шул сез башлаган эшләрегез ахырдан бизнеска күчергә тиеш. Ул бит прибыль. Сез эшегезгә кызыксынып карарга тиешсез.

3. Рекомендовать общественной организации татарских сел создания единой социальной сети по обмену опытом и продвижения новых технологий. Ул социаль челтәр дип атала инде. Безнең бу мәйданчык та, аралашуыбыз сездә дә яңа фикерләр уятып җибәрер һәм файдалы булыр дип уйлыйм.

Якты юллар сезгә, уңышлар. Рәхмәт.

**Ришат Хәбипов:** Без программа буенча Фәннәр Академиясендә җыелабыз. Анда тагын бер тапкыр күрешербез әле. Сораулар булса, фикерләрегезне туплап, әйтерсез. Минем сайтка сорауларыгызны язсагыз була. Җавап бирербез. Исән-сау булыгыз!